ISSN: 2220-8445

# Тулпар

БАШКОРТСТАН ЯШЬЛӘРЕ ЖУРНАЛЫ

№ 5 /2023



Илсур Маликов фотосы.

**Руслан КИРАМЕТДИНОВ:**
“Бәгырең таш булса, онытып кара...”
*(30-33нче битләр)*

12+

podpiska.pochta.ru



# Мәгърифәтчеләр клубы


Уфада Мәрьям Солтанова-Акчурина исемендәге зыялылар клубы оешуга биш ел тулды. Шушы вакыт эчендә биредә татар халкы, аның тарихы, мәдәнияте, күренекле шәхесләребез турында илледән артык лекция, экскурсияләр оештырылды, Мәрьям Солтановага тактаташ ачылды. Бу хакта тулырак 34-35нче битләрдә урын алган язмадан укый аласыз.











podpiska.pochta.ru

# Тулпар

***Республика яшьләренең әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журналы***

5 (176) 2023
*сентябрь-октябрь*



**Гамәлгә куючылар:**
Башкортстан Республикасының Матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат чаралары агентлыгы;
Башкортстан Республикасының "Республика Башкортостан" Нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе

**Учредители:**
Агентство по печати и средствам массовой информации Республики Башкортостан
Государственное унитарное предприятие Республики Башкортостан Издательский дом "Республика Башкортостан"

Фаил Камил улы ФӘТХЕТДИНОВ
*баш мөхәррир*

**Мөхәрририят**

Илдус Фазлетдинов *(баш мөхәррир урынбасары),* Мөнир Вафин, Дилбәр Булатова *(бүлек мөхәррирләре),* Лиана Нигъмәтҗанова *(бизәлеш мөхәррире)*

**Редакциянең адресы**

450079, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Октябрьнең 50 еллыгы урамы,13, 612нче бүлмә.
450079, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. 50-летия Октября, 13, комн. 612.
электрон адрес: tulpar.06@mail.ru

**Телефоннар:**

(347) 272-13-61 – *(баш мөхәррир),* (347) 272-67-48 – *(баш мөхәррир урынбасары, иҗади бүлекләр)*

**Нәшер итүче:**

Башкортстан Республикасының "Республика Башкортостан" Нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе
Типография: Башкортстан Республикасының "Республика Башкортостан" Нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе филиалы – "Башкортостан" республика нәшриятында басылды.
450079, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 13

**Издатель:**
Государственное унитарное предприятие Республики Башкортостан Издательский дом "Республика Башкортостан"
450079, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. 50-летия Октября, 13

**Типография:**
Отпечатано в типографии Республиканского издательства "Башкортостан" – филиала ГУП Республики Башкортостан Издательский дом "Республика Башкортостан"
450079, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. 50-летия Октября, 13

Журнал Русия Федерациясенең элемтә, информацион технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә федераль күзәтү хезмәтендә (Роскомнадзор) 2017 елның 27 гыйнварында теркәлде. Теркәлү саны – ПИ № ФС 77-68473.

Журнал зарегистрирован 27 января 2017 года Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций. Свидетельство о регистрации ПИ № ФС 77-68473.

Республиканский молодежный журнал "Тулпар" издается на татарском языке один раз в два месяца.

Индекс: П 2715.

Кәгазь форматы 60х84 1/8, күләме 11 шартлы басма табак; 12,67 нәшер-хисап табак. Заказ № 2.0190.23. Басарга кул куелды: 06.10.2023. Нәшер ителде 17.10.2023. Тираж – 1704 данә. Сатуда бәясе ирекле.


Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Авторлар фикере мөхәрририятнекенә туры килмәскә дә мөмкин.



*Күп тә үтмәде, аэропорт каршына чем-кара автомобиль килеп туктады .......5 бит*



*"Туймазы хәбәрләре" газете каршындагы "Алтын башак" әдәби берләшмәсе төзелүгә 90 ел тулды..................................26 бит*



*Элина тугач, Ильяс үзгәрде. Юк, кызын ул үлеп яратты, ә минә Айгөлгә генә бик нык салкынайды...........................................44 бит*



*Диңгез белән сөйләшә алмыйм бүген, ул мине тыңларга да әзер түгел, кәефе юк, ул да, минем кебек, җанына тынлык таба алмыйдыр инде.........................................54 бит*

БУ САНДА:


*Шигърият*
Илдар ХАФИЗОВ
Мәхәббәтем, гүя көзге чәчәк –
Вакыт агышында адашкан... 2

*"Ачыш" конкурсына*
Айдар ЗӘКИЕВ
Юл чатында
*Повесть* 4

*Әдәби берләшмәләрдә*
*"Алтын башак"ка – 90 яшь!* 26

*Шигърият*
Зөлфия САФИНА
Су ташый җил кызлары... 28

*Сәхнә*
Дилә МӨХӘРРӘМ-ХӘЙРЕТДИНОВА
Руслан КИРАМЕТДИНОВ:
"Бәгырең таш булса, онытып кара" 30

*Милли оешмаларда*
Мөнир ВАФИН
Максатыбыз – халыкка мәгърифәт тарату 34

*"Ачыш" конкурсына*
Алинә САБИТОВА
Су анасы яки квадрокоптер маҗарасы
*Хикәя* 36

*"ТУЗГАНАК"*
Балалар өчен махсус сәхифә 39

*"Ачыш" конкурсына*
Гөлия ГӘРӘВА
Бүреләр өнендә
*Хикәя* 44

*Әдәби тәнкыйть*
*Дилбәр БУЛАТОВА*
Туташ Уфага кайтты 49

*"Ачыш" конкурсына*
Гөлназ НУРИЕВА
Мин башыңнан сыйпап уятырмын... 52

*"Ачыш" конкурсына*
Розалия МИРЗАХАНОВА
Диңгез һәм мин
*Хикәя* 54

*"Ачыш" конкурсына*
Марсель ИЛЬЯСОВ
Яхшы эш
Бозау эзлибез
*Хикәяләр* 60

*2023 – Русиядә Педагог һәм остаз елы*
Мөнир ВАФИН
Оясында ни күрсә, очканында шул булыр 64

*"КЫЗЫК – МЫЗЫК"*
Сатира һәм юмор 76


12+


Литературно-художественный и общественно-политический молодежный журнал на татарском языке

Издается с августа 1994 года



©, ***"ТУЛПАР", 5*** *(176) 2023*

podpiska.pochta.ru



Илдар ХАФИЗОВ

*Илдар Әнвәр улы Хафизов Кушнаренко районының Ибраһим авылында дөньяга килә. Балачактан ук матур әдәбиятка гашыйк булып үсә. Биш яшендә үк хәреф танып, укырга өйрәнә. Мәктәптә дивар гәзите өчен эпиграммалар яза башлый.*

*Бәләбәй педагогия училищесын, Башкорт дәүләт педагогия институтының тарих факультетын тәмамлый. Алты ел мәктәптә эшли. 1982 елдан бүгенгә көнгә кадәр Кушнаренко район гәзитендә төрле вазифалар башкара, соңгы 25 елында баш мөхәррир урынбасары йөген тарта. Русиянең һәм Башкортстанның Журналистлар берлекләре әгъзасы.*

*Иҗат белән ныклап Бәләбәй педагогия училищесында укыганда кызыксына башлый. "Илгизәр Гыйззәтуллин өйгә эш итеп шигырь язарга куша иде. Мәсәлән, анда тезем булырга тиеш. Әлбәттә, беренче мәхәббәт тә чынлап язуга зур этәргеч бирде", – дип искә ала ул студент елларын.*

*Шигырьләре "Кызыл таң", "Шәһри Казан. Язмыш" гәзитләрендә даими басылып тора.*

# Мәхәббәтем, гүя көзге чәчәк – Вакыт агышында адашкан...

КОМ СӘГАТЕ

Ком сәгатен борын заман
Кемнәр уйлап тапкандыр.
Ул көннәрдән бүгенгәчә
Күпме комнар аккандыр.

Ком сәгате артта калмый,
Китә белми алга да.
Әйләндереп куясың да
Вакыт җебе ялгана.

Ком сәгате тавыш-тынсыз,
Уклары юк, теле дә.
Комы агудан туктагач,
Вакыт беткән беленә.

Су да ага, ком да ага,
Ага икән вакыт та.
Яшьлегеңдә калып булмый
Сәгатьләрне ватып та.

Ком сәгатендә күренә
Вакытның тиз үткәне.
Кеше әллә ком бөртеге,
Әллә галәм тузаны...

КӨЗГЕ ЧӘЧӘК

Кай елларны көзләр җылы килә –
Табигатьнең шуклык, ялганы.
Җил-давыллар күргән агачлар да
Чәчәк атып куя алданып.

Азга гына җитә Көзсылуның
Көлемсерәп җирне назлавы.
Кинәт суыта да, салкын җилләр
Көйдерәләр чәчәк таҗларын.

Кешеләр дә шулай ышаналар
Назлы караш, җылы сүзләргә.
Күңелеңне өшетсәләр, аннан
Салкынлыкка ничек түзәргә?!

Кызганып та, сокланып та карыйм
Соңлап чәчәк аткан агачка.
Мәхәббәтем, гүя көзге чәчәк –
Вакыт агышында адашкан...

КЕМ ҖИҢҮЧЕ?

Чәмләнеп дөнья куабыз –
Нәкъ бәйгедәге кебек.
Дәрәҗә, мал, җылы урын
Эләкми, торсаң җебеп.

Башкаларны этеп-төртеп,
Чыгасы килә алга.
Өстәлгә барып өлгерсәң,
Эләгә иң зур калҗа.

Тырышабыз, тырмашабыз,
Ашыгабыз җан-фәрман.
Инде барын җыйдым дигәч,
Беткән була дәрт-дәрман.

Гомер дигән бәйгеләрдә
Шунысы иң кызыгы:
Җиңгән була иң азактан
Үткән финиш сызыгын...

ИКЕНЧЕ ГОМЕРЛӘРДӘ

Беркайчан да хисләр белән
Булмады уйнаганым.
Төннәрен дә, таңнарын да
Син идең уйлаганым.

Көнләшерлек пар булсак та
Кавышалмадык туйлап.
Бәхет янәшә иде дә,
Җитмәде аңа буйлар.

Күңелемнән җуяр идем –
Теләсәм дә булмый шул.
Сине сагынудан тора
Яшәешем, булмышым.

Сүнмәс ялкыннарда янып
Калам бит күмерләргә.
Сокланырлык пар булырбыз
Икенче гомерләрдә,
Икенче гомерләрдә...

УРТАКЛЫК

Урам буйлап каршыма эт чаба,
Күзләрендә шатлык очкыны.
Аның өчен бүген бәхетле көн –
Чылбырыннан киткән ычкынып.

Хуҗасыннан җәбер күп күрсә дә
Кешеләргә ачу сакламый.
Курыкмадым никтер мин бу эттән,
Борылмадым, туры атладым.

Миңа каршы япь-яшь егет килә,
Әллә киткән ул да "ычкынып".
Эт ашамас сүзләр авызында,
Урам яңгырата кычкырып.

Мондый бәндәләрне урап үтү
Булмыйдыр ул һич тә куркаклык.
Кайвакытта кеше белән түгел,
Этләр белән тоям уртаклык!

БӘХЕТ ЙӨРӘК ТҮРЕНДӘ

Һәрчак ачык күңелемне
Кем генә үз итмәде.
Аяк салмый түргә үтте,
Чакырганны көтмәде.

Өләштем күңел җылымны,
Ә үземә җитмәде.

podpiska.pochta.ru

Йөрәгемә йозак элдем
Кертмәс өчен читләрне.

Буш вәгъдәләр, хыяллардан
Күптән берни калмады.
Явызлык өстен еш кына,
Хаклык җиңми ялганны.

Ни өчендер бәхет безгә
Ерак булып күренә.
Ә ул әллә кайда түгел –
Йөрәгебез түрендә!

### ЯКЫН КЕШЕМ

Рәхмәт сиңа, якын кешем,
Янәшәмдә булганыңа.
Мин бәхетле, ялгыш кына
Кагылсам да кулларыңа.

Рәхмәт сиңа, төшкә кереп,
Төн йокымны тәмләвеңә.
Хыялымда минем яшәп,
Көннәремне ямьләвеңә.

Мин бәхетле очратканга
Сине тормыш юлларымда.
Зинһар өчен, ялгыш кына
Кагылсана кулларыма...

### ӘНКӘЙ САЛГАН ИКМӘК

Көнаралаш әнкәй ипи салды –
Җиде җанга ничек җиткәндер!
Һич онытмыйм, кайнар ипекәйне
Мичтән чыгаруын көткәнем.

Шуңардан да тәмле ризык белмим –
Каймак яккан авыл икмәге!
Сый-хөрмәттән өстәл сыгылса да,
Әнкәй салган ипи җитмәде.

Әйтә төсле әни моңсу карап:
Киткәнсеңме, улым, тартылып.
Ашыйсыңмы тамагың туйганчы,
Ач йөремә, торма тартынып...

Бүген инде кибет тулы икмәк,
Тәме дә юк, ләкин исе дә.
Үткән чакта шуннан әнкәй салган
Ипекәйләр төшә исемә...

### КӨЛ ӘЛЕ БЕР

Көл әле бер, дөньяңны онытып,
Сандугачлар отып сайрарлык.
Кара әле күзләрең тутырып,
Йөрәгемдә хисләр кайнарлык.

Көл әле бер, дөньяңны онытып,
Сагыш болытларын куарлык.
Боекларның күңел көзгесеннән
Моң-зар тузаннарын юарлык.

Көл әле бер, дөньяңны онытып,
Кабатланмас сихри чың булып.
Котылгысыз тарта мине һаман
Күзләреңнең тирән чоңгылы...

### ҖАВАПСЫЗ СОРАУЛАР

Безне бары үлем генә
Аерала диденме.
Шундый мәхәббәт хакында
Хыялланган идеңме.

Татлы сөю шәрабыннан
Булдымы исергәнең.
Очрашу минутын көтеп,
Газаплар кичергәнең.

Бөреләнгән хисләреңне
Чит-ят күзләрдән саклап,
Куйдыңмы соң икеләнми
Йөрәгең белән каплап?

Сорауларга җавапларны,
Белмим, кемнән соң көтәм.
Сүнгән сөю учагында
Бер куз күңелне өтә...

### ЯЗЫЛМАГАН ҖЫРЫМ ҖИБӘРМИ

Шигырьләрем матур килеп чыкмый,
Сөюне дә дөрес аңламыйм.
Күңелдәге өзек-өзек уйлар
Таң калырлык җырга ялганмый.

Ак кәгазьдән күзләремне алмый
Карап утырам бер ноктага.
Төнме хәзер, әллә таң атамы –
Минем өчен вакыт туктаган.

Нигә кирәк мондый газаплану,
Күпмегә соң тагын түзәрмен?
Ташлар идем дәфтәр, каләмемне,
Язылмаган җырым җибәрми...

### ЧЫН МӘХӘББӘТ

Мәҗүсиләр сынга табынгандай
Сиңа гына бары табынам.
Изге Мәккә кебек, кыйблам булып,
Нур саласың ярсу җаныма.

Мин өзелеп сөйгән кебек сине
Сөйгәндерме Мәҗнүн Ләйләне.
Синсез үткән көннәремне санап,
Тезәм һаман сагыш сәйләнен.

Әйтерсең дә күңелнең һәр кылы
Сиңа гына барып тоташкан.
Гүя гомеремнең һәр мизгеле
Синнән генә тора тоташтан.

Үзем теләп алган газап бит син,
Эреп югалырлык ләззәт тә.
Чын мәхәббәт шулай буладыр ул –
Үзе тәмуг, үзе җәннәт тә...

### ТӨНГЕ СЕРЕНАДА

Баш очында тәрәзәдән
Карый ярымай.
Мәче ята бөгәрләнеп,
Гүя сарымай.

Хуш ис тарала бүлмәгә
Чәчәкле гөлдән.
Телефон ала җемелдәп –
Хәбәрләр килгән.

Дивардагы иске сәгать
Икене сукты.
Шигырь язарга утырдым
Кабызып утны.

Сиңа дигән төнге җырым
Күчә каләмгә.
Бу мизгелдә тик икәүбез
Бөтен галәмдә...

### АШЫКМА СИН, КАРТЛЫК!

Вакыт җитми. Ашыгабыз
Иртән эшкә, өйгә кичтән.
Арып кайткач, һич теләк юк
Бирелергә уйга-хискә.

Акча җитми. Һәр айныкы
Кереп бетә үз аена.
Тырышабыз, тырмашабыз –
Яшәп булмый үз җаеңа.

Һәм, ниһаять, бар да җитеш,
Кирәк түгел һич артыгы.
Хисләргә бик бирелмә дип,
Бармак селки тик картлыгым...

### КАЙТАСЫҢМЫ, БАЛАМ?

– Кайтасыңмы, балам, бу атнаны,
Оныкларны бигрәк сагындым.
Токмач кисеп куйдым, бәлеш салам,
Хәл алырсыз мунча чабынып.

– Беләсең бит, әнкәй, эшләр тыгыз,
Өч катлы йорт яңа төзедек.
Шимбә көнне җиһаз китерәләр,
Мәшәкатьләр тора тезелеп.

– Бу бәйрәмдә дүрт көн ял була ди,
Кайтасыздыр инде иркенләп?
– Вакыт тимәс, дача бакчасында
Үтәр инде аның дүрте дә.

– Отпускыңда көтәм, балакаем,
Оныкларны килә кочасым.
– Көтмә, әнкәй, билет алдык күптән,
Таиландка бүген очасы.

– Нихәл, әни! Кайтырга чыгабыз,
Бүләкләрне сиңа төядек...
– Әниегез кинәт үлеп китте
Урам капкасына сөялеп...

podpiska.pochta.ru




# Юл чатында

*Повесть*

1

“Уфа” аэропорты каршына арткы тәрәзәләре караңгылатылган сары “бүрекле” такси килеп туктады. Кара “Хендай-солярис” салонынннан бер егет белән чибәркәй килеп чыкты. Икесе дә вейп[1] алып суырдылар.

– Минекендә кремлы туңдырма тәме!

– Минеке шоколадлы.

– Әйдә алышабыз?

– Әйдә!

Кырмыскалардай йөгерешкән халык шоколад я кремлы туңдырма исе килгән агулы парларны сулый-сулый, бина эченә ашыкты. Чәче заманның соңгы модасы буенча алынган, сакалын барбер оста итеп кискән, өстенә “Бриони” фирмасының шакмаклы костюмын кигән, кулына тәгәрмәчле юл чемоданы тоткан егет беләгендәге “Ролекс” сәгатенә карады. Төгәл бер сәгать вакыт бар.

– Ярар, матурым! Юлдагы кеше юлда булсын. Син бар, кайт. Сауна кер. Ял ит. Кола белән виски – шомлы уйлардан арыну өчен иң яхшы дару. Мине уйлап бетеренмә.

________

[1]*Вейп – электрон сигарет, пар җитештерүче җайланма.*

Тез өстенә кадәр ярыклы, озын зәңгәр күлмәк кигән, алтындай чәчләре шәрә иңбашына сибелгән, йомры күкрәкләренең нәкъ уртасында алтын ярымай җемелдәгән чибәркәй сөйгәненә шоколад тәмле пар өрде дә, ике йөз мең сумлык “Гуччи” сумкасыннан айфонның соңгы моделен тартып чыгарды. Егетне кочаклап, Стив Джобсның өч шар күзле мирасына энҗедәй тешләрен күрсәтеп елмайды.

– Истәлеккә селфи. Бер елмай, матурым! Син бер ай Нью-Йоркта булганда, йөзеңне күреп куанасым, сагынганда айфонны булса да кочаклап ятасым килә...

– Айфонны кочакласаң кочакла, берәр егетне кочаклый күрмә.

Калын иреннәре белән май кояшы сыман елмайган чибәркәйнең йөзен кара болыт каплады. Үзе дә сизмәстән, автомат рәвештә сумкасыннан сигарет алып кабызды. Ясалма озын тырнаклы нәзек бармаклары белән тотып, аны тирән итеп суырып, кардай ак тешләре арасыннан агулы төтен өрде.

– Ташладым дигән идең...

– Син дә. Тупас шаяртмаска сүз биргән идең...

– Миңа да берне бир.

podpiska.pochta.ru

Кыз дәшмичә генә егеткә тәмәке кабын, яндыргыч сузды. Икәүләп көйрәттеләр.

– Мин бит шаярттым гына. Син чынга алдың.

Кыз аркасы белән борылды. Егет аны нәзек биленнән кочаклап, аккошныкыдай муеныннан үпте.

– Ачуланып калма, матурым! Барып җиткәч хәбәрләшербез. Сау бул!

Егет яртылаш тартылган тәмәкесен чүп савытына селтәп, аэропортка кереп китте. Кыз тәмәкесеннән аерыла алмады. Аны фильтрына кадәр тартып бетеп, бармагы пешкәч кенә чүп савытына ташлады. Уянып киткәндәй, як-ягына каранды. Янәшәдә, итәгенә ут капкандай, ашыккан халык йөгерешә иде. Калтыранган куллары белән айфонын алды.

– Такси. Аэропорттан “Хилтон” кунакханәсенә.

Янә бер тәмәке алып кабызды. Тартуын ташларга омтылган мәле иде. Җитте. Болай да какшаган сәламәтлекне күпме какшатырга була. Тагы ычкынды. Никотинны вейп парларына алыштырырга күнегеп кенә килә иде. Бер атна вакыт үтте. Вәт, кабахәт нәрсә! Тәмәкедән бармаклар, тешләр саргая. Теш табибына, агарттырырга йөрергә кирәк. Иртән торуга авыз сасый, баш авырта, укшытып ютәлләтә. Тик нервларны, аның нервларын шушы үлемечле агудан да тизрәк тынычландыручы юк.

Әллә шәйли микән? Юктыр! Төнен кулыннан бер эш тә килмәгән бәндә нәрсә шәйләсен инде. Кичен үзенең шәүләсеннән дә курка ич ул. Акчасы булмаса, бер көн дә түзмәс иде. Хәзер, сава-сава да котыла аңардан. Башка калын кесәлене таба. Яландагы күбәләк сыман, бер чәчәктән икенчесенә кунып, ирекле гомер итә. Ахыр чиктә берәр чәчәктә тукталырга туры килер килүен. Яшь чакта туйганчы типтереп, теләгәнен ашап, теләгән киемен киенеп, теләгән чит илгә сәяхәт итеп тә каласы килә.

Табигать аңа аң-фикерне кызганган. Тугызынчы сыйныфны чак тәмамлады. Аның каравы, гүзәллекне мулдан бирдән. Әдрән диңгездәй төпсез, яфрак сыман зур яшькелт-зәңгәр күзләр дисеңме. Алмадай йомры күкрәкләр, яшь каендай зифа буй-сын дисеңме. Яше дә, карты да, балавызга ябышкан чебеннәр сыман киләләр дә кабалар. Бер күз сирпеп карау, энҗедәй тешләре белән җемелдәп бер елмаю җитә. Тик яшьлек мәңгелек түгел шул. Ямьле җәйдән соң, салкын көз җиткән сыман, аның да ахыры бар. "Тиң-тиң". Айфонына хәбәр килде. “Сезне А452БЗ номерлы ак “Рено-Логан” автомобиле көтә”.

Салонга кереп утыру белән, айфонын кулына алды да, ватцапптан хәбәр язарга кереште: “Ботаникны озаттым. Кил, минем айгырым! Көтәм сине!” – дип, йөрәк сурәтләре җибәрде.

Егет, ишек алдында тикшерү үтеп, аэропортка керде. Уфа – Мәскәү рейсының билетын ерткалап, беренче очраган чүп савытына ыргытты. Автоматтан каһвә алып, буш урынга барып утырды.

“Хөрмәтле пассажирлар! “S7 Эйрлайнз” авиакомпаниясенең Мәскәү рейсына утыру башлана. Бөтен пассажирларны да чыгу урынына килергә чакырабыз. Хөрмәтле пассажирлар...”

Кат-кат яңгыраган игъланга игътибар итмичә, айпадын чыгарды. Кул җылысыннан эшләүче сенсорлы төймәләргә баскалап алды. Җан кергән экранда бер төймәгә басты.

**АВТОРДАН**



Айдар ЗӘКИЕВ

*Кайчан һәм кайда туууым, биографиям “Тулпар”ны даими алдыручыларга таныштыр. Чөнки яраткан басмам белән егерме елга якын хезмәттәшлек итәм. Башкалар кызыксына калса, кирәкле мәгълүматны иксезчиксез Интернет челтәреннән табарга була. Шуңа күрә, игътибарны кызуы да китмәгән, яңа гына табадан төшкән әсәргә юнәлтү дөресрәктер.*

*Әсәрнең сценарие салкын кышта төзелеп, кызу җәйге айларда язылды. “Нәрсә турында язасың?” – дип сорады компьютер каршында утыруымны күргән хәләлем. Кызым белән улым да кызыксындылар. Сорауны үз-үземә дә бирдем. Авылдан чыгып китүемә егерме елдан артык вакыт үткән. Авыл тормышын тасвирлап, төбенә тоз коеп язар өчен анда яшәргә, авыл халкының бүгенге хис-тойгыларын, уй-кичерешләрен энәсеннән җебенә кадәр белергә кирәк. Кунакка кайтып кына моңа ирешеп булмый. Моңсу хатирәләргә нигезләнеп кенә шаккатырырлык әсәр язу мөмкин түгел. Шәһәрдә эшлим, шәһәр янында яшим. Әмма уфалыларның баштан ашкан мәшәкатьләрен дә белеп бетермим. Димәк, вакыйгалар шәһәрдә барса да, язарга җиңел булмаячак. Әсәремдә вакыйгалар шәһәр белән авыл арасында бара, дисәм, ялгышмам.*

*Идея, сюжет нигезе юлда туды. Хәләлем белән икебез дә бер яктан. Туган якларыбызга “Урал” М-5 юлыннан кайтырга туры килә. Анда төзекләндерү эшләре дәвам итә. Унышар чакрымнарга сузылган “бөке”ләрдә утырылды, вакытлыча юллар ябылу сәбәпле, урау юллар үтелде. Шундый мизгелләрдә, вакыт үткәрер өчен тирә-якны, янәшәдәге авылларны күзәттем. Киңәйгән, иркенәйгән юллар аларның язмышын да үзгәртми калмады. Берничә йорт кына күренгән, бушап калгандай тоелган бер авылны әсәремдә Ак Чишмә авылы итеп алдым.*

*Вакыйгалар – уйдырма. Ә менә кайбер геройлар – чынбарлыктан, студент елларымнан. Мөгаен, кайбер дус-ишләрем аларда үзләренең чалымнарын таныр. Бары тик яхшы сыйфатларын, яхшы якларын гына алдым. Иманым камил: үпкәләмәсләр.*

*Әсәремне язышканнары, илһам биргәннәре өчен Ришат Төхвәтуллин һәм Алия Карачурина, Әнвәр Нургалиев, Айдар Галимов, Гүзәл Уразова, Илмира Нәгыймова, Фирдүс Тямаев, Филүс Каһиров һәм татар эстрадасының башка йолдызларына, аларның хисле, күңел чоңгылларына үтеп керердәй җырлары, моңлы тавышларына рәхмәтлемен. Әлбәттә, алар янәшемдә җыр башкарып утырмадылар. Әсәремне язганда, колакчада аларның җырлары уйнады. Ничек шулай килеп чыккандыр – үзем дә аптырашта. Җыр тыңлап әсәр язарга мөмкинмени? Мөмкин икән.*

*Быел күптәнге хыялым гамәлгә ашты. Туймазы районының Карамалы-Гобәй авылында Ришат Төхвәтуллин оештырган “Җәйге очрашулар – 2023” хәйрия концертында булу да иҗат киеренкелеге, рухи күтәрелеш бирде. Чарага алып барганнары өчен баҗа белән балдызга рәхмәтләрем чиксез. Бу вакыйганың җете мизгелләре әле булса күз алдымнан китми, анда яңгыраган җырларны, үзем дә сизмәстән, эчтән генә көйләп йөрим.*

*Кулымнан урысча-татарча сүзлек, татар теленең орфографик сүзлеге төшмәде. Моңарчы әдәби әсәрләрдә очрамаган сүзләрне кулланганда тәрҗемәчеләргә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Уртак көч белән җиңдек шикелле. Ничек килеп чыккандыр – анысын бары тик син, укучым, гына әйтә аласың. Дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп, смартфоныңны тавышсыз режимга куеп, каһвә я чәй ясап ал да, уңайлы урынга утырып, иҗади дөньяма рәхим ит әле!*

podpiska.pochta.ru

"Ботаникны озаттым. Кил, минем айгырым! Көтәм сине!"

Йөрәгенә хәнҗәр булып кадалучы чәнечкеле сүзләрне тыныч кына укыды. Агарынмады да, кызарынмады да. Йөзендә бер нерв кылы да, бер күзәнәге дә селкенмәде. Әйтерсең лә кояшның иртән чыгып кичен баюын күзәтте. Әйтерсең лә шулай булырга тиеш иде. Янә бер төймәгә басты. Банк карталары килеп чыкты. "Тинькофф", "Альфа-Банк", "Сбер"... "Уралсиб" картасына керде. Анда булган 187 мең сумны "Мир" картасына күчерде. Шул мизгелдә генә юка ирен читеннән сизелер-сизелмәс кенә елмаю йөгерде. "Типтерергә яратасыз икән, типтерегез. Минем исәпкә түгел, үз кесәгездән". Сөяркәләр... Сезнең заман үтте. Мөгаен, Отелло бүген яшәсә, Дездемонаның гомерен өзү түгел, тырнак очы белән дә кагылмас иде. Чөнки бүгенге технологияләр кешенең һәр адымын күзәтергә, тын алышына, йөрәк тибешенә кадәр тыңларга, тикшерергә мөмкинлек бирә. Әйтик, кайда икәнлегең турында сүз боткасы белән әңгәмәдәшеңнең колагына озын токмач элә алмыйсың. Кайда икәнлегеңне геолокация онлайн ачып салачак. Монысы айсбергның очы гына. Компьютерны биш бармагыдай белүчеләр генә кулланган күзәтү, телефоннарны тыңлау ысуллары алдашу, икейөзлеләнү үсентеләренең тамырына балта чаба ала.

Күп тә үтмәде, аэропорт каршына чем-кара "Тесла" автомобиле килеп туктады.

– Кая юл тотабыз, шеф?

– Караидел елгасы янәшәсендәге вертолет мәйданчыгына.

Бераздан һавага яшькелт төстәге, сыртына "S7 Эйрлайнз" дип язылган, 235 пассажирлы лайнер күтәрелде. Тимер кош, борылыш ясап, болытлар арасында сөттәй ак эз калдырып, Мәскәүгә юнәлеш алды. Нью-Йоркка очасы егет утырган "Тесла" Караидел елгасы ярындагы күпер янәшәсенә килеп туктады. Тиздән мәйданчыкка биш урынлы, тәрәзәләре караңгылатылган "Робинсон R66" вертолеты килеп төште. Пилот янәшәсенә бердәнбер пассажир утырган куәтле очкыч, гүелдәп, һавага күтәрелде. Тирә-якта тузан тузды, үләннәр җиргә үк ятты. Яшеллеккә күмелгән, кырмыскалармыни кешеләр чабышкан, машиналар елгасы дәрья булып ташкан Уфа озатып калды.

Нәкъ шушы мизгелдә шәһәр читендә, урман арасында урнашкан "Граф Монте-Кристо" ял йортында бәйрәм кызганнан-кыза гына иде.

*Только... рюмка водки на столе...*

Исерүе җиткән ирләрнең нәсел үгезләредәй мөгрәгән тавышлары, кемузардан микрофоннан җикерүләре киек кошларны сискәндерде. Алар, сайрауларыннан туктап, пырхылдап һавага күтәрелде. Тирә-якка куырылган ит исе, сүгенү сүзләре, берсен-берсе бүлдереп сөйләргә тырышкан көр тавышлар, буш шешә зыңгылдаулары ишетелде. Караңгылык пәрдәсен ертып, ерткыч күзедәй ике ут көлтәсе килеп чыкты. Ике ир-ат машинадан берсеннән-берсе купшы, берсеннән-берсе чибәр ике кызны сөйрәп чыгарды. Кыска итәкләрен тезләренә таба тарткалап, биек үкчәле туфлиләрендә, сынып китәрдәй шырпы кадәре генә нәзек ботларында калтыранып торган чәчбикәләр кая килеп эләккәннәрен, аларны нәрсә көтәсен башларына да китерми иде. Алар, яклау эзләп, үрдәк бәбкәләремени, бер-берсенең куенына сыенды.

Төн күбәләкләрен күргән исерекләр айнып китте. Аракыларын шешә борыныннан эчә-эчә сызгырырга, маймыл сыман үрле-кырлы ыргырга тотындылар. Кемдер куеныннан пистолет чыгарып, берничә тапкыр һавага атты. Төнге йокысына әзерләнгән битараф урманны кызларның җанөзгеч тавышлары яңгыратты. Тик бу коточкыч төндә шайтан суыннан кешелек сыйфатларын югалтып, хайван дәрәҗәсенә төшкән бәндәләр кулына килеп эләккән ике гаҗиз җанга ярдәмгә килүче юк иде. Кайдадыр ябалак уһылдап куйды да ерактa этләр өрде.

**2**

Август быел коры килде. Яңгырга өмет юк иде. Айга якын тамчы да төшми. Тау түбәләре корып, саргаеп бетте. Дымга сусаган агачларның яфраклары бик иртә саргая башлады. Анда-монда йөргән мал-туарга инеш буйларында, сазлы урыннарда гына сусыл үлән калды. Мәскәүне Урал арьягы белән тоташтырачак "Урал" М-5 трассасын төзекләндерүнең кызган мәле иде. Эшләр тәгәлләнгәч, Мәскәүдән Рязань, Пенза, Самара, Уфа аша Чиләбегә бик тиз барып җитәргә мөмкин булачак.

Ил йөрәген, кан тамырларыдай, башка төбәкләр белән тоташтыручы юл кечкенә Ак Чишмә авылы янәшәсеннән дә үтә иде. Киңәйтелгәч, юл чатында урнашкан авылга килеп үк җиткән. Мондый күршелекне кабул итәргә теләмәүчеләр күрше-тирә авылларга күченгән. Буш йортлар, каралты-кура арасында нибары бер йорт кына торып калган. Анда бер ялгыз бабай гына яши.

Расих карт көн саен, этен ияртеп, авыл сыртын буар еландай ялап үткән асфальт юлны атлап үтә. Юл салучылар монда булганда, янәшәләреннән китмәде. Ялгызлыктан тәмам гарык булгангадыр, ахры. Танышып алды. Иртәдән кичкә кадәр шулар арасында буталды. Алар белән бергә ашады, ләчтит сатты. Берничә тапкыр мунча да кертте үзләрен. Тегеләре, истәлеккә төнен ябып тора торган өс киеме, каска бүләк итеп, Самара ягына юлланып, эшләрен дәвам итте. Бабай янә ялгызы торып калды.

Бүген дә юл читеннән атлый. Кулына шомарып беткән тал таягы тоткан. Янәшәсеннән, койрыгын болгап, җирән эте ияргән. Өстенә озын җиңле яшькелт күлмәк, каеш белән буылган кара чалбар кигән. Ап-ак чәчләре, печән чүмәләседәй бер якка авышып, иңбашына сибелгән. Сакал-мыегы җитеп, ияген узган. Кыш бабай диярсең. Нәрсәдер эзләнә, карана. Монда төрле табылдыкларга очрый. Беркөнне бер фура кырын яткан. Водитель йоклап киткән. Басуга баскетбол тубы кадәре карбызлар тәгәрәгән. Башка водительләр йөк машинасын юл өстенә чыгарыштылар. Расих карт та шунда буталып йөрде. Водительгә эчәр су, икмәк-сөт китерде. Төнен йоклар урын да тәкъдим иткән иде.

– Вакыт – алтын. Бәрелгән карбызларны кибет нокталарына илтүдән файда юк. Чәчелгән карбызлар синеке, Расих карт, – дип, көрәктәй кулын бирде дә сәфәрен дәвам итте Дагстан егете.

Расих карт өч көн ташыды. Мунча алды, өй алды, абзар, ихата карбызга тулды. Көн озыны карбыз ашап,

podpiska.pochta.ru

эче күпте. Кәҗәләр дә затлы ризыктан авыз итте. Күпме яшәп тә, үз гомерендә бу кадәр карбыз ашаганы юк иде.

Бүген дә Байкал, нидер сизенеп, һау-һау өреп, юл читенә төшеп китте.

– Байкал! Байкал!

Бераздан эт үлән арасыннан килеп чыкты да, бабай алдына ике телем икмәк арасына кыстырылган колбаса китереп салды.

– Байкал, молодец! Сыйларга теләвеңә рәхмәт! Үзең аша!

Шуны гына көткәндәй, эт тузанда яткан ризыкны күз ачып йомганчы кабып та йотты. Чәйнәп тә тормады. Бүгенге табыш һуш китәрлек түгел иде. Анысына да риза. Этне ашатасы булмады. Бабай таяк таянып, юл читендәге сукмактан төшеп китеп, куаклар арасында югалды.

Төн иде. Расих карт Байкал абалап өрүгә уянды. Сәгать ничә? Төнге дүрт. Акылдан шашканмы бу эт? Әллә колбасага котыртучы дару кушылганмы?

– Я инде, я. Тынычлан. Я!

Байкал гүя хуҗасын ишетмәде. Әрле-бирле боргаланды, бөтерчек сыман бөтерелде, арткы аяклары белән җирне тырнады. Расих ихатаны урап чыкты. Капка бикле. Кәҗә абзары ябык. Тавыклар куначада. Йорт ишеген тарткан иде, Байкал янә өрергә кереште.

– Бүген мине йоклатмаска уйлагансың, ахры. Этләр телен белмим. Шулай да синең белән аңлашырга тырышырмын.

Бабай этне башыннан сыйпамакчы булды. Эт читкә сикерде. Үзе өрүдән туктамады. Капкадан чыкты. Бабайны ияртеп, юл чатына алып китте.

Юкка өрмәгән икән. Юл чатында коточкыч авария булган. Шуны сизгән. Ике джип бәрелешкәннәр. Берсе юл астында ята. Икенчесе – юл өстендә. Багананы кочаклаган. Алды бөтенләй юк. Кисеп алганнар диярсең. Руль артында бер ир. Теле көрмәлә. Бәйләп сүзен әйтә алмый. Алдарак бер җансыз гәүдә ята. Тагын берсе авыр хәлдә. Тирә-як пыяла ватыкларына тулган.

Юл астына төшеп карады. Водитель урыны буп-буш иде. Ул арада ашыгыч ярдәм машинасы килеп туктады. Үткән водительләр туктап, ыңгырашкан ирләрне микроавтобуска салырга ярдәм итте. Берсенә ярдәм кирәкми иде инде. Аның гомере юл чатында өзелгән.

– Сез монда беренче килдегезме? Кайчан булды бу хәл? Сәгать ничәләрдә?

Юл инспекторлары документ артыннан документ тутырып, сорау артыннан сорау яудырып, Расих картның теңкәсенә тиеп бетте. Аякларын көч-хәл белән сөйрәп, таң атканда гына салкын ястыгына кайтып ауды. Күз кабакларын йомып, йоклап киттем генә дигәндә, Байкал тагын телгә килде. Трусиктан гына тышка чыкты. Салкынайткан. Ихатаны келәм урынына басып алган бәбкә үләненә күз яшедәй чык төшкән.

– Җитәр инде. Хет чүт кенә йокларга бир. Юләрләндеңме әллә?

Байкал, койрык болгап, хуҗасы алдына килеп утырды да, абзар ягына юнәлде. Бабай ишекне бикләп, йокларга кереп ятты. Эт артыннан иярергә теләге дә, рәте дә юк иде.

Ул арада койма ышыгында сизелер-сизелмәс кенә бер шәүлә селкенде.

**3**

Авыл кешеләренә хас булганча, Расих бабай беренче таң нурлары белән торды. Өйдә салкынча иде. Караватастыннан тапочкаларын алып киде. Чәй куйды. Суыткычтан ике йомырка сытып, чажылдаган табага салды. Барысы да әзер булгач, тамак ялгарга утырды. Битен юып, тешен чистарткач, тышка чыкты. Анда эш баштан ашкан иде. Кызыл итекле әтәч тавыкларын ияртеп, тибенеп йөри. Абзар ишеген ачып, кәҗәләрне урамга чыгарды.

– Машка! Исән-имин йөреп, тәмле сөт җыеп кайтыгыз, яме!

Мүкләк кәҗә баш каккандай итте. Кәҗәләр көн саен таң белән чыгып китә дә, кичен генә урап кайта. Машкага биш яшь. Калганнары аны тыңлый. Артыннан тамчы да калмыйлар. Кая барса, шунда баралар. Көн озыны болыннарда, тау битләүләрендә йөртеп, кичен исән-имин ияртеп алып кайта. Үзенчәлекле исе булса да, кәҗәнең сөте дә, каймагы да, эремчеге дә бик шифалы. Исенә дә, тәменә дә күнекте. Аның каравы, атлаган саен  күрше авылга, кибеткә чабасы түгел. Җитештергән ризык бер картны ашатырга җитә. Тавыкларга келәттән алып бер коштабак җим сипте. Алар алтын бөртекләредәй ашлыкны бәбкә үләне арасыннан эзләп чүпләргә кереште. Ул арада күгәрченнәр, чыпчыклар җыелды. Бабай кумый аларны. Бушап калган Ак Чишмә авылын ямьләп торучылар бит алар. Кошлар да китсә, бөтенләй күңелсез булачак. Ашасыннар. Җим җәл түгел. Ояларында, соры томшыкларын югары күтәреп тилмереп көткән кошчыкларына алып кайтсыннар, үрчесеннәр. Кем белсен, бәлки, заманалар үзгәреп, авылга янә җан керер. Һәрбер йортның үз күгәрчене, үз чыпчыгы булса, авыл тагын да ямьләнер.

Бабай, күнеккәнчә, үле авыл буйлап сәяхәткә чыкты. Монда аңа һәр таш, һәр агач таныш. Шушы урамнарда яланаяк йөгереп, төннәрен кунак кызларын сутлы алмалар белән сыйлап үсте. Алмалы бакчаларны хәзер кычыткан, әрекмән баскан. Туры зиратка барды. Урман басып килә иде аны. Күпләр, якыннарын җирләгәч, кабер өстенә нарат, имән, чыршы утыртты. Агачлар үстеләр, орлык чәчеп, тагын да үрчеделәр. Зират үтә алмаслык карурманга әверелде. Ел саен, май бәйрәмендә мәрхүмнәрнең  балалары, оныклары, туруннары кайтып, корыган агачларны кисте, кипкән чүп үләннәрен җыеп түкте. Өмә гөрләп торды. Калган чорда килүчеләр берән-сәрән генә. Бүген дә, зират буш иде. Беркем дә юк. Кайдадыр сандугач сайравы гына ишетелә. Әти-әнисенең каберенә барганда, аны бакыйлыкка күчкән авылдашларының таныш йөзләре озата барды. Һәрберсенең йөзе генә түгел, ләкабе дә, килеш-кыланышлары да, сөйләшүләре истә. Ябалак Филүс, Козгын Рәдиф, Аю Радик, Талпан Шамил....

Әти-әнисенең каберләренә килеп җитте. Кабер өстендәге чүпләрне утады, саргайган фотоларына карап, бераз тын торды. Гомерләре озын булмады шул. Икәүләп авыл фермасында эшләделәр. Табигать ярата иде. Берсендә, көтү көткәндә, Расих тал чыбыгын кылыч итеп, чәчәкләрнең башларын өзәргә кереште. Әтисе орышмады. Карап торды-торды да янына дәште.

– Улым! Җирдә беркем дә мәңгелек түгел. Бакыйлыкка күчкәч, җаннары янә җиргә төшә. Кем – күбәләк кыяфәтендә, кем – чәчәк булып. Бәлки, шушы болын чәчәкләре кемнәрнеңдер җаннарыдыр? Алар синең

podpiska.pochta.ru



турында нәрсә уйлый микән... Кайчан да булса, шушы чәчәк урынында мин әниең булачагын онытма...

Шуннан бирле чәчәкләргә тимәс булды. Башка малайлардан да саклады. Җир шарын мәш китергән ковид әтисен аямады. Бер айдан әнисе дә бакыйлыкка күчте.

Зираттан чыгып, чишмәгә барды. Кайчандыр гөрләп аккан чишмәнең тонык тавышы гына ишетелә. Хәтерендә, авыл киленнәре, көянтәләренә чәчәкле чиләкләрен асып, су юлына чишмәгә килә иде. Нәзек билле киленнәрне күзәтергә була малайлар белән тау сыртына менә иде. Ә хәзер көмеш сулы чишмәнең моңлы җырлары чүп астында калган. Бабай, көн саен килеп, чишмәгә юл ачарга тырыша. Өстенә өелгән тау-тау чүп өемнәрен, корыган агач кәүсәләрен актара. Эх, берәр техника булса! Колхоз юк шул хәзер. Техникасы да таралып, тузып бетте. Биналарыннан хәрабәләр генә торып калды. Әнә, кайчандыр малтуар тулы ферманың нигезе генә серәеп утыра. Контор бинасының тәрәзәләрен ватып, шиферларын сүткәннәр. Халыкны өмәгә җыясы да бит. Беркем дә юк шул. Челтерәгән тавыш килсә дә, чишмә үзе күренмәде. Ишетәсеңме, чишмә? Барып җитәчәк Расих кайчан да булса синең яныңа. Улак куячак, төшәргә баскычлар ясаячак. Халык, чират торып, чишмәгә суга киләчәк. Валлаһи, теләгенә ирешәчәк.

Авылны әйләнеп кайтты. Байкал күренмәде. Кайда йөри микән зимагур? Сәнәк алып, кәҗәләрнең астын чистартырга абзарга керде. Керсә... Сәнәге кулыннан төшеп китте. Почмакта, печән өеме өстендә Су анасы ята иде. Чыннан да, Су анасы. Тукай әкиятендәгедәй. Анадан тума шәрә. Җирән бөдрә чәчләре мул күкрәкләрен каплаган. Исәнме? Тереме? Кем? Карт, ике аягыннан чөй белән җиргә кадаклап куелган сындай катып калды. Тыны кысылды. Йөрәге кабыргаларын җимереп чыгардай дөпелдәде. Әллә мондый гүзәллекне күрүдән, әллә куркудан, әллә хәйран калудан. Аяк очына басып кына, чибәркәй янына килде. Бармакларын борын астына якын китерде. Тын ала. Исән. Димәк, каршында мәет түгел, тере кеше ята. Хет бер яхшы яңалык. Ниһаять, үзен кулга алып, йортына керде. Ак җәймә алып чыкты. Өстенә капларга иде исәбе. Чыкса – Су анасыннан җилләр искән. Күзләрен уып, янә карады. Өрәк булдымы әллә? Әллә ул йоклыймы? Беләген чеметте. Авырта. Кабырга арасын ниндидер очлы нәрсә чәнчеп, уй дөньясыннан янә Җиргә кайтарды.

– Сез кем буласыз? Мин кайда? Кайда минем киемнәр?

Су анасы сәнәк белән кизәнде. Бабай сорауларга җавап бирә алмады. Чөнки белми иде. Башын читкә борып, ак җәймәне сузды.

– Мәгез.

Кыз үрелгән иде, хәлсезләнеп авып китте. Сәнәк кулыннан шуышып төште. Бабай аны тотып калды. Кулы очраклы гына билен кочты.

– Кагылмагыз миңа... Карт башыгыз белән. Оятыгыз бармы?

Бабайны этеп җибәргән чибәркәй янә җиргә тәгәрәде. Тезләнеп, ак җәймәне өстенә урады.

– Әйдәгез... Өйгә керик.

– Миңа якын килмәгез!

podpiska.pointa.ru

– Килештек. Якын килмәм. Әйдәгез!

Кыз диварга тотынып басып, ихатага чыкты. Абзар беткәч, ары китә алмады. Бабай кулын сузды. Оятын онытып, горурлыгын читкә куеп, бабайга таянырга туры килде. Башка чара юк иде. Аяклары атларга теләмәде. Алар гүя камырдан әвәләнгән. Теләсә теләмәсә дә, бабайның көчле иңбашына таянырга, аңа сырышып барырга туры килде.

– Мин Расих бабай булам.  Син кем?

– Мин... Мин...

Эчке бүлмәдә, башын мендәргә терәп утырган чибәркәй җирән башын күпме кашыса да, озын тырнакларын энҗедәй тешләре белән күпме чәйнәсә дә, бер төпле җавап та бирә алмады. Үзенең исемен дә, кемлеген дә, каян кая юл тотканын да хәтерләми иде. Менә сиңа мә! Бер документы да, телефоны да юк.

– Сусадым.

Бабай аңа су китереп бирде. Кыз йотлыгып эчте. Куллары сыдырылган. Кичәге авария исенә төште. Шул хәл белән бәйле түгел микән?

– Берәр нәрсә хәтерләмисеңме?

– Очкын... Юл... Очкын...

– Тагынниләр хәтерлисең?

– Бушлык... Караңгылык... Эчем яна. Тагын су бармы?

Бабай су алып килүгә, кыз йоклап киткән иде. Расих суны үзе голт итеп эчте. Бассын йөрәк әрнүләрен. Чал чәчен кашып, күтәрмә төбенә чыгып утырды. Байкал кайткан. Телен сәлендереп, сукмакта аркылы ята. Тигәнәккә баткан. Өтәләгән тиресеннән тигәнәкләрне чүпләргә кереште. Эт кымшанмады да. Риза булып ятты.

– Кайда йөрисең, карт ишәк! Минем башка бәла төште. Ә син әллә кайда гуляйть салдырасың? Бәлки киңәшне синнән сораргадыр? Нишләргә миңа? Я, әйт!

Байкал дәшмәде. Тамагы тук. Инештә үләксә табып, корсагы күпкәнче ашады, лач-лоч салкын су эчте. Хәзер, күләгәдә изрәп йоклыйсы килә. Койрыгын болгап, тормыштан рәхәт алып, хуҗасына иркәләнеп ята бирде. Эт тормышында шуннан да бәхетлерәк мизгелләр юктыр.

Бабай чал чәчен сыйпап, учына алып, җиргә чүгеп барган йорты алдында этен сыйпап утырган мәлдә, Уфадан М-5 трассасына, биш әзмәвер чак сыйган, тәрәзәләре бар яклап та караңгылатылган “БМВ” автомобиле чыкты. Ялтырап торган капот астындагы 450 ат көчле двигатель биш секундта спидометрда “100” санын чыгарды. Янә биш секунд үтүгә сөңгедәй очлы, кандай кызыл тел “200” санын үтеп китте. Битләрен төк баскан, күн курткаларыннан йомры мускуллары беленеп торган бәндәләр шактый ашыкты. “Корыч ат”, башка машиналарны, алар гүя туктап торгандай, җиңел генә узып Ак Чишмә авылы юнәлешенә юл тотты.

## 4

Бабай үз тормышында килмешәкләрне күп күрде. Юл чаты бит. Үткәне дә, сүткәне дә авыл өстендә ут янган бердәнбер йортка килә дә керә. Чегәннәрне сөйлисе дә юк. Уяу булмасаң, ихатаңда, йортыңда нәрсә бар, бөтенесен төяп алып китәләр. Эзләп табып кара аларны. Печән чүмәләсеннән энәне тизрәк табарсың.

Җәйге кич иде. Агачларның шәфәкъ нурында коенып, бер-берсе белән серләшкән мәле. Тынлыкны төн кунаклары бозды. Аркаларына зур сумка аскан бер егет белән кыз ишек кактылар. Өстенә ак футболка, кара бейсболка, бот төбеннән кыска джинсы шорты кигән асыл зат һәм сакал-мыегы җитү, баш очына сары панамка элгән, изүләре ачык соры күлмәкле егет.

– Чиләбеләр без. Анапага юл тотуыбыз. Якын-тирәдә кунакханә очрамады. Зинһар, бер төн генә куныйкчы. Тыйнак булырбыз,  – диделәр.

– Акчабыз юк. Җаныгыз нинди җыр  тели – шуны башкарырбыз. Бушлай! – дип, өстәде егет.

Төн уртасына кадәр гитара кылларын чиертеп, җыр җырладылар. Виктор Цойны, “Чайф” төркемен... Иләндә йокларга ризалаштылар. Чәй эчкәч, тартырга чыктылар. Карап торуга гади генә тәмәке. Агулы төтенне үпкәләренә тутыру белән, нидер сизгән иде сизүен. Исе дә ис түгел. Көйгән каен яфрагы исләре чыкты. Мунча якканда, иске себеркене мичкә ыргыткач, нәкъ шундый ис чыга. Ләкин соң иде. Күктәге йолдызлар аяк астына мәтәлде. Яшел чирәм аның битенә килеп бәрелде. Ни булганын, нәрсә  кыланганын хәтерләми. Ялгызы гына йокларга яткан Расих бабай уянганда кочагында теге чибәркәй иде. Киемнәрен ихатадан чак эзләп тапты. Эчке күлмәген, баскыч куеп, алмагач башыннан менеп алырга туры килде. Егетне бәрәңге бакчасыннан эзләп алып кайтты. Көчкә озатты.

– Гафу итегез! Ялгыш, Кара диңгезгә барып җитү хөрмәтенә көйрәтәсе тәмәкене бутаганбыз, – дип, көлеште яшьләр.

Кайтышлый кунакка керергә вәгъдә бирделәр. Бабай, аптыраулы кыяфәттә кул болгап озатып калды.

Юл чаты булгач, аварияләр еш. Юл өсте күпере инде ничәнче ел төзелә. Тик төзелешнең очы-кырые гына күренми. Авыл кешеләре, трассаны я җәяү атлап чыгарга җыенганда я иске генә машиналарында, җигүле атларында үткәндә, тәгәрмәч астына эләкте. Күпме язмышлар челпәрәмә килде, күпме җаннар күккә ашты.

Фаҗига урыннарына ясалма чәчәк бәйләмнәре белән фотосурәтләр урнаштырылган. Алар монда адым саен. Яшь кенә егетләр, чибәр кызлар, җимертеп дөнья көтәрдәй ирләр... Кемнеңдер гомере очраклы гына өзелгән. Кемнәрдер, учакка үз теләге белән очкан күбәләкләрдәй, эчкән килеш руль артына утырган. Юл чатында машиналарның туктавы, кемнеңдер учы белән йөзен каплап үксеп-үксеп елавы – гадәти хәл. Ул коточкыч вакыйгаларның шаһиты  булган тупыллар, әрвахларны искә алгандай, җил искәндә шаулапмышаулыйлар. Яңгыр, кар сулары кан тапларын юган, ачы җилләр тузанын себергән шадра йөзле битараф асфальт юл гына дәшми.

Бәладән башаяк. Су анасыннан тизрәк котылырга кирәк. Күңеле нидер сизенде. Бәлки, ул үзе алтын тарак урлап качкандыр? Көтелмәгән кунаклар килеп керүе ихтимал. Моңарчы бертөсле, талгын аккан болытлардай, акрын гына барган тормышына язмыш җилләре кискен үзгәрешләр алып килмәкчеме? Тик, үзгәрешләрнең яхшыгамы, ямангамы икәнлеген генә күзаллый алмады. Күрәзәче түгел иде. Ашыгыч ярдәм чакыртса, бөтен бәладән котылачак. Күңелендә юшкын калырлык түгел. Бәлагә тарыган юлчыны йортына сыендырды, ашатты, эчерде, кулыннан килгәнчә ярдәм итте – шул җитәр. Аңа беренче ярдәм күрсәтәчәкләр, кем икәнлеген ачыклаячаклар. Ахыр чиктә, туганнары, танышлары килеп алачак. Йортка керү белән, өстәлдәге телефонына үрелде. Ашыгыч ярдәм номерын  җыймакчы иде.



podpiska.pochta.ru

– Шылтыратмагыз, беркая да шылтыратмагыз!

– Дәваханәгә шылтыратмакчы идем...

– Кирәкми. Миңа тастымал, бер тас чиста су, чиста чүпрәк һәм зеленка бирегез. Нинди булса да киемнәр дә кирәк.

– Кем дип дәшим?

– Әлегә әйтә алмыйм. Хәтерләмим... Диана диегез. Шул исем ошый!

– Мин Расих карт булам!

Бабай түргә бер тас чиста су, ул сораган әйберләрне кертеп, тышка чыкты. Диана, чүпрәкне ерткалап, сыдырылган урыннарын чиста су белән юып алды. Аннары зеленка буяды. Яшел урыннар ут булып янды. Үзе йортны күзәтте. Алты почмаклы гап-гади авыл өе. Урам тулы шундый йортлар. Түрдә ике карават, стенка. Пыяла аша фотосурәтләр күренә. Бер үсмернең, егетнең фотолары. Карашлары Расих картныкы. Шулкадәр дә охшар икән. Мөгаен, улыдыр, бәлки, оныгыдыр. Почмактагы “Весна” телевизорына әберкәле ак җәймә бөркәлгән. Күптән эшләмидер. Тузан кунган. Кайчандыр халык хәйран калып, кинолар, тапшырулар караган “зәңгәр экран” хәзер гөлләр, гәзит-журнал куяр өчен генә хезмәт итә. Тәрәзә каршындагы өстәлдә “Тулпар” журналлары, саргайган “Кызыл таң” гәзитләре күренеп калды. Аркасындагы сыдырылган урыннарга гына буе җитмәде. Бабай ярдәм итәр әле. Өстенә шакмаклы күлмәк, ирләр спорт костюмын, футболкасын киде. Эчке киемнәрсез үзен әллә ничек хис итте. Әйтерсең дә бабай каршында анадан тума килеш басып тора. Каләм белән гәзит почмагына кирәкле киемнәр исемлеген язды. Картны кибеткә җибәрергә кирәк. Кеше төсле киенеп алса, күз күрер. Зеленканы алып, тышка чыкты.

Бабай, егетләрне дә уздырырдай булып, абзардан тирес чыгара иде. Диананы күреп, акрынайды.

– Нәрсә кирәк, балакаем?

Диана, бабайга зеленка тоттырып, аркасы белән борылып, күлмәген күтәрде. Буе җитмәгән урыннарны зеленка белән эшкәртәсе калган иде. Аркасында берничә урыннан өтеп алды. Аннан исемлек сузды.

– Шушыларын алсаң, әлегә җитеп торыр. Акчасын кайтарырмын.

Бабай башта шатланды. Иренеп йөри иде. Тоз, шырпы, көнбагыш мае беткән. Кытай токмачы, балык консервлары, сохари запаслары да кимегән. Яңа пешкән икмәк ашыйсы да килә. Азык-төлектән, көндәлек кирәк яраклардан тыш алынасы әйберләр генә янә чал чәченә үрелергә мәҗбүр итте. Эш акчада түгел. Таш Чишмә авылына барып, кибеттән хатын-кыз эчке киемнәре сатып алса, кешеләр гаҗәпләнмәсме? Бу, ким дигәндә, сәер тоелачак. Берәр очраклы хатынга дәшәргә туры килер. Таш Чишмәгә барып җитүе дә җиңел эш түгел. Биш чакрым – аның яшендә ерак ара. Велосипед бар барлыкка. Зәңгәр “Урал” велосипеды. 1993 елгы. Педаль әйләндерер хәле юк. Гараждан “Иж-Юпитер” мотоциклын этеп чыгарды. Аннан башка дөнья көтүне күз алдына китерү кыен авылда. Коляскасына төяп печән дә ташыдылар, утынны да түмәрләргә телгәләп алып кайттылар, тегермән тартырга ашлыкны да салып алып бардылар, онны шуның белән кайтардылар. Һәр йортта булмаса да, йорт саен очраган мотоцикл авыл халкына бәла-казаны да аз китермәде. Эчкән килеш мотоциклда очып, күпме асыл егетләрнең гомер өзелде, күпмесе имгәнде.

Расих чалбар балагын күтәреп, тиздән аста зур җөйне сыпырды. Июль. Таш Чишмәгә дусты белән коляскасыз мотоциклда клубка бардылар. Чибәр кызлар белән таныштылар. Озаттылар. Кайтырга чыктылар. Мотоциклның уты гына юк иде. Юлны яхшы белгәнгә тизлекне киметмәделәр. Лачындай егетләр белән чәчәк исләре алып килгән ялан җиле генә узышты. Кинәт мотоцикл борыны белән җиргә кадалды. Арткы урында утырган Расих очып китте. Дөнья әйләнде. Аппаяз зәңгәр күктә йолдызлар күз кысышты. Таштай каты җиргә килеп төшкәч, аягы авыртуга акырып җибәрде. Тимер кисәге балтырын үтәдән үтә тишкән иде. Кан фонтан булып сиптерде. Футболкасын умырып, аягын буып, канын туктатты. Шуннан, тешен кысып, аягын тимер кисәгеннән чак тартып чыгарды. Чатанлап, дусты янына килеп җитте. Дусты йөзе белән җиргә килеп бәрелеп, һушын югалткан иде. Алар төнен юл өстендә яткан төрәнгә килеп менгәннәр. Төрәнне алып, юл читенә очырды. Дустын иңбашына салып, өч чакрым җәяү кайтып, ашыгыч ярдәм машинасы чакырткан иде. Кызганыч, гаишниклар авылга килеп, йорттан йортка кереп, мотоциклларны җыеп алып китте. Беркем дә техосмотр үтмәде, исәпкә басмады. Әтисе аларныкын абзарга, печән арасына яшереп алып калды. Быел кереп тә карамады. Кабынyр микән? Күптән тотынганы юк иде. Ике тибүдә кабынды үзе тагын. Зәңгәр төтеннәр чыгарып, гөрелдәп эшләп алды. Гүя тынычлыгын бозганга орышты. Бәлки, шулай сәламлидер. Шуннан, сәгать сыман акрын гына эшли башлады. Расих карт, төтен көлтәсе калдырып, капкадан чыгып югалды. Байкал аны куа китте.

Диана капканы япты. Кинәт кенә хәлсезләнде. Чирәмгә утырды. Күз алдында ут очкыннары һәм юл сурәте пәйда булды. Юл. Төнге юл. Иксез-чиксез юл. Димәк, кул кушырып утырмаска, җавапны да юлдан эзләргә кирәк. Юл хаталарны гафу итми. Тырышларга да битараф түгел. Бәхетеңне дә, бәлаңне дә юлдан эзләп табасың. Диана, таяк таянып, шаулы һәм тынгысыз юл чатына чыкты. Алда аны нинди сынаулар көтәсен күз алдына да китермәде.

**5**

Юл чатына чак барып җитте. Ун чакрым араны үткәндәй хәле бетте. Караса, Расих бабайның йорты моннан ук күренеп тора. Кул сузымында гына.

Бер-бер артлы машиналар үтә. Юл читендә ара-тирә буш тәмәке каплары, сыра шешәләре, юлчылар ташлап киткән чүп-чар ята. Пыяла ватыклары, машина шуып барган кара эзләр, асфальтның шадра йөзендә урыны белән кара таплар. Каткан кан тамчылары. Диананың башы әйләнеп китте. Чүгәләп утырды. Күз алдыннан кино өзекләре сыман вакыйгалар йөгереште.

...Төнге клуб. Күз камашырлык утлар җемелди. Көчле музыка үзәкләргә үтеп керә. Ул бии. Каршында ахирәте бии. Аларга рәхәт...

...Кичке Уфа. Фонарьларда утлар кабынган. Бераз яңгыр яуган. Сулыш алуы рәхәт. Һава тәмле. Аны сулыйсы гына түгел, кашыклап ашыйсы килә. Гөлләмәләрдән чәчәк исе бөркелә...

...Алар тукталышта тора. Көлешәләр. Тәмәке тарталар. Исерүләре җиткән. Такси көтәләр. Кинәт кара джип килеп туктый, һәм аннан өч ир төшә...

Диананың күз аллары караңгыланып китте. Һушын

podpiska.pochta.ru

югалтса, аны дәваханәгә алып китәчәкләр. Табиблар кулына эләгергә, үзенең барлыгын белдерергә ярамый. Таякка таянып, чак торып, куаклар күләгәсендә хәл җыярга да кайтып ятарга кирәк. Хәтере кайта башлады.

Каенга сөялеп утырды. Аның ышыгында үскән чәнечкеле куаклар август аеның өтеп алгыч кояшыннан каплады. Күз башы гына иде. Үләннәр саргая башлаган. Сулып барган моңсу болын чәчәкләре, төрле төсле таҗлары белән бал кортларын, күбәләкләрне җәлеп итәргә тырыша. Кеше гомере дә чәчәк сыман гына. Бер мизгел булып үтә дә китә. Көзге усал җилләр җаныңны көлгә әйләндергәнче үз күбәләгеңне, кунасы бал кортын көтеп зарыгасың. Кемдер андый мизгелне көтеп ала алмый. Кайберәүләр, киресенчә, булганның кадерен белми. Бер күбәләк Диананың сыдырылган кулына килеп кунды. Зәп-зәңгәр төстә. Канатларында ике көрән табы да бар. Әллә аны чәчәк белән бутадымы? Бәлки, берәрсенең адашкан җаныдыр. Серләшеп булса иде шушы күбәләк белән. Канатларын сорап торыр иде. Җиңел генә, мендәрдәй кабарган ак болытлар биеклегенә күтәрелеп, теләгән җиренә очарга иде. Туган йортына. Кайда микән туган йорты? Әтиәнисе бар микән?

Каен күләгәсендә исәнгерәп утырган Диананы юл чатындагы хәрәкәт, тавыш сискәндерде.

Юл чатына кара джип килеп туктады. Аннан берсеннән-берсе озын, берсеннән-берсе таза, әзмәвердәй биш егет төште. Төштеләр дә, өзелгән муенсадай, төрле якка сибелделәр дә. Берсе нәкъ Диана янына йөгерде. Әллә күрдеме? Кемнәр болар? Торып чапса... Ике адым да атлый алмыйча сөрлегеп барып төшәчәк. Җеп өзәрлек тә хәле юк шул. Ана карынындагы баладай йомгак булып оешып, куаклар арасына посарга тырышты.

Егет Диана янәшәсенә килеп тәмәке кабызды да бушанырга кереште. Кыз аның беләгендәге аждаһа сурәтен күреп калды. Азау тешләрен күрсәтеп, тырнакларын чыгарып дошманына ташланырга әзерләнгән аждаһа. Таныш сурәт. Башы зыңлап китте.

...Тонык кына кызыл ут янган бүлмә. Киң карават. Балта элмәле тәмәке төтене. Диананы көчле куллар тоткан. Буар елан сыман кысканнар. Кымшанырлык та, тын да алырлык түгел. Аракы исе аңкыган бәндәнең беләгендәге аждаһа сурәте...

Диана янә сискәнеп китте. Аны интектерүчеләр монда нишләп йөри? Кемне эзлиләр? Бәлки, аныдыр? Кинәт, янбашын нидер ачы итеп чеметеп алды. Бот арасында, күкрәгендә, аркасында вак кына бөҗәкләр йөгереште. Кырмыска. Җирән урман кырмыскасы. Янәшәдә генә оялары булган икән. Ни кучеп булмый. Бу бәндә китәме, юкмы? Түзәр әмәле калмады бит. Аркасыннан, күкрәгеннән өтеп алырлык тешләшкән бөҗәкләрне берән-сәрән тотарга кереште һәм... Һәм ялгыш кына корыган ботакны сындырды. Шарт!

Аждаһа сурәтле егет шым булды. Тәмәкесен авызына капкан килеш Диана янына якынлашты. Ә кырмыскалар шашканнан шашты. Култык астына кереп, җилкә турыннан йөгереп чыгып, чәч арасына кереп уралдылар. Вак кына тәпиләре белән бөтен тәне буйлап йөгерештеләр, үткен тешләрен батырып, кислоталарын сиптерделәр. Гүя бөтен кырмыска оясы аның тәненә күчте. Тараканнардан, тычканнардан, елан-чаяннан гына түгел, гап-гади чебеннән дә укшыр чиктә чирканган Диана соңгы чиктә, тешен кысып түзде. Чишенеп ташлап, котыласы килде шушы бөҗәкләрдән. Мәктәптә кырмыскаларны урман санитарлары урманга, табигатькә бик тә файдалы бөҗәкләр дә дип мактадылар. Бүген биология укытучысына каршы килеп, мондый фикернең дөрес түгеллеген дәлилли ала.

– Равил! Кая югалдың? Әйттем мин сиңа, сыра чүмермә, дип. Кил әйдә.

– Нindидер тавыш ишеттем. Кемдер бар, ахры, куаклар арасында.

– Кем булсын инде. Берәр йомрандыр. Кил әйдә. Юк белән булашырга вакыт юк.

Егет тәмәкесен чиртте дә иптәшләре янына китте. Көйрәгән тәмәке Диананың каршына килеп төште. Ул аны алып суырып, бөҗәкләргә өрде. Хет шулай булса да хәлен җиңеләйтер. Үзе бөҗәкләр белән көрәште, үзе юл кырыннан килгән тавышларга колак салды. Агулы төтенне үпкәләренә тутырып, аяк астына өрде. Башы әйләнеп, рәхәт булып китте. Әйтерсең дә сусавын басты. Димәк, ул хәтерен югалтканчы көйрәткән. Талгын искән җил юл читеннән өзек-өзек тавышлар алып килде.

– Дәваханәдә юк. Мәете дә руль артында булган. Димәк, я берәр очраклы машинага утырып киткән, я күрше авылда берәр йортта посып ята. Безнең белән булган хәлләрне берәр кая тишкәнче, эзләп табарга һәм юк итәргә кирәк. Аңлашылдымы?

Кулларын уйнатып торучы егетләр баш какты да, машинага төялеште. "БМВ" язулы кара джип, зәңгәр төтен калдырып, гөжелдәп кузгалып китте.

Диана таягына таянып торып басты. Кырмыскаларны да онытты. Тиз генә кайтып җитеп, Расих картны кисәтү иде нияте. Картлар нәниләр сыман, беркатлы була. Әйтер дә салыр. Болар кулына килеп эләксә, Диана гына түгел, Расих карт та харап булачак. Аның бер гаебе дә юк бит. Кайтып киенергә дә Уфа ягына очраклы машинага утырып чыгып китәргә кирәк. Монда барыбер эзләп табачаклар. Чатанлап, чүп үскән басу аша таныш йортка ашыкты.

**6**

"Продукты" дигән язулы элекке райпо кибетендә берәү үз ноктасын ачкан. Алюмин калайлар белән бизәлгән, зур агач тәрәзәләргә тимер рәшәткәләр кагылган, түбәсендә чүп үләннәре, каен үскән бина. Ак кирпеч урыны-урыны белән кителеп төшкән. Почмагына бер бозау муенын кашып тора. Күләгәсендә сарык көтүе ята. Җилләр, яңгырлар аямаган шыксыз бинаның эче дә мактанырлык түгел иде. Азык-төлек, кием-салым берсе өстендә берсе урнашкан. Кайбер әйберләр аяк астында ауный. Хаклары да юк. Гаҗәп.

Расих кәрзингә кабы белән шырпы, сохари, икмәк, ун кытай токмачы, ике шешә лимонад салды. Аннары Дианага киемнәр эзләргә кереште. Аларны токмач тартмалары арасыннан чак эзләп тапты. Хәзер кассага барып, түлисе генә калды. Тик мөрәҗәгать итәрдәй беркем дә юк. Бер әби белән бабай. Калош сайлыйлар.

– Караны!

– Яшелне!

– Мал карарга да, кунакка йөрергә дә ярасын.

– Кем калошта кунакка йөри? Исәрләнмә. Караны ал.

Бабаеның кабырга арасына төрткәләп торган

podpiska.pochta.ru

хуҗабикә сүзен бирмәде. Йортта кем хуҗа икәне ачыктан-ачык күренеп тора. Әби – муен, әби – баш, ахрысы. Аның каравы, кибет буш. Бәлки, мондый форсаттан файдаланып калырга кирәктер? Эре-эре адымнар белән кассага килде. Тик сатучы хатынның вакыты юк иде. Каршындагы тонык кына телевизорга карап, мәш килеп, тырнак кыра. Бабайны күрсә дә, кызыл тырнак һәм төрек сериалы кадерлерәк иде. Сериалда геройлар язмышы хәл ителгән мизгел. Зәңгәр экрандагы кызу бәхәс Расих картның колагын да ертып керде. Төрек артистлары үз рольләрен һушың китәрлек, ышандырырлык башкарды.

– Миран, син миннән нәрсә телисең? Нишләптер, сине бөтенләй дә аңламыйм. Нинди максатыңа ирешмәкчесең?

– Безне үлемнән башка бернәрсә дә аера алмый. Аңладыңмы?

– Моны яхшы аңлаганга, синең күзләреңне ачмакчымын. Карарың безне үлемгә илтә. Аерылышу уены файдасыз һәм җанны телгәли. Дошманлык безгә яшәргә мөмкинлек бирмәячәк. Миңа нәрсә эшләргә? Сынауларны ничек үтәргә?

– Кызым, БСТны ач әле, бер минутка. Иртәнге яңалыкларда Ак Чишмә авылын да искә алдылар, – диде шулчак әби.

Сатучы теләр-теләмәс кенә пульт төймәсенә басты.

– Уфада егерме яшьлек студент Аэлина Рәкыйпованы эзләү дәвам итә. Ак Чишмә авылы янәшәсендә юл чатындагы авариядән соң юкка чыккан. Күрүчеләр, аның турында берәр хәбәр белүчеләр булса, шылтыратуыгыз сорала. Эзләү эшләренә Эчке эшләр министрлыгы, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре һәм волонтерлар җәлеп ителгән.

Зәңгәр экранда таныш фотосурәтне күргән Расихның кулыннан киемнәре төшеп китте. Киемнәр идәнгә чәчелде.

– Кая, ярдәм итим.

Сатучы, телсез калган бабайның әйберләрен кәрзиненә җыешты. Лифчик, хатын-кыз эчке киемнәре, джинсы чалбар, күлмәк, итәк... Чәй, шикәр һәм лимон аласы бабайның җыйган әйберләре бик сәер тоелды. Җитмәсә, телевизордан нинди яңалыклар сөйлиләр. Вакыт озак үтте. Секундлар сәгатьләргә сузылды. Вакыт кына түгел, кешеләрнең хәрәкәтләре, уй агышлары да акрынайды. Сатучы касса аппаратына килеп утырды.

– Сездән 3840 сум!

Расих биш меңлек суздЫ.

– Гафу итегез! Бер сорау бирергә ярыймы?

– Мөмкин.

– Киемнәрне кемгә аласыз?

Чират торган әби белән бабай да шым булдылар. Әби, яулыгын чишеп, колагын алар ягына борып, җавапны көтте. Сорау Расихны гүя бетон идәнгә ябыштырды. Суперҗилем белән. Сорауга җавап юк иде. Алдан әзерләгән булса да, тамагына килеп утырган төерне йота алмыйча, бер сүз дә дәшә алмас иде.

– Киемнәр Кытайдан. Бер үлчәмгә зурракны алырга кирәк, диюем.

Ул арада ишектән култык астына күн папка тоткан участок милиционеры килеп керде. Өлкән лейтенант Ленар. Расих аны чак барып кочакламады. Салкын Чишмә егетен күптәннән белә иде. Уфада укытучыга укыды. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына. Күпмедер эшләп тә йөрде. Мәктәп ябылгач, участок милиционеры итеп куйдылар. Габдулла Тукай, Әнгам Атнабаев шигырьләрен яттан сөйли. Оялчан гына авыл малае. Укырга кергәнче халык каршысына чыгып шигырь сөйләргә ояла иде. Аларны университетта олпат гәүдәле опера җырчысы Марат Шәрипов артистларча сәнгатьле итеп шигырь сөйләргә өйрәтте. “Икенче курслар сезне бик тырыш, уңган, диделәр. Алар ел дәвамында йөз шигырь ятлады. Димәк, сез егермегә күбрәк ятлаячаксыз”. Моңарчы зәңгәр экранда гына күргән абруйлы шәхес каршына басып, Тукай, Дәрдмәнд, Җәлил шигырьләрен сөйләгәндә, аяк-куллары калтырады, тавышы чыкмады. Ел эчендә бер дәфтәр шигырь ятладылар. Шагыйрьләр дә килгәләде. Яшь шагыйрь Руслан Сөләйманов белән очрашуны бүген дә онытмый. Аның бер шигырен шунда ук отып алган иде.

*Авылга кайтып киләмен*
*Кояшлы көн таңында.*
*Кайтмыйча түзеп кара син,*
*Сагын, сагын, сагын да...*

Шуннан бирле Руслан Сөләймановның бөтен шигырьләрен “ВКонтакте”дан укып, лайклар куеп бара.

Кафедрада да шагыйрьләр укытты. Камил Дәүләтшин, Лилия Сәгыйдуллина, Илдус Фазлетдинов... Үзе дә шигырь язып карады. Тик аларны беркемгә дә күрсәтмәде дә, укымады да. Студент елларындагы шигырьләр дәфтәре кайдадыр югалды. Үзенең бер шигырен генә яттан белә иде. Чөнки ул нибары ике юлдан гына тора:

*Томан төшкән безнең арага,*
*Хисләр белми кая барырга...*

Аңа эшендә “шагыйрь” ләкабе тактылар. Беркөнне җитәкчеләре чакырды. Ленар шыр җибәрде. Мөгаен, эштән куалардыр? Бәлки, эттән алып эткә саладыр. Ләкин полковник тыныч иде. Гаҗәп!

– Син шигырьләр сөйлисең. Начар гадәт түгел. Миңа хат килде. Чакыру хаты. Үзешчән сәнгать конкурсы. Беркем дә ризалашмый. Әллә кулларыннан килми. Барып кайт әле. Уфага. “Нефтьче” мәдәният сараенда сәхнәдән укырсың шигырьләреңне.

Ленар барды. Беренче дәрәҗә диплом алып кайтты. Ләкабе мәңгелеккә берексә дә, шаяртучылар бетте. Аны хөрмәт итә башладылар.

Ленар Расихның йортына килеп, кемлеген сорашкан иде. Тәпле егет. Үз эшен җиренә җиткереп башкара. Эше җиңелдән булмаса да, йөзеннән елмаюы китми. Вакытында шаулаган, даны Башкортстанны да узып, Казанны шаккатырган Камил Белый, Булат белән бергә “Уфа хәзинәләре” шаяннар һәм тапкырлар командасында чыгыш ясаган, дип сөйли халык.

– Монавы фотоны каршыңа беркет. Берәр яңалык ишетү белән, шылтырат.

Сатучы үзе участок милиционерын тыңлады, үзе биш меңлекне ваклап, бабайга сузды. Акчаларны, киемнәрне алган бабай тиз генә кибет ишегенә ашыкты. Мотоциклга утырып сыпырту иде исәбе. Тик ул уйлаганча җиңел генә килеп чыкмады.

podpiska.pochta.ru




– Туктагыз! Туктагыз!

Сатучы йөгереп чыккан. Сагызактан хәтәррәк. Бер ябышып алса, тамчы арттан калмый.

– Онытмансыз. Идәндә төшеп калган.

Бабайның кулына күкрәкчә тоттырды да кире кибеткә йөгерде. Диварда Аэлинаның фотосурәте. Кибет каршында хатын-кыз эчке киемнәре тоткан бабай басып тора. Мондый очракта җинаятьчене кулга алу өчен Ватсон кирәкми. Тортны бизәгән чияләр сыман, җинаятьче үз ирке белән бирелә. Мотоциклны кабызырга азапланганда, каршына участок милиционеры килеп басты. Велосипедта гына килгән булса! "Иж"ның көйсезләнә торган гадәте бар шул. Бер кабынмаса, икегә ярылсаң да, шартласаң да, кабынмый. Таудан түбән төшеп китеп, яки этеп кабызасы гына кала.

Ленар, тәмәке төтенен читкә өреп, шигырь сөйләргә кереште.

*Бу кешегә һәрчак нидер җитми:*
*Кара икмәк булса, ак җитми,*
*Шуышып йөргән чакта – аяк җитми,*
*Җәяү йөргән чакта – ат җитми,*
*Аты булса, машинасы җитми,*
*Очар өчен ракетасы җитми,*
*Планетасы җитми...*
*Күк җитми...*

– Атнабай...

– Нәкъ үзе.

Гүя өстеннән зур йөк төште. Димәк, озын-озак сөйләшмәячәкләр.

– Сине беренчеләрдән булып юл чатындагы авария урынына барган, дип сөйләделәр.

– Тавышка уянып бардым.

– Беренче машина руле артында студент кыз булган, ди. Мәете табылмаган. Берәр яңалык ишетсәң, шылтырат.

Телефон номеры язылган кәгазь сузды.

– Мин Салкын Чишмәдә утырам. Килеп сөйләсәң дә була. Ә мотоциклың хисаптамы?

– Юк!

– Ачкычыңны тартып алып, штраф салырга тиешмен. Ярар инде. Вадим белән бу мотоциклда аз йөрмәдек. Вакыт та, теләк тә юк. Өстәвенә, син дә яхшы кеше. Әгәр дә Уфа постовойлары авызына килеп капсаң, болай җиңел генә котыла алмассың.

Мотоцикл кабызырга азапланган Расихның куеныннан бая яшергән күкрәкчә төшеп китте. Бетте баш! Исәр баш. Ник куенга яшерергә иде? Инде җавап тотарга кирәк. Хәзер аны кулга алачак.

Ленар Расихка сораулы караш ташлады. Сүзсез дә аңлашыла. Бабай кулында булырга тиеш түгел әйберне аңлатып бирергә кирәк.

– Оныкк сораган иде. Үзе килә алмады. Авырып тора.

– Оныгың да бармыни?

– Бар. Кунакка кайткан иде.

– Ярар, алайса. Миңа шылтырат. Ул-бу була калса. Яшермә. Сер итеп кенә әйтәм. Студент кызның югалуында урындагы бер кешенең улын гаеплиләр. Аэлина-

podpiska.pochta.ru

ны нык эзлиләр. Күп сөйләшеп тормаган, акчалы һәм тупас кешеләр. Миңа килделәр. Сак бул!

Расих баш какты да, мотоцикл кабыну белән, гөжелдәп кузгалып та китте. Күзгедән күзәтте. Сатучы йөгереп чыгып, кулларын болгый-болгый, нидер сөйләргә кереште. Төшенгәннәр. Барын да аңлаганнар.

Ленар, кибет күләгәсендәге “УАЗ”ына утырып, газ педаленә басты.

Расих 1993 елгы “Иж”ында асфальттан, Ак Чишмәгә илтүче сикәлтәле юлга төшеп китте. Тәтен көлтәсе катыш тузан аша күзгедән берни дә күренмәде. “УАЗ” җитезрәк тә, куәтлерәк тә. Әгәр дә юл яссы булса. Сикәлтәле, бормалы урман юлларында мотоцикл судагы балык сыман иде. Өстәвенә, Расих “кәҗә сукмаклары”н бик яхшы белә. Яшь чагында Ак Чишмәдән күрше Таш Чишмә, Салкын Чишмә авылларына кызлар янына аз йөрелмәде. Күпме юллар үтелде, үләннәр күпме тапталды. Теңкәсенә тиеп эзәрлекләгән гаишниклардан шушы урман куенына кереп аз качмады. Бүген дә, таныш сукмактан никадәр тизрәк үтүенә аның гомере булмаса да, язмышы бәйле иде.

### 7

Шар ачык капкадан килеп керде. Мотоциклны калдырып, йортка йөгерде. Урманда, аулак урында киенер. Ашыгырга кирәк. Тырышлыгы бушка китте. Йорт буш иде. Дианадан җилләр искән. Кайда булырга мөмкин? Бәлки, берәр кая кереп поскандыр.

– Аэлина! Диана!

Җавап юк. Ничек кенә дәшмәде. Үле тынлык. Кайда микән? Чыгып киттеме? Һушын югалтып ауды микән берәр җирдә? Бәлки, абзардадыр? Чыгып карады. Бәбкә үләнендә сибелгән тавыклар җим чүпли. Абзарда этем дә юк. Ихатага чыкса... Берсеннән-берсе таза биш егет. Ленар әйткән сүзләр исенә төште. Чакырылмаган кунаклар килеп тә җиткән. Берсе мотоцикл руленда. Икенчесе коляскага кереп кунаклаган. Берсе йорттан чыгып килә. Каешына беркетелгән кобуралы пистолетны шәйләп алды. Муенында бармак юанлыгы ярымайлы көмеш чылбыр ялтырый. Расих зур өмет белән капкага карады. Күренмиме шунда “УАЗ”? Ленар! Кайда син? Дошманга тиң эзәрлекләүчесе хәзер коткаручысына әверелмәсенме? Дошманымның дошманы – дустым. Машина урынына капкадан кәҗәләр генә күренде. Машка, ят кешеләрне күреп, урынында туктап калды. Өер дә аны узып ихатага үтмәде. Көмеш чылбырлы бәндә сүз башлады:

– Хәерле кич, бабай! Гафу итегез, чакырусыз килеп кергәнгә. Ялгыш кына йортыгызга монавы чибәркәй килеп кермәдеме? – Аэлинаның фотосын йөзенә терәп үк куйды.

– Юк, егетләр! Күренмәде.

– Күрү белән, шылтырат. Шушы телефонга.

Кәгазь кисәге сузды. Коляскада утырганы, беләгенә аждаһа сурәте төшерелгәне, эчке киемнәрне башы өстендә болгап, исәр сыман көләргә кереште.

– Бабай! Болар әбиеңәмени? Әллә йортыңда эрзинкә курчак бармы? Бәлки, кәҗәләргәдер?

Шулчак тавыш яңгырады:

– Равил!

Җәелеп утырган егет, бер мизгел эчендә, юлбарыс сыман коляскадан сикереп төште. Башкисәрләр, капка төбендәге джипка төялешеп, кузгалып та киттеләр.

– Бабай сәер тоелды. Дөресен генә әйткәндә, ул бабайга да охшамаган. Нидер яшерә. Бу йортка тагын әйләнеп кайтачакбыз әле, – диде Көмеш чылбыр егетләргә.

Койма ышыгына поскан Диана, ихатага керде дә, хәлсезләнеп чирәмгә тәгәрәде. Расих аны, тәрәзәдән күреп калып, күтәреп йортка алып керде.

– Кайда йөргәнеңне тыңларга вакыт юк. Күреп торасың, сине эзлиләр. Менә киемнәр. Ишекне ябам. Киен һәм тыңла. Синең чын исемең – Аэлина. Уфада яшисең. Студент. Ниндидер төнге вакыйгалар шаһитысың. Ул бәндәләр кулына эләксәң – эшләрең харап. Хәзер киенәсең дә, такси яллап, Уфага ычкынабыз. Барып җитү белән, полиция бүлегенә барабыз. Шунда аралар өзеләчәк. Минем турыңда – ләм-лим. Полициядән әти-әниең килеп алыр...

Ихатада абалап Байкал өрергә кереште. Ату тавышы яңгырады. Эт шыңшыды да тынды. Байкал! Харап булды. Расих ярымшәрә Аэлина янына килеп керде дә, тәрәзәне ачып, бакчага бер гөлне атып бәрде. Берни дә аңлап өлгермәгән Аэлинаны кулыннан эләктереп алып, кәнәфи астындагы яшерен төймәгә төртте. Ишегалдында аяк тавышлары ишетелде. Башкисәрләр көчле куллары белән йорт ишеген ачкан мәлдә, Расих белән Аэлина лифтта идән астына яшереп төзелгән бүлмәгә төштеләр.

Аэлина үзен төштә, әкияттә, фантастик кинодагы сыман хис итте. Тормышта мондый хәл булырга мөмкин түгел иде. Һәрхәлдә, Аэлинаның моңарчы күргәне юк. Дус-ишләре белән кайда гына, нинди генә бай йортларында күңел ачмадылар. Фатир эчендәге сауналарны, өч катлы йорт түбәсендәге бассейннарны күрде. Уфа байлары халыкны шаккатыру өченниләр генә кыланмый, нинди генә башка сыймаслык адымнарга бармый. Ләкин мондый күренешне... Бәлки, Голливуд киноларында очрагандыр.

Бер мизгелдә, иске генә авыл йортыннан заманның соңгы модасы буенча төзекләндерелгән, евроремонт ясалган, диварында егермеләгән монитор җемелдәгән салкынча бүлмәгә төштеләр. Бер монитордан күл буендагы ике катлы йорт күренде. Кайберләрендә офисларда эшләп утыручы хезмәткәрләрне күзәтергә мөмкин иде. Диварда – яшь кызны кочкан чибәр егет сурәте. Егетнең йөз чалымнары, аеруча карашы, таныш тоелды. Аны кайдадыр күргән бар. Ләкин кайда? Монитордан йорт эчендә бәргәләнгән бәндәләрне дә күзәтергә, аларның һәрбер сүзен ачыктан-ачык ишетергә мөмкин иде.

– Тәрәзә аша качканнар. Ерак китә алмасалар. Берсе – карт, берсе – аксак. Хәзер, эләктерәбез качкыннарны... Эләктерәбез дә... Муеннарын борабыз...

Куркышыннан бабай кочагына сыенган Аэлина аны этеп җибәрде. Тәне кайнар, кием аша мускуллары беленде. Йөрәге дә куәтле тибә. Бабай кыяфәтле егет түгелме соң? Хәзер сакал үстерү модада. Унсигез яшьлекләр дә сакал үстерә. Ай саен барберларга, сакалханәләргә йөри. Заман башка – заң башка. Расих бабай гади бабай түгел. Ул – табышмак. Аэлина, киемнәрен киенеп, компьютер кәнәфиенә менеп, аягын аягына куеп утырды.

– Минем кемлегемне беләсең. Алай гына түгел, минем хакта миннән дә күбрәк беләсең. Вакыт җитте. Я, хәзер сөйлә инде. Кем син? Чын исемеңне әйт? Чын йөзеңне ач. Тыңлыйм. Игътибар белән тыңлыйм.

podpiska.pochta.ru

**8**

Расих карт суыткычтан ике шешә “Шихан” лимонады алды. Икесен дә ачты. Тирләгән бер шешәне Аэлинага сузды. Икенчесен борынынннан бер тында эчте. Сакалын йолкып атты, паригын салды. Бугазына беркеткән җиһазны салдырды. Күлмәген салып атты. Мизгел эчендә бабай чибәр егеткә әверелде. Нәкъ әкияттәге сыман.

– Мин Расих карт түгел. Мин – Борунсон, Вадим Борунсон. Чын исемем – Вадим Байков. “Борунсон Индустрис” корпорациясе җитәкчесе.

Аэлина лимонад эчкән җиреннән чәчәп җибәрде. Бугаздан төшкән сыекча тын юлына төште. Борунсон! Вадим Борунсон! Җимерек, челпәрәмә килгән хәтере дә бу исемне онытмаган иде. Шушы исем аның аңына гына түгел, һәр күзәнәгенә кадәр сеңгән иде. Хәтер чоңгылларыннан шушы исем белән бәйле уй өзекләре акты. Ул аны күз алдына икенче төрлерәк китергән иде. Уфаның иң бай яшь байларының берсе. Вадим Борунсон Аэлинаның хәтеренә акча, байлык, миллиардер символы буларак кереп калган иде. Ләкин ул әле бөтен нечкәлекләрне дә исенә төшерә алмады. Асылда, Вадим “Форбс” журналына кертелгән миллиардер иде. Ларри Эллисон, Илон Маск, Дональд Трамп, Билл Гейтс кебек миллиардерлар белән бер исемлектә торучы Вадим Борунсон. Уфаның иң чибәр кызлары, Аэлинаның ахирәтләре дә аны татлы төшләрендә күреп хыялланды. Чуктан-чук киенеп, бизәнеп, төзәнеп, күкрәкләрен, иреннәрен кабартып, тырнакларын убырлы карчыкныкыдай озынайтып, Вадим Борунсонны төнге клубларда, ябык кичәләрдә күзләделәр. Ятьмәдәй бөдрә  чәчләренә уратып, ерткычныкыдай тырнакларын җанына батырып, йөрәген көл итәргә иде исәпләре.

– Вадим күренсә – минеке. Якын киләсе булмагыз. Йөзегезне аркылыга-буйга умырып төшерәм.

– Һе! Сезгә борылып та карамаячак. Минем күкрәкләрне күрү белән, өнсез калачак. Аны җитәкләп, сезнең борын төбеннән алып китәм.

– Хыялланмагыз. Минем төз ботлар аны бер күрүдә аяктан егачак. Шул ботларга кагылыр өчен бөтен байлыгын каршыма җәеп салачак.

– Без Мальдив утрауларында яшәячәкбез. Һинд океанында үзебезнең яхтабызда йөзәчәкбез. Мин, гүзәл тәнемне кояш нурларында коендырып, шампан шәрабы уртлап ятачакмын...

Ләкин “алтын балык” беркемгә дә капмады. Төнге клубларда кыйммәтле эчемлекләргә, затлы киемнәргә, силикон күкрәкләргә, кабартылган иреннәргә түгелгән акчалар акланмады. Кызлар, Вадимга өметләрен өзеп, аена утыз мең сум түләп, Дим бистәсендә утыз елга ипотекага алынган кысык фатирларында яшәргә мәҗбүр булды.

Дискотекаларда, төнге клубларда ничек күренеп калса, шулай тиз генә юк булды Вадим. Соңгы тапкыр аны бер сары чәчле чибәркәй белән күрделәр. Гүя кызыл китапка кертелгән, Җир шарында санаулы гына калган җанвар сыман. Һәм, ниһаять, Вадим Борунсон, җиңел һәм имин тормыш “ачкычы”, аның каршында. Дөнья акча белән идарә итә. Вадим кулында – тау-тау акчалар һәм дөнья рәхәтлекләре. Ахирәтләре урынында булса, Аэлина аның өстенә ташланырга, тезләнеп, табынырга тиеш иде. Ләкин ул дөньяда һәрнәрсә өчен түләргә кирәк, бушлай сыр кисәгенең тозакта гына булуын аңлый иде. Ул да үлеп сөйде. Тик егете, кочагына алу белән, икенче көнне үк ташлады. Җитмәсә, дус-ишләренә, Аэлинаның дус кызларына бу хакта горурланып сөйләп йөрде. Соңрак, дуслары белән сүз куешканы ачыкланды.

Бүген ул  яшендәй кискен хәбәрне җиңел кабул итте. Каршында кем басып торуын аңлардай халәттә түгел иде. Тагын, егетләрне, бай булсалар да, кесәләрендә тиен акча гына шалтыраса да, асыл затларның тәне генә кызыктыра иде. Кулланалар, туйганчы файдаланалар да сыра савыты сыман атып бәрәләр. Аннары, берни булмагандай, яңага үреләләр. Кем белсен, бәлки, Вадим да шундыйлардандыр? Байлар, акчаларын кая куярга белмичә, журналистларны, җәмгыятьне шаккатыру, үз исемен яңгырату өчен нәрсә генә кыланмый, нинди генә адымнарга бармый. Кемдер утрау сатып ала. Берәүләр Җиһанга турист булып оча. Океан буенда берсеннән-берсе гүзәл чибәркәйләрне кочагына алып, көне-төне кызыл уылдык кына ашап ятарга тиеш Вадим Борунсонның җәен гап-гади авыл йортында  кәҗә савып яшәп ятуын күз алдына да китерү кыен иде. Мондый хәлне берәрсенә сөйләсәң, беркем дә ышанмаячак.

– Башка вакытта, башка шартларда һәм синең хәтерең кайткач, бер утырып сөйләшербез. Мөгаен, син минем хакта азмы-күпме беләсеңдер. Имеш-мимешләрнең кайберсе – дөрес, кайберсе – уйдырма. Ә хәзер безгә ашыгырга кирәк. Киенеп беттең шикелле. Әйдә.

Төймәгә басты. Алар янә авыл йортына күтәрелделәр. Ишегалдына чыктылар. Сукмакта Байкал ята иде. Хуҗасын танып, шыңшырга, кыймылдарга тырышты. Койрыгын чак кына селкетә алды. Тәпиләрен кыймылдатырлык та хәле калмаган иде. Каны белән көче дә агып беткән иде. Вадим йонлач этне кочаклап алды. Куллары, футболкасы, йөзе канга батты. Җаны чыгып килгән этнең йөзеннән дә күз яшьләре тәгәрәде, елмайгандай, йонлач авыз читләре кыймылдады.

Мәрхүм әтисенең аны көчек килеш кенә алып кайтканын бүгенгедәй хәтерли. Фермада, әнисен югалтып, салам куышында йоклап яткан. Шыңшып елый, әллә әнисен сорый, әллә тамагы ачкан иде. Учына алгач, бәби сыман, кул җылысына, Вадимның күңел җылысына оеп, йоклап китте. Шул көннән бирле Вадим аның – хуҗасына, Байкал  Вадимның койрыклы тугры дустына әверелде. Икәү бергә урамда уйнап үстеләр. Җәйләрен чәчәкле болыннарда йөгереп уйнадылар, көмеш сулы күлләрдә су коендылар. Икәүләшеп көтү көттеләр. Кышын, аны чанага җигеп, мәчеләрне бастырды. Байкал кышларын Вадимның Павловка сусаклагычы ярындагы ял йортында кышлады. Вертолетта да очты затлы иномаркаларда да җилдерде. Яздан көзгә кадәр Ак Чишмәдә икәү яшәделәр. Картайды. Соңгы елларда бигрәк тә биреште. Колакка катыланды. Ашарга бирер өчен кат-кат исемен дәшәргә туры килде. Уң аягына аксый башлады. Кеше гомеренә күчергәндә, Байкал туксан яшьлек карт бабай инде. Гадәттә, мондый яшьтә бакыйлыкка күчкән кешеләр турында: “Урыны оҗмахта булсын! Яшәсен яшәгән, күрәсен күргән!” – диләр. Вадим ышанмады. Байкал мәңгелек яшәр төсле иде. Ләкин ул уянмады. Хуҗасын тозлы яшьләр түккәнен дә, күкрәгенә кочканын да тоймады. Сау бул, Байкал! Хуш, балачакның соңгы хатирәсе.

Кинәт Аэлина кычкырып җибәрде:

– Вадим!

Киң маңгаена килеп кунган 46нчы үлчәмле “Найк” кроссовкасы Вадимны аяктан екты. Күз алдында ут очкыннары чәчрәде, һәм егет караңгылык эченә чумды. Һушын югалта язды. Аэлина, чүгәләп, аны кочагына алды. Алар әзмәвердәй биш ир камавында калды.

– Боларны нишләтәбез?

– Кара әле, бабай егет булып чыккан. Гаҗәп!

– Таныдыңмы?

– Вадим бит бу. Вадим Борунсон. Кичләрен Уфаның Октябрь проспектында “Тесла”сында җилдерүче миллиардер.

– Аның биш шәхси вертолеты бар, дип сөйлиләр.

– Йөздән артык сөяркәсе.

– Үлеп барган авылда нәрсә югалткан ул? Шефка хәбәр итик.

– Хатын мине гел аның белән чагыштыра. “Менә, Вадим Борунсон, үзе тырышып корпорация төзегән. Вәт, ичмасам, тырыш егет! Ә син... Син сыра чөмереп, диванда футбол караудан башканы белмисең”, – ди.

– Туктатыгыз ләчтит сатуны. Бензин һәм аркан эзләгез! Очраклы корбаннар булгалый. Дөнья булгач, барысы да булгалый. Вадим Борунсон да кирәкмәгән җирдә кирәкмәгән кешенең юлын кискән. Үзе гаепле, – диде үлән чәйнәп торган Равил.

Көмеш чылбыр каршы килмәде.

**9**

Вадим ни булганын ачык аңлый башлаганда Аэлина белән икесен, аркага арка терәп, бер-беренә бәйләп булашалар иде. Канистр белән бензин әзерләгәннәр. Машка да нәрсә эшләргә белми. Аңа игътибар итүче, сөтен савып, үлән белән сыйлаучы юк. Байкал җан биргән. Канлы гәүдәсен койма янәшәсенә атып бәргәннәр. Зыңлап баш авырта. Катлаулы программалар төзергә, берьюлы меңәрләгән мәсьәләләрне хәл итәргә, миллионнарны дөньяның төрле почмакларында урнашкан бер банктан икенчесенә күчерергә, бер валютадан икенчесенә әйләндерергә күнеккән баш мие эшләргә теләмәде. Нишләргә? Аэлина елый-елый үксеп беткән. Юкка. Мондый бәндәләр күз яшьләренә алданмый. Акча. Бәлки аларны хайван халәтеннән янә кеше хәленә акча кайтарыр? Акча кешене хайван дәрәҗәсенә бик тиз төшерә. Бәлки, киресенчә килеп чыгар.

– Я, әйтегез. Күпме акча кирәк? Күчерәм. Аэлина өчен күпме вәгъдә иттеләр? Йөз тапкыр күбрәк түлим. Долларда, еврода, юаньда, криптовалютада, алтында, сумнарда...

Мәш килгән егетләр туктап калды. Серле генә берберсенә караштылар. Бүгенге заманда акча кешенең дөньяга карашын, эш-гамәлләрен, таянып яшәгән фикерләрен секунд эчендә үзгәртә ала. Бушның әтиәнисе үлгән. Коры кашык авыз ерта. Бүлешә белсәң генә уңышка ирешәсең. Акчага корылган заманның канатлы сүзләре, гыйбарәләре дә үзенә башка иде. Дөньяда барысы да акчага һәм бары тик акча өчен генә эшләнә иде. Аеруча бөтен эшне дә көч һәм явызлык белән генә хәл итәргә күнеккән, шуның белән көн күргән бәндәләр даирәсендә. Акча көчен, акча тәмен яхшы белгән Вадим аларның күңел кылларында, нерв җепселләрендә оста уйнады. Аяк-куллары бәйле булса да, утырган килеш бишесенең аңын буталдырды, юлларыннан яздырды. Еллар дәвамында кешеләрне акча өчен эшләтергә, акча өчен яшәтергә күнеккән, мондый осталыкка чит илдә укып, бөтен нечкәлекләрен өйрәнеп кайткан иде. “Кешеләрне эшләргә ике стимул гына этәрә: хезмәт хакына сусау һәм аны югалтудан курку” – Генри Фордның сүзләре хәтеренә уелып калган.

– Бәлки, акчасын алырбыз да, күрмәдек, тапмадык, диярбез?

– Исәр! Ул акчасын кесәсенә салып йөрми. Алар банклардагы исәпләрендә.

Беләгендә аждаһа сурәтле егет “көмеш чылбыр” каршына килде. Калган өчәү, ризалашкандай, аның белән янәшә бастылар. “Көмеш чылбыр” пистолетына үрелде. Бергә-бер чыксалар, җиңеләчәген алдан белгәнгә, коралына өметләнде.

– Килешәм, син шефның улы. Мин аның уң кулы. Бүген син һәм синең дусларың күмәкләшеп пешергән “ботка”ның очына чыгарга килдем. Эшне җиренә җиткермәсәк, синең колагыңны гына борачаклар. Ә без? Янә урам этләренә әверелеп, сукбайлар белән чүплектә казыначакбыз. Акчаларны тотынып та өлгермәячәкбез. Шефның кайда да күз-колаклары бар. Хәзер боларны йортка биклибез дә, ут төртәбез. Иске йортны беркем дә тикшереп, карап йөрмәячәк.

Башкисәрләр һушларына килде. Акчаны алу беләнмени, аны якты дөньяда кулланып өлгерә алмаячаклар. Яшәгән урыннары, хатыннарының кайда эшләве, балаларының нинди бакчага йөрүе, кайсы мәктәптә укуы – барысы да тиешле кешеләргә мәгълүм иде. Бер-бер хәл булса, барысы да зыян күрәчәкләр. Хуҗалар өчен бернинди киртәләр дә, чикләүләр дә, чикләр дә юк. Моны исләренә төшерүчеләр Аэлина белән Вадимны йортка сөйри башлады. Әмма янәшәдә генә яңгыраган ату тавышы барысын да сискәндерде.

– Йөзтүбән ятыгыз, кулларыгызны артка куегыз!

Ленар тоткыннарның бауларын чиште.

– Вадим!

Балачак дустын бабай киемендә күргән Ленар аптыраштa калды. Бер ай элек Уфада очрашканнар иде. “Тесла”да Октябрь Проспектыннан үттеләр, ресторанга керделәр.

– Җаның ни тели – ал. Сыйлыйм! – диген иде Вадим.

Менюдагы ризыкларны гына түгел, ресторанны сатып алырдай акчасы булса да, Вадим тыйнак кына утырды. Бәрәңге белән грильдә куырылган бәрән кабыргаларын ашады. Вертолетта ял йортына очтылар. Кошлар очкан биеклектән җирне күзәтте. Өстән кешеләр кара төртекләр булып кына күренде. Агыйдел, Караидел, Дим елгалары башы-койрыгы булмаган буар еланнарны хәтерләтте. Урманнар яшел мүк сыман иде.

– Югары белемең бар. Башлы егетсең. Уфага килергә теләгең булса, шылтырат.

Авылны яратты шул Ленар. Сөйгән кызы Лиана белән шуның өчен ачуланыштылар да. Лиана авылга кайтырга теләмәде.

– Авылдан туйдым. Шәһәрдә каласым килә, – диде ул.

Ленар, биш ел Уфада укып та, шушы кырларга, тугайларга, урманнарга уенда да хыянәт итмәде. Авыл-

podpiska.pochta.ru

да туды, авылда үсте һәм авылда яшәячәк иде. Аны мәхәббәт тә, акча да авылдан йолкып ала алмады.

– Барыгыз. Мотоциклга утырыгыз да, сызыгыз моннан!

– Бәлки, сиңа ярдәм итәргәдер?

– Юк! Барыгыз!

Бу юлы мотоцикл бер тибүдә кабынды. Алар кузгалып китте.

Ленар кибеттә үк нидер шәйләгән иде. "УАЗ" сүнде шул. Куып тотып булмады. Төзәткәнче вакыт үтте. "Бу машина түгел, тас эчендә шалтыраган тимер-томыр. Харап итәчәк ул сине", – дип, көлешкән иде коллегалары.

Тизрәк килеп җитсә, бәлки районнан ярдәм чакырып өлгергән булыр иде. Хәзер ул биш башкисәр белән үле авылда берүзе калды. Бармаклары пистолетны кысып тотса да, нәрсә эшләргә кирәклеге башына килмәде. Полициягә эшкә урнашканда Затон бистәсенә әзерлек үтәргә җибәргәннәр иде. Беренче һәм соңгы тапкыр пистолеттан шунда атты. Кечкенә генә булса да, аткан чакта пистолет югарыга сикерде. Ике кул белән тоткач та тыңлашырга теләмәде. Боевик геройлары ике кулга ике автомат тотып ничек төз итеп ата микән? Торып, йөгерешә башласалар, берни дә эшли алмаячак. Кесә телефонын алып, бүлеккә шылтыратты. Йөзтүбән яткан "Көмеш чылбыр" Равилгә күз кысты. Уфада кояш астындагы җылы урын өчен бик күп канкоешлы сугышларда булдылар. Тәннәрендә пычак эзләре дә, пуля үтәли үткән җөйләр дә бар. Каршыларында басып торучының пистолеттан ату осталыгын, сугыш алымнарын белү дәрәҗәсен беренче күрүдә үк аңладылар. Аның иң зур хатасы – башкисәрләргә якын булуында иде. Бармаклары, кашлары белән ымлап, Ленарның игътибарны смартфонына юнәлткән мәлне файдаланырга уйладылар.

Вадим көзгедән күзәтте. Менә бер башкисәр өлкән лейтенантны аяктан екты. Бишәүләп ташландылар. Ату тавышы.

– Ленар!

Вадим тормозга басты. Мотоцикл шуып барып туктады. Ак Чишмәдә шулай күнегелгән иде. Дустыңны бервакытта да авыр хәлдә ташлап китмисең. Борылып карады. Джипка егетләр төялеште.

– Аңа ярдәм итә алмыйсың. Әйдә, кузгалдык. – Аэлинаның тавышына сискәнде һәм газны ачты.

Күз яшьләрен тыя алмады. Харап иттеләр? Шәп егет иде. Яшь иде. Кара машина кузгалып китте. Аларны куа чыктылар. Вадим газны ныграк ачты. Бөтен кәҗә сукмакларын да исенә төшерде. Кая кереп югалырга? Чебен кадәре кара нокта гына булып күренгән машина тиз арада якынайды. Коляскалы "Иж" белән туры юлдан "БМВ"дан качып булмый иде. 450 ат көчле автомобиль һәм 24 ат көчле мотоцикл. "Ява" я колясказыз "Урал", "Днепр" мотоциклы булса, башка хәл. Куян да кола яланда бүредән качып котыла алмый. Кайчан да булса, хәле бетә һәм ерткыч авызына килеп каба. Ә менә калкулыклы уйсу урыннарда куянның яшәргә өмете арта. Чокыр-чакырда посарга, туктап калырга, кискен борылышлар ясарга мөмкин. Вадим да куян алымын кулланырга уйлады. Артык йөктән котыласы гына калды. Буш йорт ихатасына кереп туктады. Мотоциклга береккән колясканың шөрепләрен сүтәргә керешә. Җиңел эш булып чыкмады. Өстәвенә, клавиатура төймәләренә генә баскаларга күнеккән ак куллардан я ачкыч төшеп китте, я тутыккан шөрепләрне сүтәргә көч җитмәде. Манма тиргә батты. Инде, машина тавышы якынайды. Джип зур тизлектә урамнан үтеп китте. Ниһаять, коляска сүтелде. Коляскадагы азык-төлекне алып, Аэлинага тоттырды да, кузгалып киттеләр һәм кара машинаның нәкъ алдына килеп чыктылар. Ату тавышлары яңгырады. Вадимның башы очыннан пуляләр сызгырып үтте. Болай булмый. Көчләр дә, куәттә мөмкинлекләр дә тигез түгел. Яле, тикшереп карыйк, Германия горурлыгы Ак Чишмәнең чокыр-чакырларыннан да шулай җитез йөриме? Вадим, кырт борылып, юл астына төшеп китте. Машина, чайкала-чайкала, аларга иярде. Юл бетте. Сукмак кына калды. Инешне үткәч, урман куерганнан-куерды. Машина туктап калды. Караңгы төшә башлады. Юл тәмам бетте. Мотоцикл да бара алмас булды. Вадим Аэлинаны җитәкләп, урман эченә кереп китте. Урман, тыштан тыныч кына күренсә дә, Уфа яшьләренә бик күп сынаулар әзерли иде. Тынлык эчендә бу икәүне аю белән бүредән тыш, талпаны да, кара еланы да сагалады. Кыргый бал кортлары, сагызаклар ояларына тару да үлемгә тиң иде. Монда адым саен үлем, куак саен яңа сынау көтә. Артка чигенергә дә мөмкин түгел. Анда коралланган, күзләренә кан сауган башкисәрләр тырнагына эләгәсең. Күкрәгеннән йөрәген умырып алып, алга әйдәүче Данко сыман, бары тик алга гына барырга мөмкин.

Караңгы төште. Кайдадыр ябалак ухылдады. Еракта ниндидер ерткыч тавышы ишетелде. Урман үзенең төнге тормышы белән яши башлады. Ау башланды. Кагыйдәләр гап-гади. Бөтен җәнлекләр дә ике төркемгә, заманча әйткәндә, ике командага бүленә. Ерткычларга һәм корбаннарга. Эволюциянең иң югары биеклеген патшаларча биләүче кеше затыннан булуларына карамастан, Вадим белән Аэлина бүген икенче төркемгә кертелделәр. Урман аларга ташлама ясамас.

**10**

Вадим кесәсеннән айфонын чыгарды. Зарядка егерме процент кына калган. Элемтә юк. Геолокация җибәреп, берәр акланга вертолет кына чакыртыр да очып китәрләр иде – элемтәнең әсәре дә юк. Ике йөз меңлек айфон аяк астында аунаган имән кайрысыдай бер яраксыз, бер файдасыз иде.

Караңгы төшүгә канечкеч черки өере килеп ябышты. Алардан котылу чарасы юк. Куллар белән селтәнү, берничәсен юк итү генә ярдәм итмәде. Берәү урынына – унау, унау урынына – йөзәү килде. Алар ишәйгәннәнишәйде. Тешләгән урыннар кызарып шешәргә, кычытырга кереште. Нишләргә? Учак ягудан башка чара калмады. Төнен учак ерактан күренеп, "Менә без!" дип кычкырып тора-торуын. Бөтен өмет кеше аягы басмаган, балта белән танышмаган, йөзьяшәр имәннәр үскән, үтеп чыкмасыз чытырманлы урманда иде.

Вадим пакетка үрелде. Ул уйлаганча шома гына килеп чыкмады. Лимонад ватылып, пакетны ерткан. Шырпы манма су. Кытай токмачларының берничәсе генә торып калган. Лимонад берәү генә. Икмәктән дә җилләр искән. Бер балык консервы бар. Ярый әле, кимерергә сохари калган. Юеш шырпылар арасыннан бер корырагын чак эзләп тапты. Хәзер учак кабызырга кирәк иде. Коры агач ботакларын сындыргалап бер урынга өйде дә, шырпы сызды. Пыскып сүнде. Берәү, икәү, өчәү...



podpiska.pochta.ru

Дымлы күкерт кабынырга, очкын чәчәргә теләмәде. Байтак кына азаплангач, бер шырпы чак кабынды. Аны сак кына кипкән үләнгә якын китерде. Кечкенә ялкын телләре үләнне яларга кереште. Аннары аз-азлап кына вак чыбыклар өстәде. Ялкын куәтләнде, башын күтәрде. Агач кәүсәләрендә күләгәсе биеде. Вадим туризм белән шөгыльләнә иде. Башкортстанны аркылыга-буйга кичеп чыкты. Ирәмәл тавына да менде, Бөрҗәндә, Моракта, Аскында мәгарәләргә керде, Агыйдел елгасында салда төште. Байкал күлендә су коенды, Карелиягә барды. Табигать бер көйләсә, бер чөйләде. Артык кыланганны, сторисларны көн сан хәйран калырлык видеолар белән бизәүне, очынганны яратмады. Краснодарда бер төркем туристлар белән тауга менгән иделәр. Давыл чыкты, яңгыр башланды. Кайтыр юлны югалттылар. Көннәр болытлы булганга, аларны вертолетлар да шәйләмәде. Өч көн тау-таш арасында көн күрделәр. Ашарларына бетте. Йөгерек Кавказ  чишмәләрен эчеп, сусауларын бастылар. Кыргый җиләк-җимеш, үлән тамырлары белән туклandылар. Аларны дүртенче көнгә генә эзләп таптылар. Шуннан бүтән сәяхәт итмәскә үз-үзенә сүз бирсә дә, сүзендә тормады. Учак кызып китте. Бер-ике агачны читкә алып куйды. Артык зур учак та кирәкми иде. Беренчедән, аларны ерактан шәйләп алачаклар. Икенчедән, челлә чорында урманда янгын чыгуы ихтимал.

Вадим яшел үләнне көйрәтте дә, тирә-якка селтәнергә кереште. Канечкечләр төтенне яратмый. Хәзер югала алар.

Әллә хәлсезләнүдән, әллә булган вакыйгаларны аңлап җиткерә алмаудан Аэлина кымшана да алмады. Утырган җирендә оеды. Имәнгә сөялде. Вадимны күзәтте. Байларны очынгыч, уңга-сулга акча чәчүдән башка берни дә белмәгән “ак яка” дип уйлый иде. Алай түгел икән. Әнә бит, кулыннан барысы да килә. Учагын да тергезде, черкиләрдән котылу юлын да уйлап тапты.

– Тамагым кипте. Эчәргә юкмы?

Вадим лимонадны ачып бирде. Аэлина шешәнең төбенә төшкәнен сизми дә калды. Тамагы кибүдән бигрәк, тәне яна иде.

– Ашарга сохари гына. Кытай токмачы бар. Шул килеш кимерсәң генә. Кызганыч, ләкин консерв ачардай бер әйбер дә юк.

Аэлина сохарига үрелде. Бүген ул шулкадәр тәмле, шулкадәр татлы иде. Гүя, Җир шарында сохаридан да тәмлерәк ризык юк. Кибеттән сохари сатып алу түгел, аның ягына борылып та карамый иде. Хәзер беләчәк. Тиздән тамагы туйды.

– Эчәсеңме?

Коры сохари тамагына тыгылган Вадим бер йотты да шешәне кире Аэлинага сузды. Үзе, нарат, чыршы ботакларын сындыргалап, җиргә түшәде.

– Монысы – йомшак караватк булды. – Вадим наратлар өстенә килеп утырды.

– Я, сөйлә инде хәзер. Үзең белән таныштыр. Ничек малайдан бабайга әйләндең?

Вадимның моңарчы беркемгә дә серен ачканы булмады. Хәзерге заманда, сереңне белеп алучылар, күпмедер вакыттан соң, кул астындагы мәгълүматны кулланып, синең белән көрәшә башлый. Мондый хәлләр адым саен. Әмма Аэлина белән икесе бүген бер тормыш корабында гизгәнгәме, җавaптан кача алмады. Каршындагы чибәркәй нишләптер күңеленә якын тоелды. Гүя, алар бер-берсен күптән белә.

– Ак Чишмә авылы егете мин. Уфада укыгач, үз фирмамны ачтым. Кечкенә киосклардан башлаган идем, хәзер корпорациям бар. Ковид чорында авылда яшәдем. Офислар белән читтән торып кына идарә иттем. Йорт астында подвал казып, махсус эш бүлмәсе ясарга туры килде. Тыныч имин тормышны яратам. Шуңа, чит-ят күзләрдән яшереп, лифт кордым. Трасса киңәйтелә башлагач, болай да санаулы гына халкы калган Ак Чишмә авылында яшәүчеләргә Таш Чишмәгә, Салкын Чишмәгә күченергә тәкъдим иттеләр. Йортлар төзеп бирделәр. Мин ризалашмадым. Акча төртеп, йортымны калдырдым.

– Ник бабай булып киттең?

– Уфада урамга чыгып тыныч кына йөри алмыйм. Паркта да тынгы юк. Бөтен җирдә танyйлар. Журналистлар, көндәшләр, асыл затлар. Сагалап кына торалар. Шундый хәйләгә барырга булдым. Бер ел актерлар курсына йөрдем. Бабайларча сөйләшергә, күрешергә өйрәндем. Килеш-килбәтләрен ятладым. Парик, сакал ябыштырып, бугазга тавыш үзгәрткеч ябыштырып, имтихан тапшырдым. Сукбай булып киенеп, беркөн Үзәк базар тукталышында җир асты юлында хәер җыйдым. Беркем танымады. Кич җитте. Бер ханым йөз сум акча салды. Аны куып тотып, кулына ун мең сум тоттырдым.

– Авылга ел саен кайтасыңмы?

– Ел әйләнәсенә чит илләрдә булам, Русия шәһәрләрен гизәм. Җәен авылга юл тотам. Авыл халкы өчен мин нибары кәҗә савучы, бакча үстерүче бер ялгыз бабай гына. Файдам тимәсә дә, беркемгә дә зыян салмыйм. Корпорация белән йорттан торып кына идарә итәм. Һәр офиста эш барышын мониторлардан күзәтеп торам. Фатирларымда, йортларымда да камералар урнаштырылган. Барысы да – уч төбемдә.

– Киләчәктә нишләмәкчесең?

– Авылны үтермәскә. Чишмәне тазартып, ял йорты ачарга. Өйләнү турында уйлаган юк. Чөнки миңа очраган чәчбикәләрне бары тик акча гына кызыктыра...

Аэлина агачка сөялгән килеш йоклап китте. Вадим аны ылыслы түшәккә салды да, аркасын терәде. Җылылык сизде. Тән җылысы гына түгел. Җан җылысы бөркелә иде. Эчтә, кайдадыр күңел чоңгылларында якты бер нур яралды. Ниһаять, күңеленә якын бер җанны очратты. Ясалма хисләре белән муенына асылынган, кочагына керергә нинди генә адымнарга бармаган чәчбикәләр өереннән гарык булган иде. Дәваханәгә эләккән иде, көн дә бер чибәркәй хәлен белергә килде. Яшь шәфкать туташлары ни генә кыланмады. Кая барса да, аны адым саен тозак сагалады. Беркемне дә Вадимның хисләре, кичерешләре кызыксындырмады. Аның байлыклары, акчалары иде асыл затларның теләге. Аэлина да өсбашы, килеш-килбәте белән алардан әллә ни аерылмый сыман. Анадан тума килеш джипта җилдерүе ни тора. Иреннәре кабартылган. Күренеп тора. Үзенеке түгелләр. Тырнаклары да озынайтылган. Чәче дә, кат-кат буялып, янып беткән. Курчакныкын хәтерләтә. Нишлисең, заман башка – заң башка. Ак карга булып, тырнагын бизәмичә, яшьтәшләреннән калыша алмый. Ләкин аның коңгырт күзләрендә нииндидер моңсулык бар, җаныннан җылылык бөркелә. Әллә кылана гынамы? Йоклаганда сабый балаларны хәтерләтә. Бигрәк мөлаем. Вадим йомылган керфекләрен ачарга тырыш-

podpiska.pochta.ru

ты. Йокламаска иде исәбе. Черем итү – иң зур хата. Янә теге бәндәләр белән очрашасы килми. Битеннән ботинка эзләре һаман да җуелмаган. Тиздән таң атачак. Әнә, офык кызарып килә. Аэлина бераз ял итсен дә юлга чыгарга кирәк.

Бу вакытта урманның икенче башында биш ут көлтәсе күренде. Фонарьлы кешеләр агачлар белән капланган мотоциклга юлыктылар.

– Анавында үлән тапталган. Димәк, шул юнәлешкә кереп киткәннәрдер. Ашыгырга кирәк. Таң атканчы, йоклаган хәлдә эзләп табыйк. Ерак китәлмәсләр.

**11**

Вадим йөзенә кояш төшүдән уянды. Йоклаган. Йокламаска кирәк иде. Хәзер куып килүчеләрдән качып котылу бик тә кыен булачак. Табаннарына басып киләчәкләр. Якында гына ниндидер тавышлар килә. Учак урынында көлләр генә калган. Аэлинаны уятырга кереште. Күзләрен ачкач, үзе артыннан әйдәде. Алар агачлар арасына кереп югалды. Битләрне, беләкләрне убырлы карчык тырнакларыдай куаклар сыдырды. Гүя урман да дошманнар яклы. Һәр агач, һәр куак алар каршына чыкты сыман. Алай дисәң, шушы яшел күлмәкле купшы агачлар куенына яшермәсә, бәлки, әлеге вакытта исән дә булмаслар иде.

Сүнгән учакны биш егет уратып алды.

– Эзләр көньякка кереп китә. Әйдәгез!

Аэлина акрынайганнан-акрынайды. Тәне ут булып яна, тамчы да хәле юк. Карында ач бүреләр улый. Бер чишмәгә юлыктылар. Боз кебек салкын иде. Кулларын, черки талап, бөртенгән битләрен юдылар, йотлыгып эчтеләр. Шифалы табигать суы белән хәл керде, ярсыган күңел яралары авыртуы басылды. Салкын Чишмә. Авылга килеп чыга. Менә кайда икән аның башы. Төшәр урын да ясалган, мал-туар кермәслек итеп, койма белән уратып алынган. Вадим теләгенә ирешер. Ак Чишмәне дә, чүп оясыннан актарып алып, ирекkә чыгарыр. Ак Чишмә дә, кояш нурларында коена-коена, сусавын басарга килүчеләрне сыйлар. Теш чатнарлык салкын су карынга төшү белән, качакларга көч кергәндәй, томанланган зиһеннәрен яктыргандай тоелды.

– Салкын Чишмә авылы төньякта. Димәк, трасса көньякта. Шушы юнәлештә барсак, нәкъ трассага килеп чыгачакбыз.

Чишмә тирәсен кара бөрлегән сырган иде. Вадим көрән җиләкләрне уч-уч җыеп ашады, Аэлинага сузды. Алар янә урман эченә кереп китте. Аэлина атлар алмас хәлгә җитте. Вадим аны күтәреп алды. Башта җиңел генә тоелса да, авырлыгы сизелә башлады. Куллары оеды, урманның йомшак туфрагы үзенә суырды. Вадим түзде. Туктау – үлемеңне якынайту иде. Өстәвенә, яңгыр яварга кереште. Башта сибәләп кенә торса, бераздан чиләкләп иште. Аяк асты ләмгә әверелде. Атларлык түгел иде. Бер нарат астына кереп постылар. Гүя шалаш сыман иде. Калын кәүсә астына бер тамчы да үтеп кермәде. Яңгыр ничек башланган, шулай тиз генә тәмамланды. Кара болытлар арасыннан кояш чыкты. Сандугачлар сайрарга кереште. Юан агачка аркалары белән сөялгән качаклар янына агачтан бер йомгак тәгәрәп төште. Төште дә, кечкенә тәпиләре белән җирне казырга кереште. Авызындагы чикләвекне чокырга яшереп, табигатьтә моңарчы күрмәгән ике җан иясен күзәтте. Озын кышны хәстәрләгән тиеннең кеше затын тәү тапкыр күрүе иде. Кан дошманнары – сусар белән карчыганы әллә каян шәйләп алып, качарга күнегеп алды. Каршындагы җан ияләренең дусмы я дошманмы икәнлеген генә аңламады. Якынрак килеп карады. Аэлинаның да кыргый тиенне тәү тапкыр күрүе. Йомшак уенчыкмыни! Аны кулга аласы, кочаклап сөясе килде. Койрыгы йонлач мамык сыман. Колак очларындагы мамыкларга иркәләнәсе иде. Кара төймәдәй күзләре уйнап кына тора. Кинәт тиен шым булды. Якында гына ниндидер тавышлар сизде. Гомере өчен көрәшеп, ерткычлардан биш адым алда йөрергә күнеккән җан иясе ялт кына агачка үрмәләп менеп тә китте. Койрыгы гына күренеп калды. Вадим Аэлинага торырга ярдәм итте. Яңгыр яумаган булса, бәлки, алар да агачка менеп кенә посарлар иде дә бит. Яңгыр бөтен эшне харап итте. Хәзер аларның эзеннән бару тагын да җиңелләште. Булдыра алган кадәр ашыга-ашыга юлларын дәвам иттеләр. Аэлина янә акрынайды. Куып баручыларның сөйләшкән тавышлары ачык ишетелде. Күтәреп бармалы түгел. Аяк асты ләмгә әверелде. “Найк” кроссовкасының карар җире калмады. Үзле урман балчыгы балавыздай ябышып, тубал кадәре булды. Гүя ике аякка да бишәр потлы герләр бәйләп куйдылар. Аларны чистартып, чак кына баруга, янә шул ук хәл кабатланды. Аэлина, Вадимның иңбашына таянып, сөйрәлеп диярлек атлый.

– Аларны күрәм шикелле. Кара әле анавында!

– Әйе! Безнең качаклар һәм безнең акчалар. Ягез тизрәк.

Колагын ярып кергән тавышлар Вадимны соңгы көчен җыярга мәҗбүр итте. Урыны белән Аэлинаны күтәреп тә барды. Ниһаять, алда күңелгә якын тавышлар ишетелде. Машиналар гөжләве. Димәк, котылыр чара да кул сузымында гына.

– Түз, Аэлина. Чак кына түз. Озак калмады.

Ниһаять, олы юлга килеп чыктылар. Машиналар чабыша. Бер тукталыш та, бер кеше дә юк. Аэлина белән басып, үткенче машиналарга кул күтәрделәр. Тик беркем дә туктарга теләмәде. Киресенчә, башта тизлекләрен акрынайттылар да, туктап беткәч, газ педаленә бар көчләренә бастылар. Өс-башлары, ертылып беткән, черки талаудан шешенгән икәүне беркемнең дә тузан да кунмаган чиста салоннарына утыртасы килмәде. Киресенчә, бу урыннан тизрәк үтү ягын карадылар.

Урманнан бер-бер артлы биш кара шәүлә килеп чыкты. Алар ашыкмадылар. Корбаннары алар кулында, алар карамагында иде. Монда тукталыш та юк, халык та күренми. Үткән-сүткән халык туктарга куркачак. Кешенең кешедә ни эше бар? Исән каласылары килсә, юлларында булсыннар. Туктаган хәлдә дә, аларга кем каршы тора алсын. Хәзер, эләктереп алалар да, икенче көнгә сузылган эшләрен төгәллиләр. Шуннан, Уфага кайтып, бер тәүлек саунада, бассейнда ятачаклар.

Черки талаудан бөртенеп, йөзләре пычранып беткән башкисәрләр тагын да куркынычрак тоелды. Алар гүя Җир кешеләре түгел, чит планета кунаклары иде. Вадим белән Аэлина, мәчедән качарга омтылган тычкандай, һаман алга атладылар. Соңгы көчләренә, гомерләренең соңгы минутларына кадәр көрәшергә иде исәпләре. Көчле җиңми. Кем бирешми – шул җиңә.

Көчләр нисбәте тигез түгел иде шул. Бер якта – авыру кыз белән “ак яка”, икенче якта – типсә тимер өзәрдәй

podpiska.pochta.ru

әзмәверләр. Вадим, битараф машиналарга кулын болгады. Туктамаячакларын белсә дә, чәбәләнде. Беркем дә, үз гомерен куркыныч астына куеп, бу икәүгә ярдәм итәргә теләмәде. Мөгаен, юл – җәмгыять көзгеседер. Хәзер һәркем үзе өчен генә яши бит. Кеше кайгысы, кеше мәшәкате күптәннән беркемне дә борчымый да, кызыксындырмый да. Элек авылда йорт күтәрергә булса, егермеләгән ир-ат җыелыр иде. Хәзер өмәгә этем дә килми. Килсә дә, сәгате, минуты өчен акча таләп итә. Вадим үскәндә урам белән бәрәңге утырттылар. Өлкәннәр казыды, кечкенәләр күз салды. Ә хәзер? Бакчаны атналар дәвамында утырталар.

Курку катыш ачулы йөзенә юлдан пычрак чәчелде. Бер фура аларны баштанаяк коендырып китте. Менә егетләр шәбрәк атлый башлады. Хәзер куып тотачаклар. Я хәзер – я беркайчан да! Вадим йодрыгын йомарлап, Аэлинаның йомшак учын кысып, бер машина астына ташланды. Күзен чымырдатып йомды. Я оҗмахка эләгәчәкләр, я котылачаклар. Машина, юеш асфальтта шуып барып, юл уртасында басып торучыларга терәлеп диярлек килеп туктады. Руль артында, маңгай тирен сөртеп бер бабай утыра иде. Вадим белән Аэлина, салон ишеген ачып, артка кереп утырдылар.

– Газ педаленә булдыра алган кадәр бас, бабай! Үзең телефон номерыңны әйт. Машинаңны эчен дә, тышын да юарга җитәрлек, нервларыңны төзәтерлек акча күчерермен. Я, әйдә тизрәк.

Көзгедән биш әзмәвернең йөгергәнен күргән бабай газ педаленә басты. Куе-яшел төстәге “җиделе” сызгырып кузгалып китте.

– Чак кына өлгәшмәдек! – диде тыны кысылган Көмеш чылбыр һәм, иелеп, юл читенә бармаклары белән нидер язарга кереште.

Качаклар утырган машинаның номеры билгеле. Шефка хәбәр итеп, Уфага барышлый электергә әллә ни кыен эш түгел иде. Хуҗаның тешләре бүренекедәй үткен, куллары агулы үрмә гөлдәй озын. Айфонын алды да, исемлектән “Шеф” дигән язуны табып, экрандагы яшел төймәгә басты.

Алкино авылында арткы урынга ике юлчыны утырткан “җиделе”не юл инспекторы туктатты.

– Инспектор Галимов. Кая юл тотасыз? Документларыгызны күрсәтегез!

Инспектор арткы урынга күз салды. Анда илле яшьләрдәге ике хатын утыра иде. Аларны күрү белән, сержантның йөзеннән гаҗәпләнү йөгерде.

– Документларыгыз тәртиптә! Хәерле юл! – дип, түбәсендә төсле утлар җемелдәгән машинасына кереп, рациясенә үрелде.

Вадим белән Аэлина юл өсте кунакханәсендә төшеп калып, юынып, киемнәрен алыштырып, башка машинада җилдерделәр. Төтен чалмасы уранган Уфага көтмәгән яктан килеп керделәр.

**12**

Биш процент заряды гына калган айфонга водитель ярдәме белән янә җан керде.

Башкортстанның башкаласы үзенчә гүзәл иде. Юкә агачлары үскән урамнардан машиналар елгасы ага. Шәһәр халкы атнаның кайсы көнендә дә каядыр ашыга, һич тынгы белми. Таш түшәлгән тротуарлардан чибәр кызлар атлый. Коляскаларында бәбиләрен эткән яшь әниләр дә очрый. Кайберәүләр бөтен гомерен хакы бер жигули хакы торган уч төбе кадәре этләргә багышлаган. Аяк астында йомгактай тәгәрәгән җан ияләрен киендергәннәр, махсус уенчыклары, үзләренә генә хас азыклары да бар.

– Дәваханә каршында калдырыгыз! Акча күчердем!

Вадим Аэлинаны дәваханәгә һушсыз, авыр хәлдә күтәреп алып керде.

– Сез кем буласыз? Кемне алып килдегез?

– Мин Вадим Байков. Хәбәрсез югалган Аэлина Рәкыйпованы алып килдем. Полициягә хәбәр итегез. Үзегезнең кызыгызны карагандай хәстәрләсәгез иде. Буш итмәм.

Каршында Уфа миллиардеры басып торган табиб нәрсә әйтергә дә белмәде.

– Сезнең белән селфи төшәргә мөмкинме?

Вадим ризалашты. Күнеккән иде. Аны күрүчеләр мондый үтенеч белән еш мөрәҗәгать итә. Гадәти хәл. Беркемгә дә баш тартмый. Аңа да өстәмә реклама бит. Ләкин бүген гаҗәпләнде. Пациентлары үлем хәлендә. Ә алар фото турында уйлый.

Парктагы яшьләр дә, бер-берсе белән аралашыр, табигатькә сокланыр урынга смартфоннарына текәлеп утыра. Егетләр гүзәл кызларны күзлисе урынга, айфоннарыннан карашларын алмый. Болай дәвам итсә, кешеләр аралашу сәләтләрен югалтып, янәшә басып та смартфон аша язышып кына аралашачак. Айфон чире Вадимны да урап узмаган. Әл дә Ак Чишмәгә кайтып, башын, зиһенен ял иттерә.

– Монавында кул куегыз. Исем-шәрифләрегезне, яшәгән урыныгызны һәм телефон номерыгызны языгыз.

Вадим, кәгазьләр тутыргач, дәваханәдән чыкты. Капкадан чыгуына аны кара “Лэнд Крузер” көтә иде. Шкаф кадәре егет чыгып салон ишеген ачты. Беләгендә аждаһа сурәте. Көмеш чылбыр сагыз чәйнәп тора. Танышлар. Полициядән дә алда йөриләр. Мәгълүмат яшен тизлегендә тарала Уфада. Торып чапмакчы булган иде. Кире уйлады. Аэлина бар бит. Хәзер аларның язмышлары бергә бәйләнгән. Вадим аны бәхетле итә ала. Харап итәргә дә бер ялгыш адым ясау җитә.

– Утыр, Вадим. Фатирыңа гына илтеп куябыз. Кайда яшәгәнлегеңне беләбез. Тимибез. Син бит Уфада абруйлы, билгеле кеше.

Күн салонга кереп утырды. Автомобиль кузгалып китте. Урындагы кешене таныды. Һәрвакыттагыча костюм-галстукта. Агарган чәчләре матур итеп җыелган. Тешләре энҗедәй ялтырый. Бармагында оникс ташы белән бизәлгән калын алтын балдак. Кулында “Булгари” сәгате. Яши белгән һәм теләгәнә ирешә торганнардан. Бизнес-семинарларда бергә очрашканнары, “түгәрәк өстәл”ләрдә катнашканнары бар иде. Башкортстаннан Кытайга эш сәфәре белән очкан делегациядә бер төркемдә, бер самолетта бардылар, кайттылар. Уфа Мәскәү түгел. Юллары моңарчы еш кисеште.

– Шундый хәлләр, Вадим дус. Равил улым дус-ишләре белән бераз күңел ачкан. Колагын бордым боруын. Ботканы гына мулдан пешергән. Ташып аккан. Хәзер миңа ашарга, җыештырырга. Җитмәсә, син килеп кысылдың. Кызның авызын ябарга туры килә инде. Мәңгелеккә. Исе чыкмасын өчен. Синең белән берәр ничек килешербез. Монавыңа күз сал әле.

Вадимның алдына бер чемодан куйды.

podpiska.pochta.ru

– Ачып кара. Сиңа ошаячак.

Биш меңлекләр шыплап тутырылган. Рәт-рәт. Кып-кызыллар. Ул арада машина Зәки Вәлиди урамына юнәлеш алыр урынына, Салават Юлаев проспектына төшеп, Черниковка бистәсенә юл тотты. Вадимны куркытырга, аңлату эшләре алып барырга уйлыйлармы? Кызу бәндәләрне тиз генә суытырга, хаталар ясаганчы, тыныч кына акылга утыртырга кирәк иде. Вадим чемоданны ябып, кире хуҗасына сузды.

– Ватцапп аша бер хәбәр җибәрдем. Башта шуны карагыз. Аннары сөйләшербез.

Видеоязманы караган түрәнең йөзе үзгәрде. Анда Равил Байкалны атып үтерә, Вадимны тибеп аудара, чирәмдә утыручыларны утта яндырырга тәкъдим итә.

Башта кызгылт төскә керде, шуннан чия-кызылга әйләнде. Хамелеон диярсең. Бүртенде. Тәртсәң, шартлар төсле иде. Голт итеп ярты стакан виски тутырып эчте. Тагын берне салды. Стаканны чатнатырдай итеп кысты. Ачуын чыгарырга чара юк иде.

– Аэлинага тимәскә, аның турында онытырга киңәш итәм. Азрак гафу үтенсәгез дә комачауламас. Дәваланырга, хәтерен кайтарырга күп акча таләп ителәчәк. Мәңге төзәлмәс күңел ярасы турында да онытмагыз. Аның ахирәтенә дә ярдәм итегез. Минем турында онытсагыз, ләм-лим булырмын. Акчагыз кирәкми. Әгәр дә минем белән, Аэлина аның ахирәте белән берәр нәрсә булса, шушы видео бер мизгелдә бөтен Интернет челтәрен тутырачак. Күчермәләре тиешле серверларда саклана. Килештекме?

Виски башына суккан Хамелеон читкә борылды.

– Зәки Вәлиди урамына.

Водитель, күпергә күтәрелеп, янә Салават Юлаев проспектына төште. Дүрт манаралы "Әр-Рәхим" мәчетен үттеләр.

Вадимны подъезд төбендә калдырдылар. Матурым! Нью-Йоркка киткән мәхәббәтеңне ничек сагынып көттең? Тугрылык сакладыңмы? Айфон экранындагы бер билгегә төртте. Йокы бүлмәсеннән онлайн репортаж килеп чыкты. Иркен караватта суалчаннардай бербе рсенә уралган ике шәрә гәүдә ята иде. Вадим көлеп кенә куйды да, тимер ишек аша подъездга үтте. Консьерж аны аягүрә каршы алды.

– Сөйләмә дә, Сәлимә апа. Барын да беләм.

Кара костюм кигән ханым янә утырып, сканворд чишүен дәвам итте. Дөньядагы иң тирән күл – "Байкал". Аркылыга – "аксакал". Ике шакмак тулгач, зур җиңү яулагандай, куе яшел чәй уртлады.

Фатиргә кергә, өстенә ак япма бөркәнгән Дарина килеп чыкты. Чәчләре тузгыган. Йөз-кыяфәте дә элеккедәй чибәр түгел. Намусыннан тыш, гүзәллеген дә югалткан.

– Сезгә ун минут. Әйберләреңне җый да – хуш.

Үзе ашханә бүлмәсенә керде. Кулердан су алып эчте. Дәваханәгә шылтыратты.

– Аэлина Рәкыйпованың хәле ничек?

– Һушына килде. Тән температурасы нормада. Әтиәниләре янында. Кем әле бу?

– Танышы.

– Ничәнче палата? Нинди бүлектә?

– Хирургия.

– Зур итеп рәхмәт!

Икенче номерны җыйды.

– "Алло" чәчәк салонымы? Әйе, чәчәкләр кирәк иде. Илле кызыл рауза гөлләмәсе. "Ак Чишмә егетеннән" дип языгыз. 22нче дәваханә. Хирургия, ...нчы палата. Аэлина Рәкыйпова. Зур рәхмәт!

Хәзер Канар утрауларында ял иткән чакта да, йорткураңны күзәтергә, айфон аша бакчага су сибәргә мөмкин. Автопилотта хәрәкәт итүче автомобильләр дә җитештерелә. Салонга кереп утырасың да, адресыңны әйтеп, ятып йоклыйсың. "Корыч атың", светофорларда туктап, аварияләргә эләкмичә, исән-имин алып кайтып җиткерә. Әмма заман технологияләре кешенең тормышын җиңеләйткән чорда да кәҗәләр үз-үзен сава алмый. Андый токым әлегә чыгарылмаган. Машка исенә төште. Машка! Акыллы һәм сөйкемле җан иясе. Иртән чыгып киткәндә дә, кайткач та, муен астын кашыта. Кишер, алма белән сыйласаң, Машка өчен дөньяда синнән дә яхшырак кеше юк. Ул сиңа тагылып йөриячәк, сырты белән ышкылачак. Тик бүгенге вакытта аның хәле шәптән түгел иде. Савылмаган җилене бүртенеп, шешеп, авыртадыр. Бахыркаем.

Тиз генә Филүсне җыйды. Көзен, Уфага китешли, кәҗәләрне, тавыкларны Салкын Чишмәдә Филүстә калдыра иде. Ашарына ашлыгын, түкләгән печәнен китертте. Өстәп акчасын да түләде. Филүс ай саен, Машканы, аның бәтиләрен кочып, тавыкларны тотып, ватцапп аша фотоотчет салды. Эшләре баштан ашса да, Вадим түзми, Яңа елдан соң кайтып, Машканы кочаклап, алма, кишер белән сыйлап, муен астын кашып килә иде. Әтәч белән җиде тавык та санаулы һәм һәрберсенең исеме бар. Әтәч – Наполеон. Аякларының очына кадәр кызыл төк баскан. Гүя затлы итекләр. Тавыкларына якын китерми. Очып кунарга гына тора. Һәрбер тавыкның үз ләкабе: Варан, Сарделька, Веста, Хонда, Мангуст, Жанна, Аврора. Тупас кешеләрне "тавык мие эчкән", диләр. Вадим алай уйламый. Тавыклар җим типкәндә, үлән чемнәгәндә җырлар көйли. Һәрбер тавыкның үзенә генә хас моңы, җыры бар. Әгәр дә күзен бәйләп, каршына тавыкны китерсәләр, Вадим һәрберсенең исемен әйтә ала. Филүс өчен тавык кадерле җан иясе түгел иде:

– Чалып, тазартып, алып кит. Аш итәрсең. Киләсе елны, кайтышлый Авдоннан яңаларын сатып алырсың. Тавык та булдымы җан иясе! – дип сукрана.

Филүсне җыйды.

– Саумы, Филүс. Ашыгыч кына Уфага барырга туры килде. Хәләлең белән килеп, Машканы савалмассың микән? Тавыкларны да искә ал. Мичкәләрдә су тулы. Помидор белән кыярларга су да сибәсе бар. Йортны бикләргә онытма. Ачкыч ишек кәсәгендә.

– Ярар.

Филүс баш тартмый. Беркайчан да баш тартмый. Чөнки нинди йомыш үтәсә дә, акча мулдан ява. Бүген дә аның "Сбер" картасына ун мең сум килеп төште.

Тимер ишек шап итеп ябылгач, залга үтте. Бер асыл затның тормышыннан мәңгелеккә китүе, икенчесенең килеп керүе табигый хәл иде. Мондый хәлгә аптырамады да. Аеруча бүген.

– Каһвә яса. Латте. Музыка куй. "Роксана" радиосын. Сауннаны кыздыр. Идәнне себер. Ролл китерт. Ике сет. Кызыл балык белән.

– Ярар, әфәндем!

Акыллы фатирда бер мизгелдә бар тирә-як хәрәкәткә килде. Пәрдәләр ачылды. Почмактан ике робот-тузан

podpiska.pochta.ru

суырткыч килеп чыгып, идәнне себерергә керештеләр. Көй агылды.

*Җаным, сиңа хисләремне нинди сүз белән әйтим?*
*Синнән башка бу дөньяда минем күңелем ятим...*

Илмира Нәгыймова җырлый. Аның күңел түрендә кайнаган хисләр өермәсенә туры килә түгелме соң? Уфага концерт белән килгәч, Илмирага чәчәкләр гөлләмәсе тапшырачак.

Йомшак халатына уранып, каһвә машинасыннан эчемлек алып, саунага кереп китте. Колакларны бөрерлек кызу. Шоп-шома юкә ләүкәгә сузылып ятты. Тәненнән тир ага да башлады. Черки тешләгән урыннар кычытты. Тик ул авыртуны да сизмәде, рәхәтлекне дә тоймады. Тәне кызу саунада булса да, йөрәге, җаны, уй-хисләре белән башка берәү янында иде. Ленарны искә төшерде. Ике хис бергә кушылды. Мәхәббәт һәм нәфрәт. Күз яшьләре тәгәрәде.

**13**

Ял йортында бәйрәм кызганнан-кызды. Аракы елга булып акты, сый-нигъмәтләрдән табын сыгылып торды. Көтмәгәндә артистлык сәләте ачылучылар караоке җырлады. Мунча, сауна да бушамады. Юынып чыгучылар иркен бассейнда йөзде. Туган көнен билгеләүче Равил бүген юмарт иде. Дус-ишләре өчен акча да, бернәрсә дә, беркем дә жәл түгел. Әнә бер машина чибәркәйләр китертте. Әйдә, рәхәтләнсеннәр. Равилнең туган көнен истә калдырып, тагын бер ел зарыгып көтеп алсыннар. Чуктан-чук киенгән дүрт тән күбәләге чыгып басты. Берсе тәмәке кабызды. Калганнары, пышылдап, бәхәсләшергә керештеләр:

– Миңа сары чәчлесе!

– Миңа бөдрәсе!

– Озыны минеке!

– Нечкә билгә кагылмагыз!

Егетләр тавыш күтәреп, кызларны бүлешә башлады. Ул арада асыл затлар төялешкән “Хонда” гөжелдәп кузгалып та китте. Дөм исерек ир-ат өерендә беркемнең дә каласы килмәде. Тау-тау акчалар өчен дә. Баш кадерлерәк иде.

– Кая киттегез?

– Без монда бит!

– Эх!

– Уф!

Бер егет джипны куып та карады. Егылып, чалбарын ертты. Шуннан, сүгенә-сүгенә, тузан туздырган машинага таш ыргытты.

Авызына сүнгән тәмәке капкан, кулына ярты шешә сыра тоткан Равил аңламый да калды. Күн сумкасыннан акча алырга дип кереп киткән иде. Телефоннан шылтыратты. Алучы юк. Нишләргә?

– Володя, Саня, Аза! Сез иң айныклары. Барыгыз Уфага. Тиздән “Скорпион”да дискотека тәмамлана. Такси көткән бер-ике чәчбикәне эләктереп алып кайтыгыз.

Имән ышыгында торган “Митсубиси” кузгалды. Бәйрәм дәвам итте.

Бу көнне Аэлина ахирәте Карина белән “Скорпион” төнге клубына, дискотекага җыендылар. Ахирәтенә фатирга килде. Такси чакырырга иде исәпләре.

– Мин чибәрменме? Вадим Борунсон очраса, гашыйк булырлыкмы?

Кыска итәкле Карина көзге каршында бөтерелде. Бал кортынықыдай нәзек билле, чәчләрен бөдрәләткән, күзләренә сөрмә тарткан кыз гүзәл иде. Мөгаен, бу кадәре бизәнмәсә-төзәнмәсә дә матур булыр иде. Әллә нигә Вадим дип хыяллана. Нәрсәсен тапкандыр шуның, кай җиренә кызыккандыр. Йөрәген, җанын бирергә әзер егетләргә сер бирми. Акчада гынамыни бәхет?

Аэлина исә байлыкка кызыгып, алтын читлектә яшәргә җыенмый. Очрар әле тиң яры. Егерме ике генә бит әле аңа. Артык бизәнүне, игътибар җәлеп итәрдәй кысык-мысык киемнәрне дә яратмый. Бүген аны Карина көзге каршына бастырды.

– Кара. Кемне күрәсең?

– Үземне...

– Каян таптың бу соры кофтаңны? Киң чалбарыңны? Без бит паркка бармыйбыз. Кил әле.

Бүлмәсенә алып керде. Нәкъ караваты өстендә Вадим Борунсонның зур фотосурәте беркетелгән иде. Карина кием шкафыннан күлмәкләр барлый башлады.

– Монысы бармый, монысы түгел, менә монысы...

Чак сыйды. Тән тиресенең бөтен җыерчыгына кереп торган күлмәк. Тар һәм кысык. Бот төбен чак каплады. Алгы яктан да ап-ачык. Ялтыр чүпрәк күкрәк очында чак эленеп тора. Күлмәккә туры китереп, биек үкчәле туфли кидерде. Мондый хәлдә халык арасына түгел, фатирдан да чыгарырга оялырсың. Үткер Карина ахирәтен тиз генә бизәндерде, чәчен җыеп, койрык итеп бастырып куйды.

– Ә хәзер кемне күрәсең?

Аэлина үзен танымады. Аңа күз камашырдай сылу карап тора иде. Буй-сын дисеңме, кыйгач кашлар, очкынлы күзләр дисеңме. Гадәттә, киемне мода буенча түгел, уңайлы булуына карап сайларга күнеккәнгә, үтә сәер тоелды. Алыштырып куйганнар диярсең. Иркен балаклы чалбарлар, муенга кадәр күлмәк эчендә нинди гүзәл тән яшеренеп яткан икән. Ачыш ясады. Күңелен шомлы уйлар да биләде. Төнге клубка мондый халәттә бару кирәкмәс кебек. Һәрхәлдә, әти-әнисе рөхсәт итмәсләр, хупламаслар иде.

– Бөтен борчулы уйларыңны оныт. Әйдә мәхәббәт, иркен хисләр дөньясына сәяхәткә! – диде Карина, кызыл чаян сурәте җемелдәгән, көй агылган бина каршында таксидан төшкәч.

Төнге өчтә генә килеп чыктылар. Карина үле исерек иде. Вадим Борунсон күренмәгәч, янган йөрәген шәраб белән суытты. Такси чакырдылар. Килүче генә юк. Бер мизгелдә буш Уфа урамында икәү генә торып калдылар. Ниһаять, ике ут көлтәсе күренде. Аэлинаның шатлыгы эченә сыймады. Ниһаять, такси. Джиптан өч әзмәвер төште дә, сорап та тормыйча, кызларны салонга утырттылар. “Митсубиси” гөжелдәп, кузгалып китте.

– Туктатыгыз! Безне кая алып киттегез!

Аэлинаның өзгәләнеп кычкыруы колонкалардан агылган көчле көйдә эреде. Җылыга кергән Карина йоклап китте. Көчле куллар чәбәләнгән Аэлинаның авызын капладылар.

Аларны ял йортында икенче катта икесен ике бүлмәгә кертеп бикләделәр. Аэлина йөгереп барып тәрәзәне ачты. Аста асфальт. Сикергән хәлдә аякларың сыначак. Сынмаса да, имгәнәчәксең. Бүлмә түрендәге

podpiska.pochta.ru

киң караваt өстендә зур сурәт. Диңгез киңлекләрендә җилкәнле ялгыз кораб. Акчарлаклар оча. Эх, йөзәсе иде шул корабта. Качасы иде тоткынлыктан. Акчарлаклардай, канат җилпеп, менәсе иде болытларга. Ишек артында тавыш купты.

– Мин беренче!

– Юк, мин!

– Мин!

– Бүген кемнең туган көне? Ул беренче!

Юыну бүлмәсенә кереп бикләнмәчке иде, кемдер ишекне тибеп ачты. Аягында чак басып торган бер ир килеп керде. Әллә куркышыннан, әллә һаман гаҗәпләнүдән кыз кымшана да алмады. Беләгендә аждаһа сурәтле егет Аэлинаның күлмәген, эчке киемнәре белән бергә ертып атты. Ни булганын аңлап та өлгермәгән Аэлина, ак җәймәгә уранып, почмакка сыенды. Исерүе җиткән әзмәвер, учын учка уып, иреннәрен ялап алды. Бу мизгелдә Аэлина пәрәвездә бәргәләнгән чебенне хәтерләтте. Кычкырырга уйлады. Тирә-якта урман. Көй агыла. Беркем дә ишетмәячәк. Тәрәзәдән сикереп, аякларыңны гына сындырачаксың. Нишләргә? Егет чайкала-чайкала аңа якынлашты. Аның авыр сулышына кадәр ишетте. Ул арада юыну бүлмәсен күреп алды. Тешен кысып, сакалы җиткән бәндәнең битен сыпырды.

– Чак кына түз, ярыйммы! Төнге клубтан чак чыккан идек. Тирләтте. Душ кереп чыгам.

Душ бүлмәсендә тәрәзә үтә тар иде. Ишекне бикләп, суны агызырга куйды да, үрмәләп тәрәзәгә менде. Тышка чак чыгып җитте. Тәрәзә төбенә басып, яңгыр торбасына үрелде. Чык төшкән иде. Шуып китеп, торбага тотынып калды. Ак япмасы, ак хыяллар сыман, шадра асфальт йөзенә шуып төште. Көче бетә, нәзек беләкләре калтырый башлады. Акрын гына аска шуышты. Һәр сантиметр, һәр миллиметр чакрымга тиң иде. Торба хәтфәдәй тәнен тырнады. Башта, төшеп баскач, олы юлга чабарга уйлады. Каринаны да коткарырга кирәк иде. Ләкин ничек? Үзе исән калса, ярдәм чакырачак. Йортка керсә, икесе дә харап булачаклар. Ул арада йорт эчендә тавыш купты, кемдер өстән кычкырды.

– Тотыгыз!

– Качмасын!

Аэлинаның йөрәге дөпелдәп типте. Йөгерер урынына, кымшана да алмады. Төштәге сыман. Күңелендә, аңында җилдәй җитез җилдерсә дә, өнендә каккан казыктай басып тора иде. Ял йорты хәрәкәткә килде. Эчтә кемнәрдер йөгереште. Баскычтан аяк тавышлары килде. Ниһаять, Аэлина да урыныннан кузгалып китте. Качса, куып тотачаклар. Рәт-рәт тезелгән машиналарга күзе төште. Берсе бикле, икенчесе дә...

– Әллә кая китмәгәндер. Эзләгез! Табыгыз!

Урманга йөгереп кереп киттеләр. Фонарь утлары караңгылык пәрдәсен ертты. Аяк тавышлары якынайды. Үрелеп кенә бер машинаның ишеген тартты. Руль артына менеп утырды.

– Чү! Анавында тавыш ишетелде.

Ачкыч урынында иде. Эчкән баштан алырга оныткаңнар. Кабызып, биш метр араны үтте дә сүнде. Аэлина водитель таныклыгын күптән алса да, рульгә утырганы юк иде. Җитмәсә, джипта утыргыч югарыда урнашкан, газ педаленә бармак очы белән генә баса алды.

Янә кузгалып китте. Кара шәүләләр хәрәкәткә килде. Кемдер ишек тоткасына ябышты. Бераз сөйрәлеп барып, төшеп калды. Газ педаленә басты. Олы юлга килеп чыкты. Юлга караса – юл билгеләрен, юл билгеләрен караса, юлны күрмәде. Уфа урынына Самара юнәлешенә борылды. Машина төнге юлдан җилдерде. Күз кабаклары авырайды, куллары, аркасы оеды. Адашканын аңлаганда, арттан бер машина куып килүен сизде. Газ педаленә басты. Юл читында каршына бер эт килеп чыкты. Өстенә менмәскә була, кырт кына уңга алды һәм... Юл читенә тәгәрәде. Куа килүче машина бер багана өстенә килеп менде. Каты итеп башы бәрелде. Ут сүнде. Сирена тавышына уянды. Җимерек ишектән чак чыгып, үләннән шуышып, агачлар арасына барып ятты. Бераз хәл кергәч, болын буйлап китте. Аякларына үләннәр кадалды. Күңел ярасы тирән булгангамы, тән ярасын тоймады. Бер йортка килеп юлыкты. Ихатада эт өрергә тотынды. Капкадан йонлач җан иясе килеп чыгып, аның кулын яларга, койрыгын болгарга кереште. Шул эт килеп чыкты бит юлга. Башта харап итә язды. Хәзер үлемнән коткара. Посып кына, бер корылма эченә кереп, печән өеменә хәлсезләнеп ауды. Чак кына хәл җыя да барып ишек шакый, ярдәм сорый. Ятып торган иде, ничек йоклап киткәнен дә, хәтерен җуйганын да сизмәде. Тормышның ачысын-төчесен татыган, азау тешләре кителгән карт эт, хуҗасын уятырга була, ишегалдына барып, чиныйчиный өрергә кереште.

**14**

Юл чатында бер бабай белән әби. Бабай арба эткән. Нәрсәдер эзләнәләр, як-якларына караналар. Тапталган сукмактан болынга кереп китеп, авыл читендәге йортка килеп җиттеләр.

Ихатага керү белән, әби паригын салып атты.

– Уф-ф, Вадим. Пештем. Син ничек түзәсең?

Вадим белән Аэлина бергә яши башладылар. Коточкыч хәлләрдән соң, Аэлина озак дәваланды. Хәтерен кайтару өчен кая гына мөрәҗәгать итмәделәр. Мәскәү табибларына кадәр барып җиттеләр. Ләкин хәтере тулысынча кайтып бетмәде. Урыны-урыны белән генә исенә төште. Кычкырып, кайвакыт елап уянды. Төнге маҗаралар үз эзен калдырды. Мондый чакларда аны кочаклап юатырга, даруын эчерергә кирәк иде. Кайбер көнне, иртән уянгач, хәтта Вадимны да танымады. Мондый халәтеннән чыгаруы тагын да авыррак иде. Бергә төшкән фотоларны, видеоларны күрсәтеп, чак тынычландырды. Авыр булса да, Вадимның бирешергә исәбе юк иде. Үлем тырнагыннан ычкынып, исән калдылар. Язмыш сынауларын да бергә үтәчәкләр. Никахлаштылар. Туй үткәрергә иде исәпләре. Җәен Ак Чишмәдә яшәделәр. Вадим “Ак Чишмә” кунакханәсен төзетә башлады. Нигез салдылар. Аэлинаны идарәче итеп куймакчы иде шунда. Чишмәне ачтылар. Тимер улак, баскыч ясатты. Юлчылар кереп су алалар. Салкын Чишмә, Таш Чишмә авылы халкы да эчәр суга Ак Чишмәгә йөри.

– Ак Чишмә суы йомшаграк. Чәен эчеп туя алмыйсың, юшкын да утырмый, – дип, сөенә-сөенә, унар литр сыешлы савытларын тутыралар.

Авыл халкы өчен Вадим һаман да шул Расих карт иде. Җитәр бер көн, сере ачылыр. Ләкин әле иртәрәк. Аэлинаның әби кыяфәтендәге исеме – Фатыйма. Картәнисенең исеме.

podpiska.pochta.ru

Аэлина келәт читенә бәйләнгән көчекне учына алды. Сөтен эчкән, икмәген ашаган. Көчек, чәнти бармак кадәр генә койрыгын болгап, хуҗасының кулларын яларга, ашарга сорарга кереште.

– Кул этенә әйләндереп бетәсең инде. Ул бит  йорт сакчысы. Әйеме, Вулкан?

Булачак йорт сакчысының корсагын кытыклады. Тегесе, хуҗасы белән ризалашкандай, бер-ике тапкыр өрде. Байкал урынына яңа көчекләре бар. Аэлина Уфа урамында очраган. Күз яшьләре чыгарып, уттай кайнар асфальтта шыңшыган ак йомгак янәшәсеннән үтеп китә алмаган. Алып кайткан. Хәзер яңа хуҗаларына, яңа мохиткә күнегә. Машка да, Наполеон да, тавыклар да аны кечкенә һәм тату гаиләләренә кабул итте шикелле.

Аэлина йортка үтте. Капка төбенә бер машина килеп туктады. Ихатага Ленар килеп керде. Уң аягына аксый. Ярасы төзәлсә дә, баскан чакта сиздерә. Вулкан, җитди кыяфәт чыгарып, тавык та курыкмаслык тавышы белән өрергә, ырылдарга кереште. Иңендә дүрт йолдыз җемелдәгән, көн кызу булганга, фуражкасын баш түбәсенә этәргән егет алар белән күреште.

*– Әнкәй миңа кара икмәк, чәйнәп,*
*Имезлеккә салып биргән дә,*
*Үзе киткән урак урырга...*

– Атнабай! Синең белән Атнабайның да, Тукайның да бөтен шигырьләрен истә калдырдым.

– Молодец! Юлда бер-бер хәл булса, туп-туры миңа шылтырат. Юл чаты бит. Тагын, югары очта ике йортта яңа кешеләр яши башлады. Искә алырсың әле. Нинди кешеләр микән? Ярар, күрешкәнгә кадәр.

Капитан “УАЗ”ында кузгалып китте. Вадим дустына өр-яңа “Нива” бүләк итәргә җыена иде. Туган көненә. Әйдә, йөрсен. Тырыш егет. Кар ерып, пычрак сөреп йөрергә куәтле төзек машина кирәк.

Идән астында урнашкан душ бүлмәсендә коенып чыктылар. Кәҗә каймагы, эремчеге, сөте белән чәй эчтеләр. Өстәлдәге помидор, кыяр, кыяклы суган да үзләренеке иде. Әллә шуңа, бик тә тәмле тоелды.

– Чишмәгә барып киләбезме? Кибеткә дә сугыласы бар. Лимонад белән туңдырма бетеп килә.

– Ярар! – диде Аэлина.

Коляскалы “Иж” мотоциклы кузгалып китте. Вулкан, ят тавыштан куркып, койрыгын бот арасына кыстырып, оясына посты.

Югары очта өмә гөрли иде. Рәттән ике йортта. Иске агач коймаларны аударганнар. Алар урынына профнастилдан кызыл койма коялар. Йорт түбәләренең шиферын сүтеп, калайга алыштыралар. Бер “КамАЗ” тора. Аның арбасына бакчаны баскан чия, шомырт, миләш агачларын кисеп төйиләр. Болай, булгач, авылга янә җан керә.

Чишмәгә чират иде. Вадим күбесен танымады. Автомобиль номерларына карады. Чиләбе, Сарытау, Самара, Мәскәү, Казан... Ак Чишмә суын Русия төбәкләрендә яшәүчеләр йотлыгып эчә. Димәк, суның да, авылның даны да илгә тарала. Вадим биш литрлы савытын тутырып алды да, коляскада утыручы Аэлинага сузды.

– Кузгалдыкмы, карчыгым?!

Таш Чишмә авылына барып, кибеткә керделәр. Аэлина үзенә кирәк-ярак караштырды. Вадим, суыткычтан туңдырмалар, лимонадлар алып, кассага якынлашты.

– Кызылны!

– Яшелне!

Таныш тавышлар. Әби белән бабай калошны тарткаладылар. Бу юлы әбинең сүзе өстен чыкты. Сатучы, гадәттәгечә, телевизорга кереп үк киткән иде. Янә сериалда кызган мәлгә туры килде.

– Рейан, мин Азатка аттым. Әтиеңә ни өчен шулай эшләгәнен әйттем. Мәҗбүр идем. Һәм ул ышанмады. Бер-беребездән башка беркем дә юк. Синең белән безгә бүтән беркем дә ышанмаячак. Без шулай эшләргә мәҗбүр. Аерылышудан башка чара юк.

– Юк, мин аның белән сөйләшәм. Мин аны ышандыра алам, Миран. Ул ышаныр.

–  Ничек, Рейан? Азат мин икәнлегемне раслагач, кирегә юл юк...

Әби белән бабай килеп җиттеләр.

– Кызым, БСТны ач әле. Анда шундый яңалык. Һушың китәрлек.

Сатучы теләр-теләмәс кенә пульт төймәсенә басты.

– Уфадан билгеле эшкуар шәхси самолетында Бөрҗән урманнары өстендә фаҗигагә тарыган. Беркем дә исән калмаган. Улы да, аның дуслары да...

Зәңгәр экранда фотосурәтләр килеп чыкты. Хамелеон, “Көмеш чылбыр”, аждаһа сурәтле егет... Вадимга аларның һәммәсе дә яхшы таныш иде. Аэлина килеп җитте. Сатучы кабат төрек сериалын ачты.

Мотоцикл, кузгалып, Ак Чишмәгә юл тотты.

Август урталары. Җәен туганнарына печән хәзерләшеп, туган як һавасын сулап, көмештәй күлләрдә су коенып инде фатирларына ашыккан, номерларына 86 саны язылган затлы машиналарның, кыр казларыдай тезелешеп, Чиләбе ягына юл тоткан мәле иде...

*2023 ел, июль.*

podpiska.pochta.ru



# Ает – патриотлар Ватаны!

Минем туган авылым – Бишбүләк районының шагыйрь-патриот Фатих Кәрим туып-үскән Ает авылы. Аның табигате бигрәк матур. Бер ягында – ямьле Дим елгасы ага, яшел тугайлар сузыла, икенче ягында биек тау да, киң басулар да, куе урманнар да бар.

Авылыбызда бик тырыш, ярдәмчел халык яши. Украинада махсус хәрби операция башлангач, якташларым тагы да берләшеп, дошманга каршы күтәрелде.

Ил өчен авыр вакытта иң башта авылдашларыбыз "Чулпан" кибетендә сугышчыларыбыз өчен кирәк-яраклар җыю пункты ачты. Авыл халкы җылы оекбашлар, азыктөлек, шәхси гигиена әйберләре



тапшырды. Бу посылкаларны озаткач, авылыбызда "Җиңү өчен. Ает" төркеме оештырылды. Аңа күрше Кәрим, Мулланур-Вахит авыл халкы да кушылды. Бүгенге көндә бу төркемдә 80 кеше исәпләнә. Асия Гата кызы Фәйзуллина үзенең элекке кибет бинасында тукмач әзерләү пункты оештырды. Кешеләр тукмачны өйләреннән әзерләп алып килеп тапшырды. Шул ук вакытта апалар йон җепләр сатып алып, җылы оекбашлар бәйләде.

"Алтын – утта, кеше авырлыкта сынала", – ди минем Гөләмзә апам. Хәзерге вакытта каплау челтәрләре әзерләү белән шөгыльләнәләр. Үрергә җиңел булсын өчен, абыйлар агачтан каркаслар ясап биргән. Тукымалар Мәскәүдән үк килә икән районнарга. Ике сменага бүленеп, авыл халкы кыска гына вакытта 12 челтәр әзерләгән. Каникулда сыйныф белән барып, апаларның хезмәтләре белән танышып кайттык. Алар безгә челтәр үрү буенча осталык дәресе күрсәтте. Алдагы көннәрдә алар снайперлар өчен Бичура (Кикимора) һәм Шүрәле (Леший) костюмнары әзерләргә ниятли.

Авыл китапханәсендә Альбина Гатиятуллина балалар белән сугышчыларыбызга хатлар яза. Безнең мәктәптә дә махсус хәрби операциядән ялга кайткан солдатлар белән очрашулар үткәрелеп тора. Без аларга хатлар язып, рәсемнәр төшереп, посылкалар оештырып җибәреп торабыз.

"Диңгездә тамчы булып тоелса да, бу бик зур, кирәкле эш", – ди минем әнием.

Абыйларыбыз тиз арада дошманны җиңеп, туган якларына кайтсын иде. Аларга исәнлек, тазалык теләп калабыз, алар белән горурланабыз!

***Ранелия ХАФИЗОВА,***
*Бишбүләк районының Фатих Кәрим исемендәге Ает урта мәктәбе укучысы.*





podpiska.rost



# “Алтын башак”ка – 90 яшь!

*“Туймазы хәбәрләре” гәзите каршындагы “Алтын башак” әдәби берләшмәсе төзелүгә 90 ел тулды. Узган гасырның 30нчы елларында аны Рәшит Нигъмәти, Баязит Бикбай, Муса Сираҗи, Әсгать Мирзаһитовлар оештыра. Аларның эшен Әкрам Даутов, Әмир Дивеев, Халисә Шәмсетдиновалар дәвам итә. Соңгы елларда “Алтын башак”ны Фатыйх Сайфран, Зөлфия Сафина, Нәҗия Гәрәевалар җитәкли.*

*Соңгы елларда иҗат берләшмәсе шактый гына югалтулар кичерде. Әлфирә Бикмәтова, Халидә Шәмсетдинова, Әнисә Минһаҗева кебек талантлы шәхесләребез бакыйлыкка күчте.*

*Бүгенге көндә берләшмәгә 20гә якын каләм тибрәтүче йөри. Алар район һәм шәһәр күләмендә узган чараларда даими катнашып килә. Әдәби берләшмә әгъзаларының язмалары районыбызның “Туймазы хәбәрләре”, Октябрьскийда чыккан “Туган як”, шулай ук “Кызыл таң”, “Өмет” гәзитләре, “Тулпар” журналында басылып тора.*

***Әлфия ШӘЙХЛИСЛАМОВА,***
*“Алтын башак” әдәби берләшмәсе җитәкчесе.*

ЫШАНЫЧ

Мин ышанам әле, йөрәкләрдә
Саф мәхәббәт, сөю барына.
Күз яшьләрем белән баса алам
Тезләнепләр аның алдына.

Мин ышанам әле җир йөзендә
Исертерлек тылсым барына.
Мине көчле итеп йөртә алар
Сагышларга баткан чагымда.

Мин ышанам әле, кешеләрдә
Җиңә торган көчнең барына.
Шушы көчтер бөркет итә мине,
Кеше итә бөркет янында.

***Фатыйх САЙФРАН.***

podpiska.pochta.ru

ЯШЬЛЕГЕМНЕҢ КАГАМ ТӘРӘЗӘСЕН

Ал бирмәгән ятка.
Ял бирмәгән атка.
Еллар тел шартлатып,
Калды иңрәп артта.

Үкси-үкси болыт
Керә кочагыма.
Манма суга төшеп,
Әйди яшь чагыма.

Кыяр-кыймас кагам
Чүккән тәрәзәсен.
Мин барларга тиеш
Нәсел шәҗәрәсен.

Исем-атка килсәң,
Мин… хан нәселеннән!
…Шөкер. Гади яшим
Яшьлек кәсебемнән.

***Наилә МИҢНЕХАНОВА.***

МОҢ ТАМА

Әллә әнкәй мине моңлы чакта
Тудырганмы якты дөньяга?
Башкалар еласа – күзеннән яшь,
Минекеннән никтер моң тама.

Юкә чәчәгеннән бал тамганда,
Сандугачлар сайрар таңнарда
Тудыргансың мине, моңлы булсын,
Дигәнсеңдер, кулга алганда.

Каранымның челтерәп аккан суын
Бөркегәнсең миңа моң итеп.
Сагышлы бер йолдыз җиргә төшкән,
Төннән качып, мине үз итеп.

Күзәнәгем саен моң сарыкмас.
Җырлый-җырлый кереп юмасаң,
Каның җанга җылы моң түкмәсә,
Мин кем идем, шулай тумасам.

Үзең юксың... Мин сагышлы сазда.
Синнән миңа күчә моң һаман.
Башкалар еласа – күзеннән яшь,
Минекеннән әрнеп моң тама.

***Даим ЯУШЕВ.***

КЕМ ЯЗМЫШЫ КЕМНӘР КУЛЫНДА?

Авыр сулап пароходлар килә,
Идел яры кала озатып.
Кемдер берәү тальян гармун уйный,
Узган яраларны кузгатып.

Идел ярып ак пароход китте,
Сулышлары калды талларда...
Кем язмышы кемнәр кулында соң?
Туктамады безнең ярларга...

Пароходлар узып Идел ага,
Туган ягын ташлап кайларга?
Әйтче, Идел, әйтче, нишләргә соң
Яраланып калган ярларга?

***Рима КЛЮЧАРЕВА.***

ТАЛ МАМЫГЫ

Гаҗәпләнеп карап торам,
Таң калам талларыма.
Талгын гына ак мамыгын
Коя тал алларымда.

Җир дә, тал да ап-ак була,
Ак була яшел үлән.
Талның мамык койган чагын
Гел шулай төштә күрәм.

Тал мамыгын күбәләк дип
Тотып алырга җилдән,
Һаман истә йөгергән чак
Тәпиләп мамык җирдән.

***Люция ИСХАКОВА.***

ТУЙМАЗЫ ШӘҺӘРЕ ГИМНЫ

Гүзәл төбәк – Башкортстанымның
Данлы шәһәре син – Туймазым.
Кара алтын таба, йортлар сала,
Үрләр яулый егет-кызларың.

*Кушымта:*
Үткән юлың данлы, Туймазым,
Синдә тормыш ямьле, Туймазым.
Башкаларга матур үрнәк булып,
Яшә син, чәчәк ат, Туймазым.

Үсәсең күкләргә үрелеп,
Яшисең гөлләргә төренеп.
Күпмилләтле халкың татулыкта
Гомер итә синдә туган булып.

Горурланып данлы үткәнеңә,
Хезмәтеңә биреп бар көчең,
Тормыш тыныч, матур булсын өчен
Һәркем кертә үзенең өлешен.

***Зиннур ХӘЛИУЛЛИН.***

МОҢЛЫ КОШЛАР КЕБЕК КАНАТ ҖИЛПЕП

Моңлы кошлар кебек канат җилпеп,
Кагыныр да шигырь юлларым.
Уятыр ул сөю тулы хисне,
Тибрәлдереп йөрәк кылларын.

Синең йортны табып, сине күзләп,
Учак ялкын кебек кабыныр.
Сүнмәс хисләр байкар сине эзләп,
Сөя белгән шуңа табыныр.

***Лира ГЫЙНИЯТУЛЛИНА.***

* * *

Ник мин гашыйк шулай таң нурына,
Әллә инде таңда туганга.
Әллә инде әнкәм, бәхет теләп,
Шул нурларга салып юганга.

Шул нурларга тәү кат, күзем ачып,
Күргәнгәме әллә күк йөзен.
Ишеткәнгә әллә таң нурында,
Әнкәм, синең җылы наз сүзең.

Таң нурында тәү кат хыял килде,
Таң нурлары булды сердәшем.
Керфек тә какмыйча, нурга чумып,
Йолдызлардан сине күзләдем.

Яшьлек иртәләрем – таңнар кебек,
Таң нурлары ага каннарда.
Гомерем дә таңдай гына булды,
Китеп барырмын бер таңнарда...

***Лена МӨХӘММӘТОВА.***

САРЫ ЯФРАК

Сары яфрак, җирнең өстен каплап,
Алтыннардай җәелеп ятасың.
Әйтерсең лә агач, күлмәк салып,
Көтә иркәсенең кайтасын.

Сары яфрак, агач тамырларын
Сөеп коча көзләр килгәндә.
Язлар белән кире кайтыр әле
Яшеллекнең ямен күргәндә.

Мин дә шулай, сары яфрак сыман,
Сөюләрем күчә гөлләргә.
Җиргә төшеп югаласым килми,
Яшим әле шушы җирләрдә.

***Ләлә МАННАНОВА.***

podpiska.pochta.ru



Зөлфия САФИНА

*Зөлфия Габделһади кызы Сафина Чакмагыш районының Сыерышбаш авылында туган. Сабый чагында әти-әнисез калгач, Кушнаренко интернат-мәктәбендә тәрбияләнә. Тәүге шигырьләрен шунда яза. Аннан укуын Туймазы шәһәренең 1нче интернат-мәктәбендә дәвам итә. Бу мәктәптә җыр укытучысы булып танылган композитор Әкрам Даутов эшли. Ул кызны "Алтын башак" әдәби түгәрәгенә җәлеп итә. Анда ул Тимер Арслан, Муса Сираҗи кебек тәҗрибәле остазлардан тәҗрибә ала. Читтән торып Башкорт дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. Гомере буе Туймазы пыяла заводында мастер булып эшли. Бүгенге көндә лаеклы ялда. Шигырьләре район, республика басмаларында даими дөнья күреп тора. "Илһам чишмәләре-2006" шигърият фестивалендә икенче урынга лаек булды.*

# Су ташый җил кызлары...

* * *

Тәрәзәмә чирткән вак яңгырны
Куып-куып, бозлы җил исә.
Мин язларны сагынып
уйга чумам,
Тәрәз чиртеп, көзләр килде исә.

Кемдер миңа: "Кичке караңгыда
Тәрәз чирткән тамчы – ул!" – дисә,
"Башын иеп, миңа килгән!" –
диеп,
Мин сагынмас идем, югыйсә.

Кемдер килеп:
"Җирдә кыштырдаган
Алтын яфрак – менә ул!" – дисә,
Көлә-көлә таптап үтәр идем
Һәм сагынмас идем, югыйсә.

Тик син миңа үткән язларымнан
Көзге тамчы булып кайтмадың.
Баскан саен өзелеп
пышылдаган
Алтын яфрак булып ятмадың.

Син кайтмадың,
мин дә чакырмадым,
Арабыздан көзге җил үтте...
Бу ялгышның башы синдә булса,
Өзгәләнмәс идем бу тикле.

НИГӘ?

Шәүлә кебек, калмый бер тотам,
Бер уй килә минем артымнан –
Тик әзергә генә туганмын,
Нигә генә кеше булганмын?

Нигә булмаганмын тынмас җил?
Гомер буе нидер эзлимен.
Нигә булмаганмын ут-ялкын,
Берөзлексез утсыз дөрлимен.

Нигә булмаганмын бер яфрак?
Көзләр җиткәч төшәм өзелеп.
Нигә булмаганмын көл-туфрак?
Калам берчак җиргә күмелеп.

Нигә булмаганмын бер елга?
Сулар кебек агам тукталмый.
Тамчы булсам, бер тамчыда
Барлык дөнья калмый
чагылмый.

Ә нур булсам, мизгел эчендә
Барып җитәм, көтә хыялым.
Ни булсам да, мине бу кадәр дә
Газапламас иде уйларым.

ҖӘЙ БАШЫНДА

Кичке авыл. Кырдан көтү кайта,
Читәннәргә элеп тузанын.
Чал бабайлар капка төпләрендә
Күзәтәләр сүзсез, әйтерсең лә,
Көтү түгел, гомер узганын.

Буразналар кебек җыерчыклы
Арган куллар ята тезләрдә.
Олыгайтып тагын бабайларны,
Әкрен генә кояш баеганы
Чагылып үтә моңсу күзләрдә.

Утырганда шулай көн озатып,
Җәйге кичтә өйләр каршында,
Дөньяларны күргән уйчан картлар
Иртәгәне уйлап тын кала:
"Сугыш килгән иде
җәй башында".

* * *

Яфракларның яшел, яшәр чагы,
Нидер серләшәләр үзара.
Тик бер яфрак үзгә, саргайган ул,
Әйтерсең дә тәндә бер яра.

Шул үзлеге белән күзгә кереп,
Ераклардан тора күренеп.
Яшел янгыннарда яна-яна,
Өзеп алдым аны үрелеп.

* * *

Юллар авыр – каршы җилләр исә,
Туктыйм таеп, ташка абынып.
Кемдер куша кире борылырга,
Үҗәтләнәм, кабат кагынып.

Атлыйм алга, серле юлларымда
Күзәтәмен дөнья агышын...
Саф алтыннан кыйммәт,
таудан биек
Бер бөртеге хәләл табышның.

podpiska.pochta.ru

* * *

Азмы хәсрәтле уйларны
Кырга чыгып җилгәрдем...
Җиргә ятып елаганын
Күргәнем бар җилләрнең!

Күргәнем бар яңгырларның
Чәчрәп, балкып көлгәнен.
Нинди ләззәт, рәхәт җанга,
Ачыла күңел гәпләре.

Кышка керсәм, күмеләм мин
Ап-ак карга, буранга.
Сагышлардан шаша буран,
Сыймый җырга, урамга.

...Атомнардан гына торса
Һәм җансыз булса әгәр,
Үксеп елар идемени
Бу җилләр таңга кадәр.

## ӘНИЕМӘ

Сабыйлыкта калган әкиятләрем
Төшләремә кереп йөдәтә.
Бүген тагын күрдем, имеш, әнкәй
Өр-яңа бер әкият өйрәтә.
Үзе сөйли, үзе миңа карый,
Ә тышта кыш, карлар җемелди.
Әкиятләре бетә, ә соңыннан
Ул кабасын алып йон эрли.
“Менә, кызым, син бишектә чакта
Җиңел иде әкият сөйләве,
Картаелды, авырайды хәтта
Орчык тотып җепләр эрләве...”
Сабыйлыкта калган әкиятләрем
Төшләремә кереп йөдәтә:
Әнкәй мине һаман бала күреп,
Әкиятләр сөйли, өйрәтә...

## КЫШ

Җирдәге ак карлар – чишмә,
Тәмле суы – яктылык.
Челтер-челтер ага чишмә –
Урам тора яктырып.

Җил кызлары бу чишмәгә
Көн дә килә шатланып.
Урам буйлап кайта алар
Чишмә сулары алып.

Чишмәләре мөлдерәмә,
Көянтә сыгылмалы.
Буран дип уйлама син –
Су ташый җил кызлары...

## ҖИЛ

Әй шашынды җил, шашынды.
Агачларга үрмәләде,
Ботакларны сындырды.
Аннан ары, егылып төшеп,
Кар көртләрен туздырды.
Морҗалардан мичкә төшеп,
Ялкын белән әрләште.
Ут-ялкынга көч җитмәгәч,
Төтен белән көрәште.
Урамнардан йөгереп үтте,
Тәрәзәләргә кар атты.
Ачуыннан елый-елый
Көртләрдә аунап ятты.
Ә бераздан, елауларын
Карга күмеп, туктатты.
Тәрәзәләрдә бизәк булып,
Үзе йокыга талды.

* * *

Сизмәдем дә көннең узганын,
Җиргә эңгер төшкән, ләбаса.
Узып кына барган болытлар
Төн карасын эчкән, ләбаса.
Ярсу атта җилгән көзге җил
Хисләремне талый, лабаса.
Китә алмый калган бер торна
Күзләремә карый, лабаса...
Җан юлдашын таный, лабаса..

* * *

Күзләрне күтәп алам да,
Озакка сузар булам.
Күзләрдә – сагыну илендә
Мин үзем моң-зар булам.

Баланнар балланган чорда,
Миләшләр тулган айда;
Парын югалткан кош булып,
Җырда мәхәббәт кайта.

Китәргә ашыккан көзне
Тагын туктатыр булам.
Моңнар бишегенә салып,
Азга йоклатыр булам.

Күзләрне күтәп алам да,
Хушлашу авырлаша...
Моңнарым китә көз белән,
Яшь коеп, яңгыр аша.

## КАРЛЫГАЧЛАР

Күктә кояш.
Якты шатлык булып,
Көлтә-көлтә нурлар коелалар.
Табигатьтә илаһи бер мизгел...
Мәтрүшкәләр моңга коеналар.

Күк-гөмбәздә уйный карлыгачлар,
Оча алар күзем карасында.
Кабатланмас чаклар...
Җырлар кала,
Балачаклар – еллар арасында.

Томырылып шулай вакыт чаба,
Хатирәләр – күңел ярларында.
Бу хәятнең була җил-давылы,
Ява бозлар, ява карлары да.

Хәтер хәзинәсе – айлар, еллар,
Садә күңелемә уелалар.
Сөю белән сагыш һаман бергә
Йөрәгемә килеп сыеналар.

Карлыгачлар ярга оя ясый.
Күкрәгемә бәхет оялармы?
Кай якларга алып китәр икән
Карлыгачтай матур хыялларым?

* * *

Ак каеннар яланаяк
Суга кереп басканнар.
Әллә инде, кызлар сыман,
Яратудан шашканнар?
Чайкыйлармы яулыкларын
Кар суларына салып?
Сихерләнеп калганнармы
Күл-көзгеләргә багып?
Үзләренең гүзәллеген
Беренче күргәннәрме?
Сокландсыннар безгә, диеп,
Суларга кергәннәрме?
Кар суында ак каеннар...
Сөймәс җирдән сөярсең.
Кояш-егет көлә генә –
Тигез күрә һәммәсен.

podpiska.pochta.ru



*...Унике ел дәвамында шатлыкларын да, сагышларын да бергә бүлешеп атлаган парлы җырчыларның гаилә күгендә кинәт кара болытлар куерып, бергә язган язмыш китаплары бер мизгелдә урталай бүленде. Дистәләгән битләре ертылып алынды, бергә корган өметхыяллар җилгә очты...*

*Аларның исемнәре эстрада дөньясында һәм халык телендә “яңа сулыш” алганда, тамашачы әле берсен, әле икенчесен яклады. Күпчелек үзләрен үзләре кызганды, “Ә минем белән шундый хәл булса?!” – дигәндәй, гайбәттән бигрәк, гыйбрәт алды. Бу вакыйгалар чылбырында Русланның, югалып калмыйча, иҗатта үзен табуы, тамашачысының ышанычын аклавы күңелләргә яңа орлыклар салды: тамашачы ата-аналарча борчылды, аны аңларга тырышты, якын күрде, үз итте. Җырчының юлында гүя яңа сәхифәләр, яңа мөмкинлекләр ачылды. Иҗат юлы чын мәгънәсендә яңа сулыш алды. Тугры тамашачысының мәхәббәтенә җыры, моңы, тырышлыгы белән җавап бирде ул.*

*Бүген “Тулпар” журналында кунакта – талантлы җырчы, ике бала әтисе Руслан Кираметдинов.*

**Руслан КИРАМЕТДИНОВ:**

# *“Бәгырең таш булса, онытып кара”*

**БЕЛЕШМӘ**

Тулы исеме: ***Руслан Роберт улы Кираметдинов.***
Туган көне: ***1990 елның 29 ноябре.***
Туган җире: ***Татарстанның Яр Чаллы шәһәре.***
Яшәгән җире: ***шунда ук.***
Гаилә хәле: ***аерылган, улы Камил, кызы Ясминә.***
Кешеләрдә өнәмәгән сыйфатлары: ***икейөзлелек, ялган, хыянәт.***
Яраткан киносы: ***совет фильмнары, “Вечный зов”.***
Яраткан җырчысы: ***Салават Фәтхетдинов, “Queen” рок төркеме.***
Яраткан ел фасылы: ***язын дөнья чәчәк аткан мизгел.***
Тормыш девизы: ***“Алга!”***
Тормыш баскычлары: ***1997-2008 елларда Яр Чаллы шәһәренең 29нчы урта мәктәп укучысы; 2008-2012 елларда И. В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте студенты; 2009-2014 елларда Мәскәү дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының Яр Чаллы филиалы студенты.***

**– Руслан! Сүзне иң беренче иҗат иткән җырыгыздан башлыйк әле. Чөнки ул Сезнең репертуарда мөһим урын алып тора. Хәтта бүгенге күңел халәтегезгә дә туры килә кебек...**

– Тугызынчы сыйныфта укыганда, дустым Руслан Яһүдин белән беренче җырыбызны иҗат иттек. Тарих дәресе иде. Ул – сүзләрен, мин көен яздым.

*Күзләрең кара, йөрәгем яна.*
*Бәгырең таш булса,*
*онытып кара...*

podpiska.pochta.ru

Күп тә үтми, җыр радиодан яңгырый башлады. Аннан инде "Бәгырең таш булса"ны берничә тапкыр яңарттым. Унҗиде ел бу җырга. Бервакытта да репертуарымнан алмадым.

Нәкъ шушы җыр белән минем иҗат юлым башланды. Аннан Венера Мәхмүтова сүзләренә "Ак карларны ерып барам" җыры язылды. Сүзләре ошады. Шулай ук "Сабыр итү", "Күзге яңгыр юып үтәрме?" җырларын үзем иҗат иттем.

2012 елда Казан музыка көллиятен тәмамлап, туган шәһәремә кайткач, беренче концертымны оештырдым. Төнлә шәһәр буйлап афишалар элеп йөрдем, көндез утыз градус салкында, базарда җырлап торып, билетларымны саттым. Сәхнә юлына беренче адымнарым шулайрак ясалды.

**– Ә ни өчен нәкъ иҗат юлын сайладыгыз? Әңгәмәләрегездә еш кына, шәһәрдә туып-үсүегезгә карамастан, авыл җанлы булуыгыз, техникага тартылуыгыз турында ассызыклыйсыз. Белүебезчә, соңгы елларда урманчылык белән дә шөгыльләнеп алдыгыз.**

– Балалар бакчасыннан ук җырга тартылуымны сизеп алганнар. Баян классында да укыдым. Әмма артык шук, тиктормас идем. Спорт түгәрәгенә дә бирделәр. Көрәш белән шөгыльләндем, сабантуйларда җиңеп, тәкәләр ала идем.

Ленар абыем белән безнең җәйге каникуллар авылда үтте. Әтием Роберт Фәтхетдин улы – Минзәлә районының Сарсаз авылыннан, әнием Рәмилә Габдрәүф кызы – Лениногорск районының Яңа Иштирәк авылыннан. Әти – электр монтажчысы, әни пешекче булып эшләде. Ә без техникага кызыга идек. Берничә секундта "КамАЗ" двигателен сүтеп җыя идем. Икетуган абыйларыбыз белән "ЗИЛ", "КамАЗ", комбайннарда йөрдек, кыр-басуларда үтте балачак. Укып беткәч, авылга кайтып, эшкә керәсем килде. Ленар абыем техника юлын сайлады, бүгенге көнне заводта станоклар көйли. Күркәм гаиләсе белән Ижау шәһәрендә яшиләр.

Соңгы елларда урман кисү белән шөгыльләнүем күңел таләбе түгел, әлбәттә. Ковид вакыйгалары бер мизгелдә артистларны эшсез итте. Техника сатып алып, башка юнәлештә эш башлап карадык. "КамАЗ" белән батып калган чаклар, салкыннарда ягулык туңып, урманда үсеп утырулар, оясындагы күчне урыннан кузгатып, сагызак һөҗүме астында калулар, өстеңә агач ава язып, гомер юлың бер мизгелдә күз алдыннан үтүләр – барысы да булды. Шулай да киләчәктә авылга кайтып, табигатькә якынрак булу хыялы белән яшим мин.

**– Якыннарыгыз белән сердәшме Сез?**

– Әти-әни – иң кадерле кешеләребез, алардан да ныграк кем безне аңлый ала? Әти-әниемә бик рәхмәтлемен, алар һәрвакыт минем өчен терәк-таяныч. Мин дә газиз кешеләремнең ышанычларын акларга тырышам. Әти безне сүз белән тәрбияләде. Мәктәптә укыганда, кызыгып, малайлар белән тәмәке тартып карадык. Сизеп алып, орышты гына, әмма бервакытта да кулына каеш алганы булмады. Ә менә шуклыгым аркасында әнидән эләккәләде.

Ленар абыем, киресенчә, тыныч холыклы. Төптән уйлап эш итә. Аның белән еш аралашып торабыз.

**– Иҗат мәсьәләләре, репертуар сайлау, уңышларыгыз турында кем белән бүлешәсез?**

– Күбрәк дустым, директорым Айдар Сәфәргалин белән киңәшләшеп эшлибез. Без аның белән мәктәп елларыннан таныш. Шәһәр чараларында очраша идек. Ул концертларда беренче алып баручым да булды. Аннан мәгариф өлкәсенә китте. Чаллы татар дәүләт театрын да җитәкләде. Авыр чакларда ул



*Кечкенә чакларда.*



*Әнисе Рәмилә белән.*



*Яшьлек үзе матур.*

podpiska.pochta.ru



*Сәхнәдә.*



*Салават Фәтхетдинов белән.*



*Җырчылар Гүзәлия һәм Айдар Галимов янәшәсендә.*

ярдәмгә килде һәм бүген оештыру эшләрен дә, иҗат мәсьәләләрен дә аның белән бергә хәл итәбез.

**– Иң кадерле тамашачыларыгыз?**

– Якыннарым, балаларым. Бүгенге көнне әтием ягыннан Фәйрүзә әбием исән. Телевизорда күреп кенә калса да, бик сөенә.

**– Тамашачы бүләк иткән чәчәкләрне өегезгә алып кайтасызмы?**

– Бүләк итәм: оештыручыларга, мәдәният йортында эшләүче хезмәткәрләргә, идән юучыларга.

**– Яраткан ризыкларыгыз бармы?**

– Барысын да ашыйм. Үзем дә бик тәмле пешерәм. Бәлешләр дә сала беләм. Әнием пешергән ризыкларны үз итәм.

**– Бүгенге көнне күңелегездә нинди хисләр саклыйсыз?**

– Балаларыма мәхәббәт, эшкә мәхәббәт, якыннарыма һәм тамашачыларыма рәхмәт хисләре.

**– Яңадан гашыйк булырга әзерме Сез?**

– Бүген – юк. Кемгәдер вәгъдәләр бирергә әле әзер түгелмен. Алдагысы күрсәтер.

**– Ә бәхет? Бәхетле булу өчен...**

– Бәхет дигәне – минем өчен исәнлек-саулык. Якыннарымның, балаларымның сау-сәламәт булуы. Нинди машинада йөрүеңдә дә, нинди фатирда яшәвеңдә дә, нинди телефон белән куллануыңда да түгел бәхет. Бу дөньяларга ничек киләбез, шулай китәбез.

**– Мәктәп елларына әйләнеп кайтсак, күп кызлар Сезгә гашыйк идеме?**

– Мин кызлар артыннан чабып йөрмәдем. Әлбәттә, гашыйк була иделәр. Арттан үзләре йөргәннәре дә булды. Син игътибар итмәгән саен, алар ныграк йөри иде.

**– Бәлки, бердәнберегезне көткәнсездер?**

– Көттем, таптым һәм...

Музыка училищесында укыганда таныштык. Ул – тугыздан соң, мин унберенче сыйныфтан соң укырга килгән идек. Бер парта артында утырдык. Класста өч кенә малай иде. Әмма барысы да үзгәрде... Бу дөньяда бөтенесе дә вакытлыча. Хәтта үпкә хисе дә вакытлыча. Һәркайсыбызга акыл телим.

**– Уйламаганда килеп төшкән сынауларны җиңеп чыгарга кем ярдәм итте?**

– Әти-әнием, туганнарым, дусларым, тамашачым. Беренчеләрдән булып, Фирдүс Тямаев шылтыратты. Ул безнең кияү. Тормыш иптәше Резидә белән туганнар без. Эш һәм иҗат мәсьәләләре буенча, әйтеп үтүемчә, директорым Айдар Сәфәргалинга таянам.

Әлбәттә, мин ышана алмадым. Минем якын кешем, балаларымның әнисе – бу хәлләр булырга мөмкин түгел дип уйладым...

**– Әниегезнең күңеле ничек кичерде боларны?**

– Әни икенче көнне үк шылтыратты, ялгызым калдыруларын үтендем, бер атна буе мин үз уйларым, үз кайгым белән калдым. Аннан әти-әни янына кайттым.

**– Программагыз “Ничек җырламый түзим соң?” дип атала иде. Тамашачыга әйтер сүзләр шушы бер җөмләгә сыйды... Бу вакыйгалар шаукымы тәэсирендә, яңадан тамашачы каршына чыгарга курыкмадыгызмы?**

– Халыкка ышанычым зур иде. Минем белән бергә барган тамашачыма ышандым. Сәхнәне яратып чыктым.

Беренче концертыбыз Минзәлә шәһәрендә үтте, аннан Чаллыда концертлар куйдык. Тамашачы шыгрым тулы заллар белән каршы алды. Татарстанның бик күп районнарында чыгыш ясадык. Былтыр йөзгә якын концерт куйдык. Барысына да рәхмәтлемен.

**– Иҗаттан башка яраткан шөгылегез бармы?**

– Бүгенге көнне беренче урында – иҗат. Ял итмим, диярлек. Йокы да туймый. Буш вакыт булса, балалар белән үткәрергә тырышам. Аралашып торабыз. Әлбәттә, безнең аерылышуны

nadpiska.pochta.ru

алар кабул итми. Алар мине көтә. Мин гаиләмне ташлап чыгып китмәдем.

**– Әгәр Сез укытучы булсагыз, укучыгыз Руслан Кираметдиновка нинди билгеләр куяр идегез?**

– Эшендә бишлегә тырышуын теләр идем. Тәртибе төрлечә булырга мөмкин. Чөнки балачактагы шуклык та, кызулык та бар. Әмма тиз сүрелә.

**– Үкенәсезме?**

– Үкенмим. Һәрнәрсәнең үз вакыты. Шулай булырга тиеш булган. Үч сакламыйм, таш белән атсалар да, аш белән атарга тырышам. Әмма нинди очракта да артка юл юк, үземне хөрмәт итәм. Горурмын, үземне үзгәртә алмам...

**– Елаган чакларыгыз буламы?**

– Ир-егетләр дә елый. Без бары тик күрсәтмибез. Күңел тулган чаклар була. Күз яшьләре килеп тыгыла. Машинама утырып елаганым да булды...

**– Бүгенге күзлектән караганда, кайда ялгыштыгыз?**

– Иҗат кешесен ниндидер ялган әйберләр, начар дуслар алдарга мөмкин. Заман чире – кешеләргә социаль челтәрләр нык тәэсир итә. Хатын-кыз бәйсез булырга тиеш дип, төрле психолог, нумеролог һәм башка “секта” форматында дип әйтикме, акылны томалаучылар бар.

Бүгенге көнне бик күп парлар аерылыша. 80 процент очракта хатын-кыз беренче адым ясый. Нидер җитми... Мәхәббәт – ул бер мизгел, өйләнешкәч, ике-дүрт ел булырга мөмкиндер. Аннан хөрмәт һәм ышаныч калырга тиеш. Тик соңыннан терсәкне тешләсәң дә, өйләнеп кайтып булмый.

Ни өчен мөселман илләрендә тәртип? Ә бездә, бәлки, нәкъ хатын-кызның бәйсезлеккә омтылуы да шундый нәтиҗәләргә китерәдер.

**– Чит илдә ял иткәнегез булдымы?**

– Юк. Диңгезне күргәнем дә булмады, миңа барыбер. Мин шундый кеше: су буенда тик кенә кызынып ята алмас идем. Тарихи урыннарда йөрү, төрле халыкларның фестивальләрендә катнашу кызыграк булыр иде. Әлбәттә, киләчәктә балаларым белән бергә сәяхәт итәргә теләр идем.

**– Ничек уйлыйсыз: бүгенге көнне яхшы эш хакы аласызмы?**

– Байлыкка кызыкмыйм, кеше акчасын да санамыйм.

**– Яңа иҗат мизгеленә нинди уй-фикерләр белән аяк басасыз?**

– Яңа программа турында күп уйланам. Чит ил җырчыларын тыңлыйм. Үзебезнең эстраданы читтән генә күзәтәм. Тере тавышка җырлауны яратам. Сыйфатлы музыканы гына сәхнәгә чыгарасы килә. Тамадаларның зур сәхнәләргә чыгып җырлавын аңламыйм. “Плюс”ка җырлауга каршымын. Халык хәләл акчасын чыгарып, билет сатып алып килә, без аларга тиешле дәрәҗәдә концерт куярга тиешбез.


Бүгенге көнне төркемемдә уналты кеше. Алты музыкантым бар, тере тавышка концерт программасы әзерләдек.

**– Башкортстан тамашачысына әйтер теләкләрегез?**

– Башкортстанда җыр яраткан, моңлы һәм рәхмәтле тамашачы яши. Һәр җырчыны җылы алкышларга күмә, күтәреп ала. Уфаны бик яратам. Кадерле тамашачымны концертларымда көтеп калам.

**– Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт! Киләчәктә матур уңышлар, имин юллар телибез. Бәхетле булыгыз!**

*Әңгәмәдәш – Дилә МӨХӘРРӘМ-ХӘЙРЕТДИНОВА.*



*Шатлыклы мизгелләр.*



*Кызы Ясминә, улы Камил белән.*



*Балалар – безнең киләчәк.*

podpiska.pochta.ru



*Уфада Мәрьям Солтанова-Акчурина исемендәге зыялылар клубы оешуга биш ел тулды. Шушы чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә ул бик күп чаралар уздырган. Клубның җитәкчесе Нәфисә Акчурина оешманың тарихы, эшчәнлеге турында фикерләре белән уртаклашты.*

# Максатыбыз – халыкка мәгърифәт тарату

***– Сүзне тарихтан башлыйк. Башкортстан татарлары зыялыларының клуб форматында оешу идеясе сездә барлыкка килеп, гамәлгә ашты. Соңыннан сезнең үрнәккә башкалар да иярде. Клубны нинди максат белән оештырдыгыгыз?***

– Клуб форматына дискуссия, фикер алышу мәйданы кирәклегеннән тукталдык. Әлеге формат зур акчалар таләп итми, бухгалтериясен алып барасы да, хисап бирәсе дә юк. Аны галимнәрне, белгечләрне чакырып үзебезне кызыксындырган темаларга лекцияләр тыңлау максатыннан оештырдык. Чөнки аерым темаларга мәгълүмат табу бик авыр. Татар һәм ислам тарихы, мәдәният, аерым шәхесләребез турында күбрәк беләсебез килә. Милләтне саклап калуда диннең, мәгърифәтчелекнең һәм иганәчелекнең өлеше зур дип исәплим. Шуңа төп максатыбыз – халыкка мәгърифәт тарату. Биш ел эчендә без илледән артык лекция уздырдык, экскурсияләр оештырдык, Мәрьям Солтановага тактаташ ачтык. Клуб оешкан мәлләрдә утырышларны тар аудиториядә башласак, тора-бара ул зурайды. Соңгы өч елда без утырышларны видеога төшереп, Интернетка куеп барабыз. Бу исә яңа мәгълүмат зур аудиториягә барып җитә дигән сүз.

Беренче утырышны 2018 елның 3 октябрендә үткәрдек. Ул этнос һәм этник билгеләнеш мәсьәләләренә багышланды. Тарих белгече Илдар Габдрәфыйков Европаның илләрендәге этник төркемнәр мисалында гореф-гадәтләрне, мәдәниятне саклау буенча күзәтүләре белән уртаклашты. Шулай, беренче утырышны ук җитди темадан башладык.

***– Кайбер утырышларда миңа да катнашырга туры килде. Русиянең атказанган, Башкортстанның һәм Татарстанның халык артисты, сәнгать фәннәре кандидаты Идрис Газиев, тарих фәннәре докторы Фаил Сафин, этносәясәтче, тарих фәннәре кандидаты Илдар Габдрәфыйков, “Ихлас” мәчетенең имам-хатыйбы Альфред Дәүләтшин, Татарстан Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Миркасыйм Госманов исемендәге үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты, якташыбыз Илнур Миргалиев белән узган чаралар бик фәһемле булган иде.***

– Әйе, Илнур Миргалиевның чыгышына аерым тукталасым килә. Ул утырышта “Алтын Урда: тарихы һәм бүгенгесе” дигән темага лекция сөйләгән иде. Галим чыгышында Алтын Урда тарихын өйрәнү торышы, чыганаклар мәсьәләсе, үзәк тарафыннан чыгарылган китаплар турында мәгълүмат бирде. Шулай ук, Алтын Урданың Монгол империясеннән аерылып, дәүләт буларак формалашуы, Ислам динен кабул итүе, диннең урыны, дәүләтнең сәяси һәм икътисади яктан ныгу тарихына да тукталган иде.

“Алтын Урда безнең этник тарихыбызда төп этап булган, чөнки биредә нәкъ бүген яшәгән татар формалашкан. Безнең дәүләтчелек тарихыбыз, бөтен Евразиядә танылуыбыз, татар әдәбиятының, мәдәниятенең нигезе шунда ята”, – диде ул. Башка спикерларның чыгышларында да фәһемле фикерләр күп булды. Шул ук Илнур Миргалиев быел февраль аенда тагын бер лекция белән чыгыш ясады. Анысы “Идегәй тарихта һәм дастанда” дип аталды, онлайн рәвештә узды.

***– Агымдагы 2023 ел Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы тарафыннан Дастаннар елы дип игълан ителгән иде. Сез дә бу чарадан читтә калмадыгыз кебек.***

– Әйе, Дастаннар елы уңаеннан узган беренче чарада онлайн лекция тыңласак, соңрак инде җыелып “Идегәй”не укулар һәм фикер алышулар уздырдык. Әйтергә кирәк, моңа кадәр дастаннар турында мәгълүматыбыз бик сай иде. Баксаң, дастаннарны өйрәнеп балаларда һәм, гомумән, киң җәмәгатьчелектә милли үзаң тәрбияләп була икән. Минем “Идегәй”дән башка дастан

podpiska.pochta.ru

турында ишеткәнем дә юк иде, алар йөздән артык икән. “Идегәй”не дә төрле кеше төрлечә кабул итә иде. Идегәйнең күпкырлы шәхес булуын аңладык.

“Идегәй”дә, әлеге дә баягы, милләтнең таркаулыгы, ил тоткан ирләрнең үзара сугышуы, бер-берсен кимсетүләре, минминлекләре, ил язмышын түгел, ә үзләрен кайгыртулары турында сүз бара. Дастанында яңгыраган вакыйгалардан без рухи сабак алдык. Бердәм булмауның милләтне таркатуга алып килгәненә инандык. “Идегәй“ дастаны безне кисәтә, уята торган әсәр дигән уйга килдек.

*Мин очаем дисәм, канат юк,*
*Кунаем дисәм, койрык юк.*
*Барырыма җирем юк.*
*Батарыма күлем юк:*
*Алдым биек, артым яр,*
*Әйләнергә җирем тар!*

Бу юллар, һичшиксез, уйланырга мәҗбүр итә.

Халкыбызның классик мирасын күмәкләшеп өйрәнү Мәрьям Солтанова-Акчурина клубының яңа бер тәҗрибәсе булды. Дөресрәге, онытылган гадәткә яңа эчтәлек салу булды ул. Без бу тәҗрибәне дәвам итәчәкбез, чөнки ул безгә фикер алышу мөмкинлеге бирә, офыкларыбызны киңәйтә. Киләсе очрашуларда Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасын, Сәйф Сараиның “Сөһәйл белән Гөлдерсен” дастанын укыячакбыз.

***– “Татар кызы” республика бәйгесен оештыру да сезнең җилкәгә төште. Шуны да искә алып үтик әле.***

– “Татар кызы” бәйгесен “Берлек” оешмасы оештырды һәм финанслады. Мин ул оешмада башкарма директор вазифасын алып бардым. Аңа кадәр бәйге “Нәүруз гүзәле” исеме астында үтә иде. Аның бюджеты бик зур иде – ярты миллионнан бер миллион сумга кадәр тәшкил итте. Бәйгене дүрт тапкыр үткәрдек. Без анда халкыбызның яшәешеннән чыгып, татар кызының җыелма образын тудырырга тырыштык. Ул заманда бу мөһим чара буларак күренә иде. Хәзер мин андый бәйгеләргә бөтенләй башка караштa торам. “Татар кызы” бәйгесенең “файдалы нәтиҗә коэффициенты” бик югары түгелдер дип уйлыйм. Аны үзешчән дәрәҗәдә түгел, камерный залларда, һөнәри югарылыкта уздырырга кирәк, ә бу зур чыгымнар таләп итә.

***– Зыялылар клубы бер дә юкка гына Мәрьям Солтанова исемен йөртмидер. Ул яшәгән йортка тактаташ кую да сезнең тырышлык белән башкарылды.***

– 2019 елда Мәрьям Солтанованың тууына 160 ел тулган иде. Шул уңайдан аның исемен мәңгеләштерү чаралары уздырдык. Уфаның Тукай урамында, Русия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте каршында урнашкан тарихи бинага тактаташ куйдык.

Мәрьям Солтанова Уфада гына түгел, бөтен төрки дөньяга билгеле шәхес. Ул ире вафат булганнан соң шушы йортны ятим балаларга биргән. Милләтенә, диненә карамый ятим балаларны урамнардан җыеп, ашатып, киендереп, белем биреп, зур тормышка әзерләгән. Кызларны кияүгә биреп, аннан соң да язмышлары белән кызыксынып торган. 1906 елда Русиядә беренче хатын-кызлар мөселман хәйриячелек оешмасы төзегән. “Галия” мәдрәсәсенә, картлар йортларына бик күп ярдәм күрсәткән. Аларның гаиләсе Зәки Вәлидиләр гаиләсе белән бик дус булган. 1926 елны ул абыйлары белән хаҗга барып кайткан. 1928 елда авырып Мәскәүгә киткән һәм анда вафат булып, мөселман зиратына күмелгән. Без аның каберен дә эзләп таптык, ел саен зиярәт кылып, догалар укып кайтабыз.

Мәрьям Солтанова хәйриячелек, мәгърифәтчелек белән шөгыльләнгән, аның исеме тарихта алтын хәрефләр белән язылырга лаек.

***Әңгәмәдәш – Мөнир ВАФИН.***



podpiska.pochta.ru



# Су анасы яки квадрокоптер маҗарасы

*Хикәя*

1

Кәримне Өчиледә барысы да белә. Ул алай начар малай түгел. Кайчан карама, теге яки бу эш белән мәшгуль. Укудан кайткач, өйне җыештыра, савыт-сабаны юа. Соңыннан малларны карый. Тыштагы эшләрен бетереп керүгә, әнисе дә кайтып җитә.

Гөлфия апа район үзәгендәге дәваханәдә шәфкать туташы булып эшли. Эше тыгыз булса да, өен бик чиста һәм пөхтә тота, кош-корт, мал-туар асрый, һушыңны алырлык матур гөлләргә күмелгән бакча үстерә һәм улы Кәримнең бернәрсәгә дә мохтаҗ булмавын кайгырта. Кәрим әнисен бик ярата. Үзенә унөч яшь кенә булса да, гаиләдә ир-ат вазыйфасының аның кулында икәнен яхшы аңлый.

Әтисенең аны соңгы тапкыр алдына утыртып яратканына, үзе кичергән төрле вакыйгаларны тәмләп, кызыктырып сөйләвенә, чәнечке сыман мыеклары белән улының сипкелле битен кычыттырып үбүенә инде җиде ел вакыт үткән. Әмма җиде ел элек булган фаҗига кичә генә булган кебек тоела...

Бу куркыныч хәл февраль аенда булды. Ул елны яз иртә килде. Кәримнең әтисе ял көннәрендә балык тотарга ярата иде. Җәйме, кышмы – мөһим түгел. Балык тотканда ул гүя үзенең эчке борчуларыннан, тынгы бирмәгән уйларыннан котыла иде сыман. Менә ул көнне дә, эш пошуын басам дипме, балыкка китте. Тик, күрәсең, язгы бозга ястык калынлыгы булса да ышанма, диюләре юкка түгел...

Шушы вакыйгадан соң Кәрим нык үзгәрде. Аңа тиз арада өлкәнәергә, малайдан чын егет булырга, чыныгырга туры килде. Өйдәге авыр эшләр хәзер аңа калды. Башта әнисе белән икесенә генә авыр булды. Тик вакыт узган саен, алар мондый яшәү рәвешенә өйрәнә төште.

2

Өчиле авылы зур түгел. Монда бары тик ике йөзләп кеше яши. Ул искиткеч матурлык кочагында урнашкан. Әйтерсең табигатьнең иң-иң матур өлешләрен нәкъ шушы авыл тирәсенә җыйганнар. Саф чиста сулы чишмә, чылтыр елга, ачы җилләрдән саклап, авылны үз кочагына алган таулар, җиләк-җимешле аланнар, куе урман һәм авылдан ерак түгел – буа. Болар барысы да авылга ямь биреп, аны тагын да матурлый иде.

Ул буа – үзенә бер гаҗәеп урын. Бераз тылсымлы, серле дисәң дә, ялгыш булмас. Буа тирәсендә озыноозын камышлар үсә, абага белән какы да очрый. Ярдагы чытырманлык шундый куе һәм биек, хәтта буа яныннан берничә адымга гына китсәң, су керүче кешеләр күренмәс була.

*Алинә Рөстәм кызы Сабитова 2003 елның 9 ноябрендә Бүздәк районының Иске Актау авылында туган. Әнисе авыл мәктәбендә балалар укыта, әтисе авыл хуҗалыгы оешмасын җитәкли. Гаиләдә кече яшьтән үк туган телгә, милли гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләнә.*

*Алинә 5-6 сыйныфларда укыган чагында ук төрле иҗади конкурсларда ("Җанлы сүз", "Илһам – 2019", "Тукай вайбын тот" һ. б.) катнашып, призлы урыннар ала башлый. Шигырьләре, хикәяләре Татарстан һәм Башкортстан журнал-газитләрендә һәрдаим басылып тора.*

*Каран урта белем бирү мәктәбен алтын медальгә тәмамлагач, М. Акмулла исемендәге БДПУның татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Хәзерге вакытта ул 3нче курс студенты.*



Алинә САБИТОВА

Кичен буа тагын да шомлырак тоела. Кояш бату белән суның җаны барлыкка килә сыман. Әгәр тәүлекнең шушы вакытында биредә берүзең калсаң, үзең дә теләмәстән, бөтен тәнеңне калтырау биләп ала. Әкрен генә искән салкын җил дә әллә ни пышылдаган кебек, башыңда төрле куркыныч уйлар пәйда була. Шуңа күрә кояш баеганнан соң буага баручы кеше дә юк. Әйе, куркынычрак монда.

Авылда моны барысы да белә. Тик беркем дә тегеләйболай кычкырып сөйләп йөрми. Элек-электән шундый бер риваять билгеле. Янәсе дә, әлеге буада Су анасы яши, ди. Ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк. Бу Су анасы монда авыл салынганчы ук булган, диләр. Кичен буага килгән кешеләрне юри куркыта икән. Ә суга я тирә-якка чүп ташлап, табигать бозып йөрүчеләрне су астына, үзенең дөньясына алып кереп китә икән!

### 3

Тып та тып... Яңгыр инде бер атна туктамый. ...Су өстенә төшкән һәр тамчы түгәрәк-түгәрәк боҗралар хасил итә. Ул дүңгәләкләр буа буенча йөгереп барабара да юк була. Тирә-якта бер кеше юк, тыныч. Бу кешесез тынычлыкны бары тик яңгыр астында шыбырдаган яфраклар, челтерәгән су тавышы гына боза.

Бермәл буа читендә ниндидер калкулык пәйда булды. Бер мизгелдә ул халыкта йөргән сүзнең чынбарлыгына әйләнде. Ләкин ул әкиятләрдәге кебек бер дә куркыныч, ямьсез түгел. Киресенчә, озын матур чәчле, сөйкемле йөзле, озын керфекле, ямь-яшел күзле, алсу битле кыз!

– Әйбәт булды әле бу, – дип, ягымлы тавышы белән үз алдына сөйләнеп җибәрде Су анасы. – Көннең буена балалар су керә, бер тынгы юк. Әй, яңгыркаем, әл дә явасың! Яу, яу әйдә!

Ул алтын тарагын алды да озын толымнарын иплэп кенә тарый башлады:

– Их, нигә мине яратмыйлар микән? Мин бит кешеләр өчен тырышам. Әгәр мин булмасам, шушы буа калмас та иде, мөгаен. Пычратып, ямьсезләп, сазлыкка әйләндерерләр иде. Суга төшергән каз-үрдәкләрен козгыннар ташып бетергән булыр иде. Кая әле, берсе дә булмаганда, җайлап кына авыл тирәсен караштырып чыгыйм. Бар да тәртиптә микән?

Су анасы суга чумды да тиздән калкып чыкты. Кулында нәрсәләрдер бар. Чирәмгә утырып, берсен сөрткәләп, сыпыргалап, читкә алып куйды. Аннан икенчесен алды. Бер төймәсенә басуга, тегесе, һавага очып менеп, безелди башламасынмы?! Менә могҗиза, менә тылсым! Су анасы төймәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә баса. Һавадагы теге нәрсә я тегеләй, я болай оча. Әкият...

Бу серле очкыч – квадрокоптер. Ягъни Су анасының дроны бар. Авылда мондый очкыч әлегә бердәнбер, һәм ул бары тик Су анасында гына.

Менә ул квадрокоптерын бераз һавада йөртеп көйләгәч, аны авылга таба җибәрде. Очкычның юлы, нәрсәләр күргәне – барысы да Су анасына пульттагы экраны аша күренеп тора. Дрон авыл өстенә очып барып күзәтә башлады. Барысы да тәртиптә шикелле. Яңгыр яву бик уңай булды әле. Күп кеше өендә генә утыра, тышка чыкмый. Димәк, мондый сәер әйбернең кеше күзенә күренү ихтималы да кими.

Дрон бар тирә-якны карап чыгып, кире борылганда, кинәт экранда рәсем бетте. Су анасы пультны селкетеп тә карады, төймәләргә дә басты, тик бәйләнеш өзелде дә куйды.

### 4

Яңгыр туктады түгелме соң? Әһә! Туктады! Баядан бирле тәрәзә пыяласында бер-берсе белән узышкан яңгыр тамчыларын, урамдагы күлләвекләрне күзәтеп утырган Кәрим: "Мин – тышка!" – дип, тиз генә курткасын элде дә, әнисенең җавабын да көтмичә, чыгып чапты.

Тышта шундый рәхәт!.. Бар дөньяда сафлык, яңа явып үткән яңгыр исе. Сулыш алулары иркен. Рәхәт. Агач яфраклары юпь-юеш, аларны чак кына селкетсәң, душ астында каласың. Яңгыр тамчылары, энҗе-мәрҗән кебек, әле монда, әле тегендә җемелди.

Шушы матурлыкка соклана-соклана, Кәрим урам башына килеп җитте. Монда аның яраткан имәнлеге бар. Бу агачларны аның әтисе Кәрим кебек чагында утырткан. Хәзер инде алар зур, нык. Егет бу урынны әтисе үлгәннән соң тагын да ныграк якын итә башлады. Якынрак торган ике агач арасына таган ясады, буш вакытларын монда үткәрә башлады. Әтисе кебек, ялгыз калырга ярата иде.

Әле дә ул шушы имәннәр янына килде. Таганда атынырлык түгел – такта лычма су. Кәрим бер имәннең ботагына тотынып, бер мизгелдә агач башына менеп

podpiska.pochta.ru

тә кунаклады. Биектән табигать тагын да матурраклап тоелды аңа. Шулчак каяндыр безелдәү тавышы ишетелде.

"Кара әле, яңгыр туктады, ә болар инде эшкә дә чыккан!" – дип, бер-ике ботак аска төшеп, яшеренебрәк утырды. Бал кортларыннан курка иде ул. Тик бу безелдәвек бал корты түгел ләса! Имәннәр янында әйләнгәләп оча да оча. Нәрсә соң бу?

Су анасының квадрокоптеры иде бу сәер әйбер. Ә Кәрим аны якыннан үткәндә бәрде дә төшерде. Тиз-тиз генә җиргә төшеп, әлеге табылдыгын карый башлады. Тик күпме генә боргаласа да, нәрсә икәнен аңлый алмады.

Бу очракта таныш түгел әйберне шунда калдыру, я булмаса, гомумән, аңа тимәү кирәк иде. Әмма алай итсә, Кәрим ул Кәрим дә булмас иде шул. Берәр әйбер кыек ята икән, Кәрим аны шалт чәлдерергә генә тора. Аны бу гадәте өчен күпме тиргәделәр инде. Тик ул тыела алмый шул.

Шулай итеп, ул бу сәер әйберне, күп уйлап тормыйча, култык астына кыстырды да өенә чапты. Тиз генә кайтып җитеп, табылдыгын үзе йоклаган караватастына яшерде. Иртәгә әни эшкә киткәч, иркенләп сүтеп карармын әле дип, йокларга ятты.

Икенче көн егет өчен бик уңай булды. Төштән соң Гөлфия апа тәүлек дежурствосына китте. Өйдә ялгыз гына калу белән, Кәрим караватастыннан теге нәрсәне тартып чыгарып, иркенләп караштыра башлады. Ул аны боргалады да, сыпырып та карады, селкетте дә, төймәләренә дә басты, әмма нәрсә булуын гына төшенә алмады.

Шулай бераз уйланып утыргач, аның башында бер даһи фикер туды. "Ә-ә-ә! Менә нәрсә! Бу әйбер үзе тимердән эшләнгән, үзенең авырлыгы да бар, шөрепләре дә күренә. Очарга дип җайланган таяклары да. Аңлашылды!" – диде дә дронны тиз генә кире урынына куеп, тышка, маллар янына чыгып китте.

Һавада бүген болытлар сирәк. Кояш алар арасыннан бар дөньяга шатлык чәчә. Кәримнең сипкелле битенә төшкән нурлар аңа тагын да сөйкемлелек өсти. Егет, җылы нурлар астында иркәләнә-иркәләнә, кояш яктысында күзләрен челт-мелт йомып, үзенә генә билгеле булган тирән уйларга чумып китеп бара. Иртәгә иртән үк табылдыкны Таһир абыйга илтергә кирәк. Тимере шактый күп, төшеме дә әйбәт булыр...

Кәрим эшләрен бетереп, өйгә керүгә кояштан офыкта тик бер алтын сызык кына калган иде. Бераздан ул да җир читенә кереп югалды. Егет арыган иде, иртәгәсе көнне тизрәк җиткерер өчен, ул йокларга урын әзерли башлады. Шул заман караватастыннан теге әйбер очып килеп чыкмасынмы?!

Кәрим гөп итеп урынына утырды. Теге галәмәт өй эчендә әле тегеләй, әле болай очарга кереште. Үзе әллә нинди тавыш белән безелди, сәер, шомлы итеп пипелди. Өй эчендә әрле-бирле очып, чаршауларны, пәрдәләрне җилфердәтеп, өстәлдәге вазаны төшереп ватты. Аннары яшен тизлеге белән тәрәзәне ватып, тышка чыгып олакты.

Әлеге берничә минут Кәрим өчен бер гомер булып тоелды. Тиз генә ишекне чыгып элде дә, тәрәзә пәрдәләрен тартып, йокларга ятты.

Ләкин бу вакыйга аңа һич тынгы бирмәде. Башыннан төрле-төрле уйлар су булып акты. Ичмасам, әнисе дә өйдә түгел. Бераз тынычланып, төнге икеләр тирәсендә генә йокыга талды.

**5**

Су анасының бик кадерле ярдәмчесе – "уң кулы" югалганга бер тәүлек вакыт үтеп бара иде инде. Кыз тәмам күңелсезләнгән, зәбәрҗәттәй күзләрендә нур сүнгән иде. Тик бер өмет бар әле: бу очкыч – заманча технологияләр белән эшләнгән. Ул терәк пунктына кире кайтырга өйрәтелгән. Ары-бире хәл була калса, тәүлек эчендә көч җыя да, кабынып, хуҗасына кайта. Бәхеткә каршы, шулай булып та чыкты.

Су анасы, аның кайларда булганын белергә теләп, GPS-навигатор ярдәмендә, очкычның юлын тикшерә башлады. Озак үтмичә, ул каракның кем икәнен ачыклады. Әһә! Бу тагын Кәримнең эше! Тә-ә-әк, моны болай гына калдырып булмый дип, хәйлә кора башлады Су анасы.

Бу вакытта исә Кәрим тынычланып, сабый балалар кебек тәмләп йоклап ята иде. Әллә нинди матур төш тә күрә. Янәсе, ул картәнисе белән картәтисендә кунакта. Тышта челлә, һава мунчадагы сыман бөркү. Мондый көнне тик бер теләк: елгада су коену. Кәрим тастымалын җилкәсенә элде дә су буена төшеп китте. Әмма төшеп җитә алмады, кинәт бер бал корты килеп бәйләнә башлады. Башта моңа исе китмичә, күрмәмешкә салышса да, куркy хисе барыбер җиңде: ул, куллары белән селтәнгәләп, чәчләрен сыпырып, йөгерә үк башлады. Сәер, бал корты үзе күренми, ә тавышы ишелә. Безз-безз...

Кәрим кинәт күзләрен ачты. Аның баш өстендә баягы әкәмәт очкыч асылынып тора иде. Егетнең йөрәге табанына төште. Күзләре шардай ачылды, еш-еш тын алды. Аркасыннан, маңгаеннан тир тамчылары бәреп чыкты. Үзе дә сизмәстән, чигенә-чигенә, караватының башына килеп җитте.

Шул мәлдә дрон кеше тавышы белән сөйләп җибәрмәсенме?!

– Син! Син мине бәреп төшердең! Син мине урладың! Мине тимер-томырга илтеп бирергә уйладың! Карак! Бур!

Төшме бу, өнме – егет буталды. Куркуыннан типкән йөрәк тавышы бар дөньяга ишетелә кебек тоелды.

Кәрим, тотлыга-тотлыга:

– М-м-мин бүтән алай итмәм! З-зинһар, миңа тимәге-е-ез! – диде дә, бу бит бар да төш кенә дип өметләнеп, күзләрен чытырдатып йомды.

Бер мизгелдә дрон юк булды, үзәк өзгеч безелдәү тынды. Икенче мизгелдә исә яр буенда утырган Су анасы, очкычын алып, буага чумды.

Ә Кәрим? Кәрим башкача беркайчан да кеше әйберенә тимәс булды...

podpiska.pochta.ru

# Дус кыйммәтме, абыймы?

Алсу – шук, кызыксынучан, сүзгә оста бер кыз. Аның очлы теле класстагы беркемне дә чәнчеми калмый иде. Шуның өчен дә укучылар арасында дус табу авыр булды Алсуга. Тик өченче сыйныфка килгән яңа кыз белән генә дуслашты ул. Асиянең яхшы укучы икәнлеге беренче көнне үк билгеле булды. Такта алдына чыгып сәнгатьле итеп шигырь сөйләүче дә, мәсьәләне “биш”легә чишүче дә, беренче булып йөгереп килүче дә Асия иде. Алсу аның уңышларын, радиодан тапшыру алып барган кебек, кычкырып сөйләп торды. Алар тиз арада шулай дуслашып та китте.

Мәктәптән бергә кайтып килә иде кызлар. Өч катлы өйгә җитәрәк тавыш ишетеп туктадылар. Бу күрше малайларның шаулашып уйнаулары булган икән. Кинәт, әллә нәрсәдән качкан төсле, барысы да төрле якка йөгереп таралдылар. Подъезд алдында зур яшьтәге апа гына басып калды һәм кызларның тетмәләрен тетәргә дә кереште:

– Тәрәзәмә кем кар ыргытты? Нигә яклашасыз? Үзегез аткансыз, димәк! – дип пыр тузды Рәсимә апа. – Хәзер үк әниләрегезгә шалтыратам!

Кызлар ни дип тә әйтә алмыйча, аптырашып басып калды. Бераздан Алсу уянган төсле сөйли башлады:

– Сезнең тәрәзә миңа кирәкми, икенче катка кадәр ыргыта да алмыйм мин!

Асия дә бераз сөйләшүне йомшартырга теләп:

– Тынычлансагыз, кемне күргәнемне әйтермен. Без очраклы гына монда торып калдык! – дип куйды.

Үзе бик икеләнде, күргән малайларның да кайсының исемен әйтергә төгәл белмәде, чөнки үзенең абыйсы да шулар арасында иде. Ничек булса да булды, туганының исемен телгә алмады.

Икенче көнне класстагы барлык укучы Асияне дошманы итеп күреп каршы алды. Аларның ачулы йөзләре дә, сөйләшмичә борылып китүләре дә, күрмәмешкә салышулары да кызны бик борчуга салды. Асия үзен гаепле итеп кенә түгел, ә сатлыкҗан, алдакчы итеп тә тойды...

Бу көнне аңа дус булган Алсу да:

– Үзеңнеке үзгә шул, туганыңны сатмадың! Ә калганнарны директор чакыртты, – дип йөрәген телде.

Нишләргә Асиягә? Ничек ялгышын төзәтергә хәзер?

***P. S.*** *Дуслыкның кадерен белергә кирәклеген Алсуга укытучы апасы әйтте. Класс җитәкчесе балаларны күзәтеп, үзенчә ярдәм итеп тора иде. Алсу Асиянең абыйсын директорга керергә күндерде, тәрәзәгә кар атучы табылды. Асиянең дусты барысын да хәл итте.*

***Әлфия МӨХӘММӘТҖАНОВА,***
*Дүртөйле районы Мәскәү урта мәктәбенең IV сыйныф укучысы.*






ЧИШМӘ

Авыл башы тау астыннан,
Кайнап чыга бер чишмә.
Челтер-челтер түбән таба,
Елгага агып төшә.

Ярлары да сөзәк кенә,
Бер яклап зирек үскән.
Җир-Ананың сихәт көче,
Чишмә суына күчкән.

Кайнап-ташып чыга чишмә,
Өстендә йөзә күбек.
Безгә серен сөйли гүя,
Дуслары итеп күреп.

– Сезнең өчен генә саклыйм
Күңелемнең түрләрен.
Тик тәрбияләп тотыгыз
Минем чыккан җирләрне.

КАР ЭРЕГӘЧ

Юлда эрегән кар суы,
Агып төшә канауга.
Канау кардан тазаргач,
Суы ага елгага.


Без, малайлар, елгага,
Көймә ясап картоннан
Җибәрәбез суга агызып,
Күзәтәбез артыннан.

Һәр малайга да кызык бит –
Ничек ага көймәсе.
Арадан берсе кычкыра,
“Минеке бит беренче!”

– Карагыз әле, минем көймәм
Ничек йөзә, – ди Марат. –
Минеке иң яхшысы, – ди
Сокланып тора карап.

***Ләйсән КӘРИМОВА,***
*Кыйгы районы Югары Кыйгы авылының 2нче урта мәктәбе укучысы.*

podpiska.pochta.ru



# Моң илчесе

Үә-үә-үә! Чү, нинди тавыш бу?! Бөтен җирне яңгыратып якты дөньяга сабый туа! Нинди бәхет, нинди шатлык?! Бер каләм белән дә язып, сүзләр белән дә әйтеп бетерә алмаслык олылардан-олы шатлык бит бу! Менә бәләкәч, алсу иреннәрен бөрештереп, әнисенең җылы куенына сыена. Әнисе аны саклык белән генә бишеккә сала. Бишеге дә нинди бит әле аның! Көтеп алган улына әтисе үз куллары белән ясады аны. Дим буенда үскән сыгылмалы нечкә таллардан үрде шул. Шулай итеп Наҗар исемле бер малай олы җиһанның кечкенә яшел бишегендә тирбәлә башлады...

Туган як! Нинди искиткеч матур, күңелемә якын сүз ул. Туган авылым, туган табигатем, туган туфрагым, әти-әнием... Шушы сүзләрне әйтү белән, минем күңелемдә ниндидер рәхәтлек хисе туа. Беренчедән, бу бит минем туып-үскән, беренче адым ясаган, уйнап-көлеп йөргән, беренче сүземне әйткән җирем. Икенчедән, монда минем иң якын кешеләрем, белем дөньясына әйдәгән мәктәбем, дусларым. Кем булуына карамастан, аның тормышын туган илсез күз алдына да китереп булмый торгандыр. Кайда гына тумасын, нинди илдә генә балачагын үткәрмәсен, барыбер үз Ватанын ул кеше өчен берни дә алыштыра алмый. Башка җиргә чыгып китсәң, сиңа хәтта туган як әрәмәлеге, кайчандыр син яратмаган гап-гади нәрсәләр дә кадерле була башлый. Мондый хисне, минемчә, бөтен кеше дә кичерәдер. Күренекле Башкортстанның халык шагыйре Наҗар Нәҗминең дә бөтен язмышы, иҗаты туган якка мәхәббәт, горурлану хисе белән сугарылган.

*Туган җирем, туган җырым –*
*Ак чишмәм син, Ак чишмәм!*
*Дөньямның бар ятларына*
*Серләремне чишмәм!*

Шушы җырны әкрен генә көйлим. Әнием дә бик еш бу җырны җырлый. Менә үзебезнең Каран чишмәсе янына килеп җиттем. Көмештәй суы ашыкмый гына ага да ага... Әкрен генә челтер-челтер көе ишетелә... Юк-юк, тавышы түгел, ә көе! Ихласлык, матурлык, тынычлык, мәрхәмәтлелек һәм миһербанлык белән сугарылган бу көй. Бары чишмәгә генә хас, Наҗар Нәҗми генә белгән кебек бу көйне. Акрын искән дымлы җил чәчләремне тузгыта. Күкрәк киереп тирән тын алам. Көч-куәт арткандай була, хәтта саф һавадан чак кына башым әйләнеп китә. Мин чишмә янында басып торам. Күпне күргән, күпне кичергән бу чишмә.... Кемнәр генә килмәгән дә, кемнәрнең генә йөрәк ялкыны түгелмәгәндер аңа. Ә ул ага да ага, еллар, гомерләр белән язмышлар аша... күңелне сафландырып, җаннарга сихәт биреп ага.

*Очраштырган, таныштырган*
*Егетләрен, кызларын,*
*Күпме җыңги, күпме килен,*
*Күргән көзен, язларын,*
*Эх, бу чишмә буйлары!*
*Эх, бу чишмә сулары!*

Бу чишмәгә бүгенге көндә дә кеше өзелми. Инде өйләргә кадәр су кергән вакытта олы апалар, әбиләр көянтә-чиләкләрен асып чишмәгә килә. Минем әбием аның суын “җанга дәва, тәнгә сихәт”, ди. Балачактагы бер матур күренеш истә калган. Күрше егете Илмир өйләнгәндә килен буласы кешегә су юлын шушы Каран чишмәсендә күрсәттеләр. Без бер төркем кызлар һәм малайлар,

podpiska.pochta.ru

## Тамгалы бозау

Таный алмадым
Алырга баргач,
Үз бозавымны
Тамгасыз булгач.

Алар таллыкта
Берничә дистә.
Кайберсе кызгылт,
Я сары төстә.

Бүген бергәләп
Китердек талга.
Йонына нәнәй
Бәйләде тамга.

Бозау тамгалы –
Кызыл чүпрәктән.
Тамгасы минем
Иске күлмәктән.





## Пешерергә өйрәнәм

Пешерергә өйрәнәмен
Азыкларның төрлесен.
Тәмләп карармын пешкәчтен
Ашның майлы өресен.

Иң беренче кирәк булыр,
Салыр өчен тәмләткеч.
Оныткамын, белкәемә
Кирәк икән алъяпкыч.

Өстәлдә савытта кәнфит
Тора иде күренеп.
Бармак очларыма басып,
Алдым аны үрелеп.

Урындыкка җайлап басып,
Сузылдым суыткычка.
Чак-чак мәтәлеп төшмәдем,
Уралып алъяпкычка.

Барыбер дә суыткычтан
Алдым кызгылт кишерне.
Суганын да, кыярын да
Табып алдым бишәрне.

Зур савытка салдым барын:
Кишер, кыяр, кәнфитен.
Онытмадым мин ашыма
Салырга сыер итен.

Аш пешердем көннең буе –
Симез калҗалы, итле;
Бигрәкләр дә тәмле булды,
Күбрәк салгач кәнфитне.






Резеда ШАКИРОВА

# Тузгакбаш тузганак

шигырьләр



Түллар
китапханәсе



*Мин, Резеда Флүр кызы Шакирова, 1962 елның 15 мартында, Башкортстанның Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында өч игезәк кызның иң кечесе булып дөньяга килгәнмен. Әтием халкыбызның моңлы җырларын тальянында уйнап башкара, әнием аңа кушылып җырлый иде. Әтинең Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил кебек шагыйрьләрнең әсәрләрен яттан укуы мәңгегә хәтеремдә уелып калды.*

*Мәктәп елларында әдәбият дәресләрендә укытучым Фәния апа Мусина шигъри әсәрләргә яңача карарга өйрәтте. Аннары Башкорт дәүләт университеты филология факультетының татар бүлеген тәмамладым. Соңыннан шактый еллар Уфа авиация-техник университеты китапханәсендә эшләдем, чит телләрне өйрәнү үзәгендә татар теле дәресләрен алып бардым. Бүген хаклы ялдамын.*

*Әдәбият мине үзенә һәрвакыт әйдәп, чакырып торды. Шигырь, хикәя, очерк һәм нәсерләремнең иң уңышлылары республика матбугатында даими басылып килә. Бүгенгә көнгә бернечә китабым дөнья күрде.*

*Балалар өчен язылган "Шук буран" һәм "Оялчан кояш" исемле шигъри җыентыкларым киләчәктә нәшриятта басылып чыгып, нәниләребез кулына барып ирешер дип ышанып калам.*

podpiska.pochta.ru

Йомгач күзләрне,
Әнием күрмәс.
Яңа уеннан
Мине һич бүлмәс.

Алган әтием
Матур бер күлмәк.
Туган көнемә
Искиткеч бүләк.

Матур күлмәкне
Киеп тә куйдым,
Ап-ак билбавын
Билемә будым.

Нәкъ итәгендә
Чәчәкләр ваклар:
Кызыл төсләләр,
Яшел һәм аклар.

Яңгыр яугач та
Тышка йөгердем.
Чәчәкләрен, дим,
Тизрәк үстерим.

Салдым да юдым
Җыелган суга.
Тик үсмәделәр,
Аптырыйм шуңа.



## *Тузганак-тузгакбаш*

Сап-сары келәм
Җәйгәннәр җиргә.
Кояш белән җир
Тоташкан бергә.

Келәм дигәнем
Тузганак икән.
Кояш сарысын
Алдымы микән?

Яңгыр яуганда,
Чәчәген каплый.
Елак тамчыдан
Ул шулай яклый.

Башында аның –
Төкле күп орлык.
“Өф” итеп өрсәң,
Коела мамык.

Куштым мин исем
Аңа әр-яңа.
“Тузгакбаш”, дисәм,
Карап елмая.





## *Атым*

Минем атымның
Исеме – Байрак.
Утырып чаба
Абый бик ерак.

Куалый аны
Биеккә – тауга.
Чаптырып төшкәч,
Китәләр ауга.

Урамда чабып
Көннәре үтә.
Атымны шундый
Арытып бетә.

Тәмам арыган
Уенчык атым.
Ял ит дип аны
Кочаклап яттым.





## *Ике сәгатькә*

Тәү кат бакчага барганны
Тотмыйлар икән озак.
Башта ике генә сәгать,
Аннан көн буе азак.

Бер сәгатьләп тик утырдым,
Кымшанмадым. Чын менә!
Шул арада елаштырдым:
– Әни кирәк, – дип, – миңа!

Тик утыру эш түгел! – дип,
Уйнарга булдым уен.
– Уен уйнагач, –ди апа, –
Үсеп киткән, – ди, – буең.

Өйгә кайткач та буемны
Үлчәр минем әтием.
Уеннан да туйдым әле,
Тизрәк килче, әнием!

... Яраттым мин бакчабызны,
Шау чәчәк тирә-ягы.
Тик ике сәгатькә генә
Иртәгә киләм тагы.





podpiska.pochta.ru

## Машинам

Машинамның бар:
Газы, педале.
– Яле, – ди, – эти, –
Йөреп карале.

Әтине тыңлап,
Кереп утырдым;
Ике куллап мин,
Рульгә тотындым.

Шәп итеп киттем,
Газына бастым.
Аю, төлкене
Стенага кыстым.

Тагын машинам
Җилдереп үтте;
Стена обоен
Ертып та китте.



Юл кагыйдәсен
Белми машина.
Газына бассам,
Бигрәк ашыга.

Өй эчендә бит
Төзелмәгән юл.
Ничек йөрергә
Кайдан белсен ул!



## Чиләктә йөздем

Сызганды әни
Күлмәге җиңен;
Идәнгә куйды
Матур чиләген.

Әни нигәдер
Ваннага китте.
“Нәрсә чиләктә?” –
Башка уй чиртте.

Атлыйм әкренләп
Чиләккә таба.
Әнием килми,
Күренми һаман.



Чиләк эченә
Карадым туры.
Күрдем чиләкнең
Суы туп-тулы.

Сулы чиләккә
Утырдым кереп.
Тик әни генә
Калмасын күреп.

Чәчрәтәм суны,
Идән тутырам.
Күзләрне йомып,
Уйнап утырам.



## Нигә елый?

Иртән йокыдан уяна
Гел дә Фәнилә елап.
Әни кулларына алып,
Күтәреп йөри көйләп.



Аптырадык абый белән,
Нигә елый сеңелкәш?
Көне буе уйладык та
Бирдек әнигә киңәш.

“Бу кадәр күп елавына
Түзәрлек түгел бер дә.
Күтәреп йөртерсеңме син,
Зур үскәчтен дә гел дә?

Тиктомалдан елый сеңел,
Авыртмый бит бер җире.
Магазинга эти белән
Илтеп куйыйк без кире”.

“Бәләкчнең, – диде әни, –
Әнә уртлары шешкән.
Ап-ак кына теше чыгып,
Яңак эчләрен тишкән”.

Менә нигә елый икән,
Авырткан авыз эче.
Елый икән Фәниләбез,
Чыккан саен һәр теше.



## Кер юа беләм

Керләр юарга
Кереште әни.
Карап торамын,
Чөнки мин – нәни.



Әнием суга
Порошок салды.
Аннары керне
Батырып алды.

Ышкыды аннан
Куллары белән.
Мин дә әнидәй
Кер юа беләм.

Шкафтан киемне
Төшердем тартып.
Юсам тунымны
Булмасмы артык?

Күлмәкләр юып
Карыйм бүгенгә.
Салдым тасыма
Агын, күген дә.

Суның җылысын
Тасыма салдым.
Кернең барысын
Батырып алдым.

Керләрем минем
Булачак бик ак.
Чөнки порошок
Салдым тулы кап.



podpiska.pochta.ru

## Зыянлы компьютер

Абыйның компьютерында
Бар шашкалар тактасы.
Көннәр буена уйнагач,
Ул – уенның остасы.

Кабызганын көтеп тора
Компьютерда шашкасы.
Мине һич тә кызыктырмый
Машинамнан башкасы.

– Әйдә, – димен, – Нияз абый, –
Икәүләп чыгыйк тышка.
Машинамны биреп торам,
Йөретеп ал саф кышта.

– Игътибар да итмисең бит
Әти-әни сүзенә.
Компьютерда күп уйнасаң,
Зыян килер күзеңә.

Ялгызым тышка чыктым да,
Йөрим уйлап, кар ерып.
Компьютерыннан абыйны
Булыр микән аерып?





## “Качышлы” уены

Нәнәем белән “Качышлы”
Өйдә көн дә уйныйбыз.
Көн дә, көн дә уйнасак та,
Ул уеннан туймыйбыз.

– Нәнәй, – димен, – яулык бәйлик, –
Бүген синең күзләргә.
Качып беткәч тә әйтермен,
Тотынырсың эзләргә.

“Качышлы” уйныйбыз өйдә
Нәнәем белән әле.
Бәйләнгән яулыкны алып,
Мине эзләгән мәле.

Күзләремне йомып яткач,
Нәнәем күрми китә.
Мине эзли-эзли торгач,
Нәнәмнең хәле бетә.

Беркөнне озак таппмыйча,
Сорап чыкты барсыннан.
Шул вакытта килеп чыктым
Зур караватт астыннан.





## Һөнәр иясе

– Бакчага барсаң, – ди нәнәй,–
Сорарлар бит, нәнием.
Нинди һөнәр ияләре
Әтиең һәм әниең?

– Нинди һөнәр ияләре,
Белми, дисезме, әллә? –
Җәйлап кына төшендерә,
Нәнәем шушы мәлдә.

– Әти эшли төзелештә,
Йортлар сала кирпечтән.
Әнием ап-ак икмәкне
Алып торучы мичтән.

Нәнәй өйдә генә тора,
Ә апам йөри укып.
Мин үзем дә өйдә эшлим
Нәнәй оныгы булып.





## Оннан – кар

Тартты тегермән
Нәнәй, картәти.
Калган ак оннан,
Ясыйм кыш – тәти.

Кыш булгач булсын,
Тулсын ак төскә.
Онлы савытны
Күтәрдем кичкә.

Сиптем мин аны
Чәчкә, чирәмгә.
Ап-ак онкаем
Китми әрәмгә.

Сагындым кышны,
Яудырдым кар-он.
Килер Кар бабам,
Белеп, кыш барын.

Тауга чанамны
Барырмын алып.
Киеп чыгыймчы,
Пимамны табып.





podpiska.pochta.ru

чыр-чу килеп, тамашаны күзәттек. Бизәлгән чиләкләрне мөлдерәтеп тутырып алды Айгөл апа. Шундагы олылар чишмәнеке кебек озын гомер, саф мәхәббәт теләде. Чынлап та бик бәхетле гомер кичерә бу матур, тату, тырыш гаилә. Ләкин чишмәләрнең гомере озын микән дигән уйлар да туа күңелдә. Ярый әле, без укучылар, авыл халкы чишмәләрне һәрдаим рәвештә өмәләр ясап чистартып торабыз. Бу күркәм гадәтне биология укытучысы Әлфия апа Хәйруллина оештырган иде. Әлеге вакытта аның эшен Миләүшә апабыз Гыйззәтуллина лаеклы дәвам итә. Башка җирдәге чишмәләрнең хәле ничек?! Аларны да онытмасыннар иде!

Чишмәнең икенче ярында солдатлар кебек рәт-рәт чыршылар тезелгән.

*Дим буенда, өй артымда*
*Миңеште чыршылары.*
*Дим һәм Миңеште арасы*
*Йөз чакрымнан ары, –*

дигән шигырь юллары ирексездән искә төшә. Әкрен искән җилдә тибрәлеп корыган ботаклары суга талгын гына килеп төшә дә кечкенә көймәләр сыман агып китә. “Кайларда икән сезнең туктар ярларыгыз?” – дип сорыйсы килә алардан. Ә алар үз юлларын күптән алганнар инде. Минем барасы юллар кай тарафларда икән?! Кайда гына булса да, бер генә теләк – туган якларымнан аермасын иде. Язмыш җилләре кайчакта бик усал була шул, кешеләрне үз төбәкләреннән аерылып китеп, чит җирләрдә яшәргә мәҗбүр итә. Мин үз тормышымда мондый катлаулы сынауларга түзә алмас идем.

Туган ил, туган як, туган туфрак төшенчәләре – һәркемгә дә газиз һәм кадерле. Нажар Нәҗми – бу хисләрне укучыларына каршылыклы һәм бәхәсле хисләр, уйлар аша җиткерүче әдип. Шагыйрь үзе әйткәнчә, кеше гомере – “Бер күз ачып – йомган ара гына”. Ул шушы гомере эчендә шигъриятебезне унбиштән артык поэмалары менән баетты. Кырыкка якын шигъри җыентык чыгарып өлгерде, драмалар иҗат итте, башкорт-татар җыр сәнгатенә дә үз өлешен кертте. Бөтен иҗаты халкыбызның рухи яшәеше, рухи сулышы белән сугарылды. Алар аша туган ягыбыз Башкортстанга, Уфабызга мәдхия җырлады, илебезнең башка төбәкләренә дә җылы хисләр белән мөрәҗәгать итте, чөнки ул – балачактан авыл көе тыңлап, көтү көтеп, саф чишмә суларын эчеп үскән бала:

*Авыл көе... Димәк авылныкы!*
*Үз туфраклы, җирле, үз илле!*
*Ул табигый –*
*җир астыннан бәреп*
*Чыккан гади чишмә шикелле.*

Шагыйрь өчен туган як кына түгел, ә һәрвакытта да сөекле халкы, әти-әнисе, теле һәрчак мөһим һәм кадерле булды. “Әни”, “Әтиемә”, “Татар теле”, “Бу җирләрдә...” кебек әсәрләре моңа ачык мисал.

*Калган! Нигез калды! Аны, әткәй,*
*Сатып ашамадык... Сатмадык!*
*Өч малаең – өч яугирең яуда*
*Нигезне һәм илне сакладык.*

Яки:

*Туган телдә, үз телендә генә*
*Аңлашалар кебек бу җирләр.*
*Аңлашкандай туган телләрендә*
*Новгородлар, Псков, Суздальләр.*

Нажар Нәҗминең шигырьләре кечесенә дә, олысына да аңлашыла. Тикмәгә генә аңа “Башкортстанның халык шагыйре” исемен бирмәгәннәрдер. Моның сере авторның телендә, язу стилендә. Гади халыкчан тел. Аның шигырьләрен укып аңлар өчен әдәби белем кирәкми, аның һәр сүзе моңга тартылып тора. Көн дә диярлек “Юлдаш” радиосыннан агылган “Уфа юкәләре” җырын белмәгән якташларыбыз юктыр дияр идем мин.

*Яшьлек урамнары,*
*Тулы хыяллары,*
*Без – шатлыкка туймас исәрләр.*
*Уфа юкәләре*
*Безнең хакта да әле*
*Яфрак яра-яра сөйләрләр.*

Әйе, шагыйрьне хаклы рәвештә туган ягының моң илчесе дип атыйлар. Нажар Нәҗми туган як табигатенең, Агыйдел елгасы буйларының гүзәллеген, урман-тауларының, чәчәкле болыннарының күркәмлеген, чишмәләрнең сихри тавышын, кошлар сайравын шигырьләренә, җырларына кертә, алар белән горурлана, уй-хисләрен туган як табигате гүзәллеге аша бизи, матурлый. Шулар белән үзе генә сокланып калмый, аларны иҗаты белән чит җирләргә дә тарата, Дүртөйле якларында бер генә дә тапкыр булмаган читләрне дә туган ягы белән таныштыра, яктылыгын ача. Сүземне үзенең юллары белән тәмамлыйсым килә:

*Кеше җаны, туган җире кебек,*
*Үз кояшы белән кояшлы!*

***Розалина ҖӘЛАЛОВА,***
*Бүздәк районы Каран урта мәктәбенең VIII сыйныф укучысы.*

# *Ел мизгелләре*

Мин үземне бик тә бәхетле итеп саныйм. Безнең илдә генә бөтен ел фасылларының матурлыгын күрергә, тояргә мөмкин. Иң-иң җылы җәйләр бездә, иң-иң мул, алтын сары көзләр бездә, иң-иң ап-ак кышлар бездә, иң-иң язгы шаулап аккан ташкыннар да бездә генә...

Җәй көне минем сагынып көтеп алган каникулларым башлана. Бөтен бала-чага күп вакытын тышта, уенда уздыра. Кызу көннәрне су коенабыз, җиләк пешкәч, җиләк җыябыз, урамда футбол, волейбол уйныйбыз. Төнгә кадәр бала-чаганы урамнан кертеп тә булмый.

Көзен тагы мәктәпне сагынып укырга киләбез. Ял итеп, яңа көчләр җыеп, парталар артына утырабыз. Белем дөньясына чумабыз. Укуы авыр булса да, һәр укучы урмандагы кырмыскалар кебек, үзенчә белем алырга тырыша.

Кыш көне бергә җыелышып Кар бабай ясыйбыз, кар атышлы уйныйбыз, чаңгыда шуабыз. Иң рәхәте – кыш көне биек таудан чанада төшүе, шугалакта тимераякта шууы. Нинди рәхәт һава ул кыш көне!

Язны да бик сагынып көтеп алабыз. Урамнар буйлап ерганаклар акканын түземсезлек белән карап торабыз... Шул ерганаклардан кәгазьдән ясалган көймәләр йөздерүе үзе ни тора! Хәзер урамда көймә йөздергән балаларны сирәк очратасың. Ерганаклардан сикереп, йөгереп өс-киемнәребез чыланып, пычранып бетә, ләкин бу безне һич тә туктатмый. Ничек тә булса, уйнап калырга тырышабыз. Җылы кояш нурлары астында бу ерганаклар бик тиз кибеп тә бетә. Аннары туган якларына ашкынып сыерчыклар кайта. Аларның матур, моңлы итеп сайраулары безне шундый сагындырган... Читтән карап торсаң, бик кызыклы күренеш: тиздән алар бала чыгара һәм тырышып-тырышып балаларына ашарга алып кайта башлый. Менә бәләкәч кошчыклар әкренләп үсә, канат чыгара һәм очарга өйрәнә. Шулай һәр ел фасылы үзенчә сизелмичә үтә дә китә.

Мин барлык ел фасылларын да бик яратам, һәрберсен сагынып көтеп алам.

***Илина НАСЕРТДИНОВА,***
*Туймазы районы Татар-Олкан урта мәктәбенең V сыйныф укучысы.*

podpiska.pochta.ru

# Балачак хикәяләре



Гөлфизә КӘЛИМУЛЛИНА

## Оекбаш

Картәнисе Салаватка ак сарык йонынннан җылы оекбашлар бәйләп бирде. Кунычын кара төстәге ике буй сыр белән бизәде. Чөнки ул балалар бакчасына йөри, ә анда күпвакыт әйберләр алышынып бетә. Хәзер Салават беркайчан да тамгалы оекбашларын бүтәннәрнеке белән бутамас.

Икенче көнне әнисе, матур оекбашларны кидереп, аны тәрбияче кулына тапшырды. Салават бакчада рәхәтләнеп уйнады. Бүлмәнең бер башыннан икенче башына чапты. Оекбашлар бик уңайлы, үзеннән-үзе йөгертә иде.

Төшке ашны ашап алгач, балалар бер кат киемнәрен салып утыргычка куйды да, йокларга ятты. Салаватның яңа оекбашлардан бер дә аерыласы килмәде. Тәрбияче күргәләгәнче тизрәк юрган астына чумды...

Ул кемдер иңеннән селкеткәнгә уянып китте. Бик каты йоклаган икән. Башкалар уянып, киенә башлаган иде инде. Күзләрен уа-уа торып утырды. Шулчак карашы аякларына төште, бер аягында оекбаш юк иде. Малай яхшы хәтерли, ятканда икесе дә аякларында иде. Карават астында да, утыргыч өстендә дә сыңар оекбаш күренмәде.

Аның мыштырдаганын күреп, янына тәрбияче апасы килде. Икәүләшеп эзли башладылар. Берәздән ярдәмчеләр күбәйде. Тик оекбаш табылмады. Салаватның күз яшьләре бите буйлап агып барып, идәнгә тамды.

Аптыраган тәрбияче: ”Туктале, монда түгелме икән?” – дип, куллары белән тышлы юрганны капшый башлады. Сәрмәнә торгач, юрганның бер почмагыннан югалган оекбашны тартып чыгарды. Барысы да көлеп җибәрделәр. Күрәсең, Салават йоклаганда аягын юрган тышының уемына тыккан да, шул чагында оекбаш сыдырылып төшеп калган.

Шатлыгыннан авызы ерылган малай, сикерә-сикерә, иптәшләре янына йөгерде.

## Кибеттә

Рамазан бик тә туңдырма ярата. Әнисе генә: ”Син яратасың да бит, ә менә туңдырма сине яратмый”, – ди. Кибеткә дә ияртми. “Тегене-моны сорап кеше алдында мине оятлы итәсең”, – ди.

Картәнисе алай дими. Тик ул кибеткә бик сирәк чыга. Ә менә пенсия акчасын алган көнне бармый калганы юк. Аның кибеткә чыккан вакытын чамалаган малай, тәрәзәдән карап көтеп тора, ул күренү белән каршысына йөгереп чыга.

Менә бүген аны көтеп, капка төбенә үк чыгып басты. Берәздән, кешелеккә генә дигән матур күлмәген кигән, чәчәкле зәңгәр яулыгын ябынган картәнисе күренде. Тик үзе генә түгел, бәләкәй Даутны да иярткән. Димәк, шәһәр малаен тагын кайтарып куйганнар. Чын исеме Дэвид аның. Картәнисе бу исемне яратмыйча, Даут дип йөртә. Рамазанның да аның исемен әйтергә, картәнисе әйтмешли, теле әйләнми, шуңа ул да Даут дип дәшә.

Рамазанны күргәч, нәни малайның авызы ерылды, хәтта олыларча кул биреп күрешкән булды. Даут татарча сөйләшми, шулай да үткән кайтканында бик матур итеп “абый” сүзен әйтергә өйрәнгән иде. Онытмаган икән, әле дә “абый” да “абый” дип бер алдына, бер артына төште, сагынган, күрәсең. Рамазан, абый кеше буларак, Даутны



podpiska.pochta.ru

икенче кулыннан җитәкләп алды. Кибеттә кеше хәтсез иде, чиратка басарга туры килде. Алардан алда бәләкәй малаен кулыннан тоткан яшь кенә чибәр апа басып тора. Рамазан кызыксынып малайны күзәтте. Моңарчы аны бер дә очратканы юк иде. Даут шикелле кунакка кайткан малай микән?

Таныш булмаган малай, әнисеннән кулын ычкындырып, тезеп куелган йорт кирәк-яраклары янына килде. Төрелеп куелган клеенкаларның берсенә күрсәтеп:

– Әни, әйдә менә монысын өстәлгә җәяргә алыйк, бездә андый матуры юк бит, – диде. Кибеттәге халык елмаеп куйды. Аннары ят малай берсе өстенә берсе өелеп куелган, төрле төстәге чиләкләр янында тукталды. Арадан берсен сайлап алып, әйләндергәләп карады да читкәрәк алып куйды.

Чиратта басып торган бер апа, малайга ымлап:

– Кара, ничек оста итеп дөнья кирәк-ярагын сайлый, – диде. Кибеттәге апалар малайга соклanып та, яратып та карап тора иде.

Рамазан аптырады: туңдырма да, сагыз да таптырмады нәни малай. Картәнисе Рамазанга ул сораган стаканлы иң тәмле туңдырманы алып бирде дә колагына: ”Бар, тизрәк кайт!” – дип пышылдады. Чөнки Даутка туңдырма ашатмыйлар, тамагы шешеп чыга. Ул арада Даут, аның кулындагы туңдырманы күреп калып, еларга уйлаган иде дә, картәнисе: ”Это не мороженое, ә катык”, – дигәч, тиз тынычланды. Даутның катык яратмаганын Рамазан да белә.

Туңдырмасын тәмләп ялыйялый Рамазан кайтырга чыкты. Аннан арттарак, тезелешеп, кулына алма сурәте төшкән чиләк тоткан бәләкәй малай, култык астына матур бизәкле клеенка кыстырган яшь апа, бер кулы белән Даутны җитәкләгән, икенче кулы белән тәм-томнар салынган сумкасын күтәргән картәнисе атлый иде.

## Кар шары

Менә ничә көн инде бакча балалары тышка уйнарга чыга алмый. Бу арада бертуктаусыз карлы яңгырлар ява. “Көзнең китәсе килми, елый”, – ди тәрбияче апалары.

Бүген төнлә кинәт кенә салкынайтып җибәрде. Иртәнгә таба бераз җылытып, җепшек кар ява башлады. Бөтен тирә-як күзне чагылдырырлык аклыкка чумды. Кар явуы туктагач, тәрбияче балаларны мәйданчыкка алып чыкты. Алар шундук кар йомарлап бәрешергә, йөгерергә, шаярырга тотынды.

Ризван Кар бабай ясамакчы булды. Куллары белән кыскалап кар йомарламы ясады да, җепшек кар өстенә куеп, тәгәрәтә башлады. Кар катламы әлегә юка булганлыктан, аның артыннан кара юл сузылып барды.

Менә кар йомарламы зурая башлады: башта туп хәтле, аннары өреп кабарткан шар кадәрле булды. Бераздан, этәргә көче җитми башлагач, иптәшләрен чакырды. Күмәкләшеп кар шарын тегеләйболай тәгәрәтеп йөртергә тотындылар. Балалар арып туктаганда мәйданчыкта кара җир генә калган, ә кар шары Ризваннан да биегрәк булып киткән иде. Балалар юеш бияләйләре белән сыпырып шарны шомартты. Ризван шар өстенә менеп утырмакчы булган иде дә, булдыралмый кире шуып төште. Башкалар да аяк белән тыпырчынудан уза алмады. Ул арада ашар вакыт та җитте.

Икенче көнне Ризван бакчага беренче булып килде. Уе – абыйсы өйрәткән буенча йөгереп килеп, кар шарына менеп утыру һәм шул халәттә иптәшләрен каршылау иде. Капкадан керүгә Ризванның күзләрен яшь пәрдәсе каплады, аяклары атламас булды.

Күпме көч сарыф итеп ясалган кар шарын төнлә белән кемнәрдер ватып, изгәләп киткәннәр иде.

## Беренче тапкыр чаңгыда

Регина башлангыч сыйныфта укый. Рәсем төшерергә бик һәвәс. Авылда сәнгать мәктәбенең филиалы эшли, дәресләрдән соң ул шунда ашыга. Бик теләп йөри, бармый калганы юк.

Кышның матур бер көнендә укытучы абыйлары аларны табигать кочагына алып чыкмакчы булды. Чаңгы тагып барырга кирәклеген белгәч, Регина кара кайгыга батты. Чөнки аның чаңгыны киеп тә караганы юк иде. Аларның хакы бик кыйммәт, шунлыктан күпләрнең чаңгы сатып алырга хәленнән килми шул.

Кемнәрнең чаңгысы юк, мәктәптән алып тордылар да сәгать өчкә җыелырга сөйләшеп таралыштылар…

Китәр вакыт җиткәч, әнисе Регинага чаңгыларны кияргә ярдәмләште дә үз эшләре белән өйгә кереп китте.

Беренче тапкыр чаңгы тагып караган һәркем аның хәлен аңлагандыр инде. Көч-хәл белән аякларын шудырып, кыз урамга чыкты. Чаңгылар икесе ике якка китә, таяклар да ярдәмче түгел, комачаулый гына.

Интегә-интегә, ниһаять, ул олы юлга чыкты. Артта машина тавышы ишетелде. Берсе өстенә берсе менгән чаңгыларга абынып, юл уртасында тәгәрәп яткан кызга бәрелмәс өчен читкә чыккан җиңел машина көрткә кереп батты. Үтеп баручы кешеләр, көлешә-көлешә, машинаны кардан этеп чыгарды. Бәхетенә руль артында укытучы абыйсы иде.

Мәктәпкә чаклы Регина машинага утырып барды баруын, тик аннан соң нишләр?

Бергәләшеп, тезелешеп юлга чыктылар. Башкалар остарып беткән, шундук күздән югалды. Регина гына артта калды, тирләде, пеште. Укытучы аның халәтен күреп: ”Регина, булмаса, бүгенгә кайтып тор инде”, – диде. Чаңгыларын култык астына кыстырган кыз, авызын ерып, авылга таба элдертте. Аның куанычы эченә сыймый иде.

podpiska.pochta.ru



Гөлия ГӘРӘЕВА

# Бүреләр өнендә

*Хикәя*

podpiska.pochta.ru

Айгөл тукталышта автобустан төшеп калды да, гадәттәгечә, өе ягына шәп-шәп атлады. Җәйге матур кич иде. Кояш инде бераз сүрелгән, талгын гына җил исә. Бу вакытта шәһәр җанланып китә. Кемдер эшеннән өенә ашыга, эсселектән фатирында качып яткан бала-чага урамга уйнарга чыга, подъезд алдындагы эскәмиядә өлкән яшьтәгеләр күренә башлый. Хәзер өйгә кайтам да, токмач кисеп, тәмле итеп аш пешерәм, дип уйлады хатын. Шунда өйдә ипи беткәнлеге исенә төште. Кибет киштәләрендә тезелеп яткан яңа гына пешерелгән, күпереп торган икмәкнең исе болай да бераз ачыккан хатынны тагын да кабаланырга мәҗбүр итте. “Тулы бер икмәк алсам, искерә инде... Менә бу ярты икмәкне генә алыйм, булмаса”, – дип, кәрзиненә салды ул. Аннары казылык саткан бүлеккә атлады. Анда да төрле иттән әзерләнгәннәре “мине ал, мине ал” дигәндәй, туңдыргыч пыяласы аша хатынга карагандай булды. Тагын да кечкенә шешәдә сөт, бәләкәй генә сыр телеме, ике алма, бер банан һәм башка шулай берәмләп кенә сатылган азык-төлекне кәрзиненә тутырды хатын.

Фатирга килеп керү белән аягына хуҗасын көткән